ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА
№10 (334) – ОКТЯБРЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
ISSN 0130-2418
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Умартачының балсыз тормышы

Беренче һәм соңгы сәфәр…

Якты киләчәк ничек төзелгән

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ: ЮГАЛГАН МИРАС ЭЗЕННӘН…

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Мөршидә Кыямова, Ксения Сёмина,
Луиза Шарова, Илшат Фәйзрахманов
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта галим Миркасыйм Госманов.
Фото Госмановларның гаилә архивыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-2896
Басарга кул куелды: 25.10.2019
Басмадан чыкты: 31.10.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ҖАН ҖЫЛЫСЫ САКЛАНСЫН...

Шулай бервакыт Татарстандагы Олы Мәми авылында Чеховның кат-кат укудан шактый таушалган томыннан бер хат килеп чыккан: кулдан язылган, хәрефләре матур итеп бөгелгән, сырланган. Күрәсең, ниндидер бер яшь туташ, бу хатка хисләрен кушып, бик тырышып язгандыр. Мәхәббәт бөркелеп тора ул хаттан. Пушкин мәдхия җырлаган Татьяна булмаса да, безгә таныш түгел Настенька В. язган юллар «Онегин»дагы тойгылардан бер дә ким түгел.

Инде җир йөзендә без хатын сокланып укыган Настенька В. да, Татьяна Ларина да күптән юк. Ә менә хатлары исән – алдыбызда ята, кәгазь аша хисләр кайнарлыгын бөрки. Аларны уку – үзе бер ләззәт... Сәяхәт итәргә яраткан «Татарстан» журналы журналистларына гына да түгелдер, дип уйлыйм. Мондый затлы ләззәткә өстенлек бирүчеләр шактый җыела, ахрысы. Югыйсә хатларга тулы бер күргәзмә багышламаслар иде...

Свияжскидагы яңа ачылган күргәзмәдә кулдан язган хатлар сәнгатенә орынып карарга мөмкин. Экспонатлар, чынлап та, гаҗәеп. Кайчандыр яза белү сәнгате элитар төр булганга, һәркемгә дә өйрәнә алу мөмкинлеге чыкмаганга, ул югары сыйныфлар билгесе булып исәпләнгән.

Хәзер инде без электрон хәбәрләр ташкыны заманында яшибез. Алар да – хатның бер формасы, ләкин биредә формальлек юк һәм катгый кагыйдәләр кешене чикләми. Тик шунысы бар: электрон хатларда җан калмады...

Менә шушы сораулар бимазалаганга,«татарстан»лылар Свияжскига юл тотты да инде. Ә сез хатлар язасызмы, ханым, әфәнделәр? Нинди булса да ярый: электрон хатлар, телефондагы хатлар... Иң мөһиме: ул хатларда җан җылысы сакланып калсын!

СЕЗНЕҢ КЫЗЫКСЫНУЧАН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Александр Шадрин, «Бабушкины сказки»

ОКТЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

8. Иделдә тәҗрибә
Сыегайтылган табигый газда эшләүче суднолар кайда чыгарылачак

10. Үсеш катализаторы
Республика нефть-газ химиясе комплексын нинди үсеш көтә

12. Безнең горурланырлык эшләребез бар
Рөстәм Миңнехановкиңкүләм бурычлар һәм нәтиҗәле карарлар турында

16. Күзгә нәтиҗәләр
Умартачының балсыз тормышы

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

30. Редакция кухнясында
Икмәк пешерү серләре

34. Өлкәннәребез
«Мин аларга хәер-догада...»

38. Аклы-кызыллы бәрелеш
101 ел үткәннән соң...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

46. «Без күпләрдән бәхетлерәк идек...»
60 нчы елларда Чулман ярында төзелгән шәһәр

50. Беренче һәм соңгы сәфәр
ТАССРда Никита Хрущёвны ничек каршы алдылар

52. Бөек Пётрның һава флоты
Американы юкка чыгарырга тиешле самолётлар кайда җыела

56. Бәхет тулы еллар...
Беренче Казан «хрущёвка»ларында кемнәр өй туйлары уздыра

69. Тарих
Батырша җитәкчелегендәге халык күтәрелешләре

72. Кече Ватан патриотлары
Миркасыйм Госманов: югалган мирас эзеннән...

84. Татар авыллары
Бигеш – үткәннәр сагында

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

14.10

Исмет Эрикан, Төркиянең Казандагы генераль консулы, – журналистлар белән очрашуда:

– Россия һәм Төркия Президентлары илләребез арасындагы товар әйләнешен хәзерге 35 миллиард доллардан 100 миллиардка кадәр күтәрү максатын куйды. Әгәр 314 миллион доллар (Татарстан белән Төркия арасындагы товар әйләнеше – **ред.иск.**) 1 миллиардка кадәр генә үссә дә, без ике ил җитәкчеләре куйган гомуми максатка ирешү өчен үз өлешебезне керткән булабыз. Әгәр без бу саннарга элегрәк ирешкәнбез икән, аларга хәзер дә җитәргә мөмкин, моның өчен нинди дә булса каршылыклар юк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

16.10

Александр Моор, Төмән өлкәсе губернаторы, – Татарстанга эш сәфәре тәмамланганнан соң:

– Беренче чиратта, үзебез өчен нинди тәҗрибә алдык, – бу махсус икътисадый зоналар, сәнәгать парклары, индустриаль мәйданчыклар булдыру тәҗрибәсе. Әлбәттә, әлеге өлкәдә Татарстанның бик зур тәҗрибәсе бар. Һәм бу юнәлештә без дә актив хәрәкәт итәбез. Бүген без, Тобольскида «СИБУР» белән бергә зур икътисадый зона булдыру өчен, үзебезгә партнер итеп «Алабуга» идарә итүче компаниясен алырга килештек.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

16.10

Михаил Борисов, телевидениедә алып баручы, ГИТИСның кафедра җитәкчесе, – Казанда, мәдәният һәм мәгариф буенча «КазГИК-50» халыкара саммитында:

– Яшь буын сәер һәм өлкәннәргә аңлашылмаган сленгта сөйләшә. Клип рәвешле фикерләүгә чумып, кеше үзе дә үзгәрде. Әмма театр сәнгать буларак инде өч мең ел яши, ул бу авыруны кичерер һәм алга таба китәр, дип ышанам.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Республика газ-нефть комплексын **НИНДИ** үсеш көтә

Сыекландырылган табигый газда эшләүче суднолар **КАЙДА** җыелачак

Быел бал кортлары **НИ ӨЧЕН** күпләп кырылды

ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2020 елның
I яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 933 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 933 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7077 **татар телендә**

П 7076 **рус телендә**

«Татарстан» журналына ТР буенча еллык язылу индекслары:

ПА 468 **татар телендә** 1866 сум 00 тиен

ПА 471 **рус телендә** 1866 сум 00 тиен

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

АВТОГРАД: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

Фотолар ТР Президенты сайтыннан (Марсель Бадыйкшин)

НӘРСӘ:

Машина төзүчеләр көненә багышланган чара

КАЙДА:

Яр Чаллы

КАЙЧАН:

9 октябрь

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Автогигант, җитештерүне тулысынча яңартып, үзенең 50 еллыгын лаеклы каршы ала. Агымдагы елның маенда – кабина каркасларын җитештерү, июньдә – алюминий ягулык бакларын җитештерү заводы ачылды. Быелның дүртенче кварталында К5 буыны йөк машиналарын җитештерүне башлау һәм аларны тест рәвешендә сынауга тапшыру планлаштырыла.

ТУЛЫРАК:

Яр Чаллыда Татарстан Президенты КАМАЗның беренче генераль директоры Лев Васильев бюстын ачу тантанасын ачты. Лев Васильев Кама автогигантын 1969 елдан 1981 елга кадәр җитәкләде. Әле вакыт аралыгында япан кырда заводлар комплексы сафка басты һәм зур йөк машиналары җитештерүгә эшли башлады.

– КАМАЗ – илебез горурлыгы ул. Һәм монда Лев Борисович Васильевның өлеше гаять зур. Аның җитәкчелегендә йөк машиналары җитештерү буенча өр-яңа предприятие төзелде. Аның вакытында Яр Чаллы кечкенә генә бистәдән эре шәһәргә әверелде, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Миллионлаган квадрат метр торак, дистәләгән мәктәп, балалар бакчасы, сәламәтлек саклау учреждениеләре төзелде. Без һәрвакыт Лев Борисовичның республика машина төзелеше үсешенә керткән гаять зур хезмәте өчен рәхмәтле булырбыз.

Алга таба ТР Президенты шәһәрнең үзәк магистрален (Әлмәт тракты – Җәлил проспекты – Яр Чаллы проспекты – Тынычлык проспекты – Алиш урамы) капиталь ремонттан соң ачу тантанасында катнашты. Ул «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» федераль программасы кысаларында төзекләндерелде. КАМАЗның 50 еллыгы алдыннан шәһәрне төзекләндерү, шул исәптән юл инфраструктурасын үстерү буенча кайбер проектлар гамәлгә ашырыла, дип искә төшереп үтте Президент.

Машина төзелеше көненә багышланган тантаналы чараны ачканда Рөстәм Миңнеханов, аерым алганда, болай диде: әлеге бәйрәм традицион рәвештә Яр Чаллыда уздырыла. 40 елдан артык КАМАЗ илебездә йөк автомобильләре җитештерүчеләр арасында лидер булып кала бирә. Ә электробуслар, пилотсыз идарә ителешле авомобильләр, яңа К5 автомобильләре буыны предприятиенең киләчәктәге үсеше өчен әзерлек булып тора.

ТР Президенты Яшел Үзәндәге Горький исемендәге заводны машина төзелеше комплексы предприятиеләре арасында лидерларның берсе дип атады. Бирелә Россиядәге һәр өченче хәрби корабль җыела, дип билгеләп үтте ул. Алай гына да түгел, суднолар Яшел Үзән проект-конструкторлык бюросы белгечләре тарафыннан проектлаштырылган. Казан авиация заводында да тирән модернизация узды. «Ту-160 самолётларын җитештерү һәм Ту-22М3М очкычларын модернизацияләү буенча ил җитәкчелеге тарафыннан күрсәтелгән тирән ышанычны югары сыйфат һәм дәүләт оборона заказын вакытында башкару аша акларга тиешбез. Шул ук вакытта заводка гражданлык авиация төзелешендә дә компетенцияләрне саклап калу мөһим», – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов.

ТР Президенты оборона сәнәгате комплексы предприятиеләрендә граждан продукцияләрен җитештерү өлешенең үсә баруын хәбәр итте. Моңа «ПОЗИС» компаниясе яхшы мисал булып тора, анда җитештерелә торган продукциянең яртысы диярлек хәрби заказ түгел. Завод әлеге күрсәткеч буенча илдә лидерлар арасында. Предприятиедә уздырыла торган модернизация куәтләрне 40%ка арттырырга, җитештерүне нәтиҗәлелеген күтәрергә һәм ассортиментны киңәйтергә мөмкинлек бирә.

Рөстәм Миңнеханов шуны да искә төшереп үтте: якын елларда РФ Президенты тарафыннан куелган киңкүләм үсеш бурычларын тормышка ашырырга кирәк булачак. Аларны хәл итү өчен предприятиеләрен модернизацияләү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, цифрлы заман стандартларына туры килүче инновацияләрне һәм алдынгы фәнни эшләнмәләрне гамәлгә кертү таләп ителә. Югары квалификацияле белгечләрне әзерләргә, эшче һөнәрләренең абруен күтәрергә, егет-кызларның үз эшләренең осталарына әверелергә омтылышын хупларга, югары профессиональ стандартларны тормышка ашыру өчен шартлар тудырырга кирәк.

Наил Мәһдиев, Яр Чаллы мэры:
– Биш ел дәвамында Яр Чаллыда юллар төзелешенә һәм аларны ремонтлауга ике миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелә. Ярдәмнәре өчен Россия һәм Татарстан Республикасы җитәкчелегенә рәхмәтемне белдерәсем килә.

ИННОПОЛИС.
«ГАЗПРОМ» БЕЛӘН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

НӘРСӘ:

«Газпром» ГАҖ һәм ТР предприятиеләре арасындагы хезмәттәшлек сораулары буенча киңәшмә

КАЙДА:

Иннополис

КАЙЧАН:

15 октябрь

Фотолар ТР Президенты сайтыннан (Рөстәм Кадыйров)

ТУЛЫРАК:

Киңәшмә алдыннан Татарстан Президенты һәм «Газпром» ГАҖ идарәсе рәисе урынбасары Виталий Маркелов газ-мотор техникасы үрнәкләре белән таныштылар. Газда эшләүче җиңел автомобильләр һәм авыл хуҗалыгы машиналары, шул исәптән Алабуга районындагы заводта чыгарыла торган «МТЗ» тракторлары да күрсәтелгән иде. Биредә үк газ-турбиналы приводы булган модульле мобиль компрессор җайланмасын күрергә мөмкин булды. Ул табигый газны магистраль газүткәргечнең ремонтлана торган участогыннан эшли торган газ үткәргечене суыртуу өчен кулланыла. Иннополис университеты холлында Рөстәм Миңнеханов һәм Виталий Маркелов шулай ук «Газпром» ГАҖның структур бүлекчәләре ихтыяҗлары өчен Татарстанда эшләнгән инновацияле һәм импортны алыштырырлык технологияләр күргәзмәсе белән таныштылар. Аерым алганда, вуз вәкилләре республикада «ТРның цифрлы моделе» дип аталган болытлы 4D-геомәгълүмат платформасын эшләү һәм сынау рәвешендә гамәлгә ашыру турында сөйләделәр. Система территорияләрне мониторингларга мөмкинлек бирә, төрле тармаклар, шул исәптән АСК, урман хуҗалыгы, шәһәр хезмәтләре өчен төрле чишелешләр тәкъдим итә. Нефть-газ секторында торбаүткәргечләрнең һәм саклана торган зоналарның халәтен контрольдә тоту, чыганакларның 3D-модельләрен төзү, һ.б.лар өчен әлеге системаны кулланырга мөмкин.

«Газпром» ГАҖ ихтыяҗлары өчен Иннополис университеты тарафыннан тормышка ашырыла торган беренче проектлар арасында комплекслы геомеханик модельләштерүнең мәгълүмати нигезе эшкәртмәсе дә бар. Әлеге системаның өстенлеге шунда: ул тулысынча үзебездә эшләнгән. Димәк, чыганакларның урыны турындагы мәгълүмат читкә китә алмый. Математик модель Иннополис программистлары тарафыннан уйлап табылган һәм «Газпромгеологоразведка» белгечләре тарафыннан чынбарлыктагы объектларда сыналган.

Иннополис университеты белгечләре шулай ук технологик торбаүткәргечләргә техник диагностика үткәрүнең интеллектуаль системасын тәкъдим иттеләр. Ул газүткәргечләр турындагы мәгълүматның тулылыгын арттырырга, техник диагностика һәм ремонтның нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. «Электроприбор» (алмашучан ток өчен «Патриот» сериясендәге автомат аергыч), «Тасма» (радиографик техник плёнка), «КМТБ» (газ суыртуу агрегатлары компрессорларының приводлары өчен двигатель), «Казанкомпрессормаш» (технологик газлар өчен компрессорлар), «РариТЭК» (сыекландырылган табигый газ салуның виртуаль ассистентлары) кебек предприятиеләр дә үзләренең эшкәртмәләрен күрсәттеләр.

А. М. Горький ис. Яшел Үзән суднолар төзү заводы күргәзмәсе янында Рөстәм Миңнеханов һәм Виталий Маркелов сынау рәвешендәге проектны гамәлгә ашыру чаралары планын имзаладылар. Әлеге проект ТРның туристик маршрутларында сыекландырылган табигый газда эшләүче елга судноларын куллануны күздә тота. Шундый беренче судно Яшел Үзәндә инде төзелә.

КАЗАН.
ҮСЕШ КАТАЛИЗАТОРЫ

Фото ТР Президенты сайтыннан

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Нефть-газ комплексының алгарышлы үсеше икътисадның барлык секторларында химия һәм нефть химиясе продукцияләрен куллануны интенсификацияләүгә бәйле. Дөнья тәҗрибәсе күрсәткәнчә, нәтиҗәле дәүләт ярдәменә таянганда мондый алгарышлы үсешкә ирешү мөмкин. Аның төп инструментлары – сәнәгать һәм инфраструктур проектларны гамәлгә ашыру өлешендә дәүләт-хосусый партнерлыгы һәм дәүләт финанславы. Әлеге мәсьәләдә республикада системалы якын килү 1999 елдан бирле тормышка ашырыла.

НӘРСӘ:
ТР Куркынычсызлык Советы утырышы

КАЙДА:
Казан Кремле

КАЙЧАН:
18 октябрь

ТУЛЫРАК:

Утырышның төп темасы 2020–2024 елларга республиканың нефть-газ химиясен үстерү программасын тикшерү булды. ТР Президенты Россия Президенты Владимир Путинның Май указында кайбер милли максатлар, шул исәптән икътисадый үсеш темпларын тизләтү, чимал булмаган экспортны киңәйтү һәм ил икътисадының Евразия икътисадый берлеге илләре арасында иң көчле беренче бишлеккә керүе каралуын искә төшереп үтте. «Әлеге максатларга ирешү юлларының берсе булып тулаем икътисадка мөһим мультипликатив нәтиҗәлелек бирергә сәләтле нефть-газ химиясе комплексын үстерү тора», – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов.

«Узган 20 ел эчендә Татарстанның нефть-газ химиясе комплексында төп өстенлекле юнәлеш булып углеводород чималын эшкәртүнең тирәнлеген арттыру торды, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Әлеге өстенлекле юнәлеш яңа, бишенче программада да сакланып кала. Без аны яхшы чимал базасы һәм перспективалы планнар белән башлыйбыз. Моннан алдагы программа комплексны стратегик үстерүнең яңа инструментлары таләп ителүен күрсәтте. Күп кенә тармаклар яңа, күпмедер күләмдә гадәти булмаган һәм үзләре өчен уңайсызрак шартларда эшли башлады. Без җайлашырга тиешле, безнең тарафтан яңа карарлар тәкъдим ителүне көткән базар тенденцияләре бар».

Рөстәм Миңнеханов шулай ук РФ Энергетика һәм Сәүдәсәнәгать министрлыкларының 2030 еллар чорына Россиянең газ һәм нефть химиясен үстерү планын актуальләштерү буенча эшләр планлаштыруын искә төшереп үтте. «Документның яңа вариантында эре проектларны гамәлгә ашыручы предприятиеләр өчен салым системасының үзгәрешсезлеге принцибын теркәү планлаштырыла. Бу турыда октябрь ае башында узган Россия энергетика атналыгы мәйданчыкларында әйтелде, – диде ул. – Тискәре эчке факторлар арасында республика эчендә чимал китерү механизмының балансы бозылуын атарга мөмкин. Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: республика эчендә җитештерүчеләрнең, галимнәрнең һәм хакимият органнарының кооперациясен көчәйтми торып, без илдә иң югары позицияләрне саклап кала һәм Евразия икътисадый берлегенә кергән илләр арасында химия җитештерүе өлкәсендә лидер төбәк булуга ирешә алмаячакбыз».

Татарстан Президенты, алда торган максатларга ирешү өчен, нефть-газ химиясе комплексына таянучы һәм аңардан динамик үсеш таләп итүче яңа карарлар һәм продуктлар уйлап табарга кирәклеге турында белдерде.

«Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ генераль директоры Рафинат Яруллин кыскача гына дөнья икътисады һәм нефть-газ химиясе комплексы тармаклары үсешенең мөһим тенденцияләре белән таныштырып үтте. «Татарстанда химия сәнәгате үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, функциональ материаллар, уртача һәм аз тоннажлы химия тармакларын үстерү максатка ярашлы булачак, – дип басым ясады ул. – Евразия икътисадый җәмәгатьчелеге арасында югарыда аталган өлкәләрдә лидерга әверелү республика нефть-газ химиясе комплексын үстерүнең стратегик максаты булып тора. Яңа тармакларны булдыру өчен эре тоннажлы химия продукциясе күләмнәрен һәм ассортиментын киңәйтергә кирәк».

Рафинат Яруллин, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ генераль директоры:
– Дөньяда дәүләтләрнең эчке базарларны чит ил товарларыннан саклауга һәм энергия бәйсезлегенә ирешүгә омтылышы көчәя, нефть продуктларын табигый газ белән алыштыру, альтернатив технологияләргә күчү дәвам итә. Водород энергетикасы үсә бара. Нефть компанияләре үзләрендә эшкәртүне, химия продукцияләрен эшкәртүне үстерә, энергияне генерацияләүгә һәм саклауга акча салулар арта.



БЕЗНЕҢ **ГОРУРЛАНЫРЛЫК** ЭШЛӘРЕБЕЗ БАР

Рөстәм Миңнеханов – киңкүләм бурычлар һәм нәтиҗәле карарлар турында.

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫННАН

Икътисадта һәм социаль өлкәдә уңай тенденцияләр күзәтелә. Тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлгән масштаблы программалар һәм проектлар тормышка ашырыла. Бу икътисадый потенциалга, инвестицияләр җәлеп итүгә, федераль үзәкнең һәм шәхсән илебез Президенты Владимир Владимирович Путинның милли проектларын һәм стратегик инициативаларын тормышка ашыруда актив катнашуга, аларның Татарстанга күрсәткән ярдәменә күрә мөмкин булды.

Гражданнарны социаль әһәмияткә ия булган карарлар кабул итү эшенә тартуда граждан җәмгыяте институтларының роле зур. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга һәм иҗтимагый советларга ярдәм күрсәтү чараларын тагын да арттырырга кирәк.

Республиканың дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын халык катнашуында билгеләүгә юнәлтелгән сынау проектын киңрәк җәелдерү, электрон тавыш бирү системасын үстерү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлеген камилләштерү дәүләтнең һәм җәмгыятьнең үзара тагын да нәтиҗәлерәк хезмәттәшлек итүенә этәргеч бирәчәк.

Тиздән ТАССРның 100 еллык юбилеен бәйрәм итәчәкбез һәм бу вакыйга республика төзелә башлаган елларга, аның героик тарихына һәм хәзерге дәүләтчелегебезгә игътибарыбызны тагын да арттыра. Нәкъ менә шуңа да 2020 ел Татарстанда ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үтү елы дип игълан ителде. Без Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга бу датаны федераль дәрәҗәдә билгеләп үтү турындагы Указы өчен рәхмәтлебез.

Якын арада юбилей чаралары программасы ачылачак. Анда халыкара, федераль дәрәҗәдәге социаль-мәдәни, фәнни проектлар һәм форумнар, тарихи һәм рухи мирасыбызны саклап калуга юнәлтелгән чаралар уздыру каралган. Бу эштә муниципаль берәмлекләребез, предприятиеләр һәм оешмаларыбыз, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук Татарстанның иҗат көчләре катнашачак.

Киләсе елда без Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итәчәкбез. Бу олы вакыйга безнең өчен һәрчак әхлакый һәм рухи маяк булып торды һәм киләчәктә дә шулай булачак, дип ышанып әйтә алам. Илдә Хәтер һәм дан елы дип игълан ителгән киләсе елда бүген дә безнең арабызда булган ветераннарыбызга, шулай ук сугыш һәм хезмәт геройларының истәлеген мәңгеләштерүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк.

Теләсә кайсы илнең һәм милләтнең киләчәге – яшьләр кулында. Җәмгыятьтәге процессларның тагын да катлаулана баруы, егет-кызларның иҗтимагый тормышка аяк басканда хәвефле хәлләргә тару очракларының артуы аерым министрлык төзү турында кабул ителгән карарның дөреслегенә дәлил булып тора. Министрлыкның төп бурычы – яшьләрнең барлык категорияләре белән нәтиҗәле багланышлар урнаштыру

Милләтара һәм динара тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү элеккечә өстенлекле бурычларыбызның берсе булып тора. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясенә гомумфедераль карарларны исәпкә алып кертелгән үзгәрешләр халыкларның милли-мәдәни һәм телләрнең күптөрлелеген саклап калуга, аларның рухи бербөтенлеген ныгытуга юнәлтелгән.

Федераль үзәк белән бергәләп, халыкларның туган телләрен һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләрен

саклап калу һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен уңай шартлар тудыру бурычы һаман да җитди булып кала бирә. Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең күп телләр укытыла торган мәгариф комплекслары челтәре төзү турындагы башлангычы бик мөһим проект булып тора.

Чит илләр эшләре министрлыгы ярдәмендә Татарстан Россия Федерациясенең халыкара хезмәттәшлеген үстерүдә актив катнаша.

«Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме, быел 72 илдән һәм Россиянең 38 төбәгеннән вәкилләр катнашкан KazanSummit форумы кысаларында мөселман илләре белән алып барыла торган эш турында аерым әйтеп узасым килә.

Республика мәнфәгатьләрен үстерүгә этәргеч бирү һәм чит илләргә товарлар чыгаруны арттыру өчен безнең көндәшлекле өстенлегебезне тәшкил иткән ватандашлар белән эшләүдәге мөмкинлекләребездән күбрәк файдаланып, халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне киңәйтүне дәвам итәргә кирәк.

Хакимият органнары эшчәнлегендә кеше капиталын үстерү, халыкның тормышын яхшырту кебек бурычларга өстенлек бирелә. Стратегия-2030 һәм республиканың барлык программалары (узган елдан алар ил Президенты йөкләмәсе нигезендә булдырылган милли проектларны гамәлгә ашыру чаралары белән ныгытылды) шуңа юнәлтелгән.

Биш ел элек бездә 27 программа гамәлдә булса, хәзер аларның саны 40 ка җитте. Бу программаларны тормышка ашыруга республика бюджетыннан быел 40 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелде. Ул яңа торак йортлар, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, поликлиникалар һәм фельдшер-акушерлык пунктлары, спорт мәйданчыклары һәм модульле чаңгы базалары төзүгә һәм аларны төзекләндерүгә тотылды. Җәмәгать урыннары – парклар һәм елга ярлары, урамнар һәм бульварлар, скверлар һәм мәйданнар тамырдан үзгәреш кичерде.

> **Рөстәм Миңнеханов:**
> **– Хакимият органнары эшчәнлегендә кеше капиталын үстерү, халыкның тормышын яхшырту кебек бурычларга өстенлек бирелә. Стратегия-2030 һәм республиканың барлык программалары (узган елдан алар ил Президенты йөкләмәсе нигезендә булдырылган милли проектларны гамәлгә ашыру чаралары белән ныгытылды) шуңа юнәлтелгән.**

Эчә торган чиста су белән тәэмин итү, урамнарны яктырту, авыл клублары төзү һәм аларны капиталь төзекләндерү, яшелчә саклау биналарын, ындыр табагы хуҗалыкларын, машина-трактор паркларын торгызу эшләре шулай ук авылга ярдәм итүгә юнәлтелгән.

Гражданнарның үзсалым акчалары хисабына эшләр башкару программасы кысаларында күмәк ял урыннарын төзекләндерү, елга-күлләрне чистарту, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, зиратларны карап тоту һәм башкалар эшләнә. Уртак финанслау шартларында халыктан җыелган акчаның һәр 1 сумына бюджеттан 4 сум акча бүлеп бирелә. Быел бу максатларга тоту өчен 1 млрд сум каралган.

Моннан тыш республикада транспорт инфраструктурасын үстерүгә, яңа юллар һәм күперләр төзүгә һәм төзекләндерүгә шактый акчалар бүлеп бирелә. Быел гына да бу сумма 32 млрд сумны тәшкил итәчәк.

Татарстан поликлиникаларын яңартып кору буенча киң колачлы программа тәмамланганнан соң, хастаханә комплекслары стационарларын төзекләндерү буенча биш елга исәпләнгән яңа программаны гамәлгә ашыра башлыйбыз.

Быелдан республикада балалар лагерьларын капиталь төзекләндерү, үзгәртеп кору һәм яңаларын төзү буенча «ҖӘЙ – БАЛАЛАРГА» дигән комплекслы программа эшли башлады. 3 ел эчендә республиканың барлык муниципаль берәмлекләрендә 7 млрд сумнан артык суммага 94 объектны яңарту эшләре башкарылырга тиеш.

Җәмәгать урыннарын тагын да уңайлырак итү программасын гамәлгә ашыруны дәвам иттерәбез. Хәзерге вакытта 63 объектта эшләр тәмамланып килә, болар арасында халык яратып йөри торган Казансу елгасы белән Кабан күле яр буйлары да бар. Татарстанның һәрбер районында анда яшәүчеләрнең горурлыгына әйләнгән урыннар бар. Ә иң мөһиме – кешеләр аларны булдыру процессына җәлеп ителгән.

Нәкъ менә шулай, татарстанлылар белән бергәләп, үзенең колачы һәм эш ысуллары ягын-

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫННАН

нан моңа кадәр тиңе булмаган «Безнең ишегалды» дигән программаны гамәлгә ашырырга уйлыйбыз. Гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алып, 3 ел эчендә без республиканың барлык күпфатирлы йортлары ишегалларын кешеләргә уңайлы итәр өчен шартлар булдырачакбыз. Тагын 5980 ишегалды тәртипкә китереләчәк.

Гражданнарыбыз өчен бик әһәмиятле тагын бер тема – торак һәм сатып алу һәркемнең хәленнән килерлек торак белән тәэмин ителгәнлек мәсьәләләре. Аларны, шул исәптән түбән бәядән ипотека алу, социаль арендага торак бирү, шулай ук эконом класска керә торган торак төзү кебек чаралар кулланып, федераль үзәк белән бергәләп хәл итү юлларын табарга кирәк.

Агымдагы елда сәламәтлек саклау өлкәсен милли проектны исәпкә алып финанслау 62 млрд сумнан артып китте. Безнең тарафтан күрелә торган программа чаралары комплексы соңгы 5 ел эчендә, гомерне 2 елга озынайтырга, 74,3 яшь дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкинлек бирде.

Матди-техник базаны ныгыту һәм югары технологияле ярдәм күрсәтүне үстерү белән беррәттән, без медицина ярдәменнән һәркем файдалана алуны тәэмин итү, авыруларны алдан кисәтү юнәлешендә тырышлык куюыбызны арттырырга тиешбез. Биредә диспансерлаштыруга иң зур әһәмият бирелә. Тикшеренүләрне барлык кешеләр узуын тәэмин итү гаять мөһим. Үзәкләрдән ерак урнашкан авылларда яшәүчеләргә аерым игътибар бирергә кирәк.

Гериатрия хезмәтен үстерүне дәвам иттерәчәкбез. «Өлкән буын» дип аталган төбәк проекты кысаларында ике ел эчендә барлык муниципалитетларда махсус кабинетлар ачылачак, ә муниципальара медицина үзәкләрендә гериатрия койкалары булдырылачак.

Инфраструктураның һәм медицина технологияләренең үсеше тармак белән идарә итү системасын камилләштерүне таләп итә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына ел ахырына кадәр дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган медицинаны интеграцияләү буенча юл картасын әзерләп бетерергә кирәк.

Без тагын 4 ябык футбол мәйданчыгы – икене Казанда, берәрне Чаллыда һәм Түбән Камада – төзү турында карар кабул иттек. Аларның һәрберсендә спорт мәктәбе ачылачак.

Күп балалы гаиләләр өчен социаль ярдәм күрсәтү чараларының тулы бер комплексы каралган. Киләсе елдан боларга биш яки аннан күбрәк бала тәрбияләгән гаиләләргә айлык пособие, 3 яше тулмаган балаларга дарулар алу максатына елына 10 мең сумлык электрон сертификат бирү, җан башына исәпләнгән кереме яшәү минимумыннан азрак булган күп балалы гаиләләрне балалар бакчасына түләүдән азат итү кебек ярдәм чаралары өстәргә карар кылдык.

Өч яше тулмаган сабыйларны балалар бакчаларында урын белән тәэмин итү мәсьәләсе актуаль. 4 мең урынга исәпләнгән 22 балалар бакчасы эшли башлады инде, 2 мең урынга исәпләнгән тагын сигезе үз чиратын көтә. Киләсе ике елда тагын 49 яңа балалар бакчасы төзергә ниятлибез.

Уку-укыту өлкәсендәге иң яхшы тәҗрибәләрне гомумиләштерү һәм уртаклашу, педагогларның һөнәри үсешен тәэмин итү, фән укытучыларының методик берләшмәләренә ярдәм күрсәтү кебек эшләрдә муниципаль методика хезмәтләренең ролен арттыру зарур. Шуның белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты эшчәнлегендә мәгариф программаларын һәм технологияләрен үстерүгә игътибарны көчәйтергә кирәк.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте алдында мәгариф, фән һәм җитештерү өлкәләрен системалы рәвештә берләштерү, шулай ук «Фән» милли проекты кысаларында республикада дөньякүләм дәрәҗәдәге Фәнни-мәгариф үзәге булдыру буенча конкрет тәкъдимнәр кертү бурычы тора.

Социаль өлкәдәге бурычларны уңышлы хәл итү һәм татарстанлыларның тормыш сыйфатын тагын да яхшырту өчен ныклы икътисадый нигез таләп ителә. Республика икътисадының төп нигезе булып нефть-газ-химия һәм машина төзү комплекслары тора, аларда киң колачлы инвестицияле проектларны тормышка ашырыла.

«ТАНЕКО» комплексы производстволарын төзүне этаплап тәмамлауга бәйле рәвештә, компания алдында торган стратегик бурыч – үз чималы, нефть һәм газ эшкәртү продукциясе нигезендә яңа перспективалы юнәлеш – газ-нефть химиясе комплексын үстерү. Бу исә углеводород чималын кабаттан эшкәртү һәм компаниянең керемен арттыру мөмкинлеге бирәчәк.

«ТАИФ» компанияләр төркеменең «Түбән Кама Нефтехим»да яңа олефин комплексын төзү, Казанның «Оргсинтез» заводында этилен һәм полимерлар җитештерүне арттыру, шулай ук әлеге предприятиеләрдә генерацияләү объектларын төзү республика өчен әһәмиятле проектлар булып тора.

Елына 55 мең кабина җитештерүгә исәпләнгән автомобиль кабинасы каркаслары производствосын ачу, шулай ук К5 буын автомобильләре линейкасының беренче моделен базарга чыгару – болар

КАМАЗ заводының юбилее елындагы әһәмиятле вакыйгалар. КАМАЗ – Татарстан өчен генә түгел, тулаем бөтен Россия өчен дә машина төзелеше тармагын үстерүдә стратегик әһәмияткә ия булган предприятие. Бүген ул үз алдына яңа амбициоз бурычлар куя.

Граждан билгеләнешендәге, граждан һәм хәрби билгеләнештәге югары технологияле продукция җитештерүдә үз куәтләреннән нәтиҗәле файдалану оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре өчен төп бурычларның берсе булып кала.

«Челтәр компаниясе» һәм «Татэнергосбыт» алдында кулланучыларның йортларында «акыллы» исәпләү приборлары урнаштыруны күздә тоткан электр энергиясен исәпләүнең интеллектуаль системаларын урнаштыру бурычы тора.

Тулаем алганда, система булдыручы предприятиеләребез бүгенге көндә уңышлы үсә. Монда дәүләт ярдәме чараларының роле зур. Соңгы 5 елда федераль программалар кысаларында әлеге максатларга 135 млрд сум акча бүлеп бирелде. Республика үз чиратында 30 млрд сумлык салым ташламалары бирде. Предприятиеләргә әлеге ресурслардан мөмкин булганча нәтиҗәле файдаланырга кирәк.

Республикада гамәлгә ашырыла торган барлык зур проектлар мәҗбүри рәвештә экологик экспертиза узарга тиеш. Каты куллану калдыкларын термик эшкәртү заводы төзү проектына килгәндә, аңа өстәмә рәвештә халыкара экологик экспертиза уздырылачагын әйтергә кирәк.

Бүгенге көндә республикада куәтле инвестицияле инфраструктура төзелде. Әлмәт, Лениногорск һәм Түбән Кама районнарында «АлмА» дип аталган тагын бер МИЗ төзү планлаштырыла. Биш алгарышлы үсеш территориясе, шулай ук «Мастер» Кама индустриаль паркын һәм «Химград» технополисын да кертеп, 90 сәнәгать мәйданчыгы һәм сәнәгать паркы эшли. ТАССРның 100 еллыгына әлеге объектларның санын 100 гә җиткерү планлаштырыла.

Без алга таба да бизнес өчен уңайлы мохит булдыру һәм контроль-күзәтчелек органнары ягыннан басымны киметү буенча чаралар күрәчәкбез. Ришвәтчелек куркынычын киметүгә яхшы этәргеч бирә торган «Ышанычлы бизнес» интернет-ресурсы уңай бәяләнде, ул шулай ук федераль дәрәҗәдә дә танылды.

Электрон сәүдә системаларын актив рәвештә кулланышка кертү товар җитештерүчеләрнең яңа базарларга чыгуы өчен тагын бер этәргеч булып тора. Без республикага әлеге базарда катнашучы OZON һәм Wildberries кебек иң зур компанияләрне җәлеп иттек. Алар Яшел Үзән районында логистика үзәкләрен төзү проектларын тормышка ашыра. Биредә 7 меңгә якын яңа эш урыны булдырылачак. Татарстан товар җитештерүчеләренә үз продукцияләрен әлеге зур компанияләр ярдәмендә сату мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска кирәк.

Быел Татарстан үзен үзе эш белән тәэмин итүче гражданнар өчен яңа салым режимын гамәлгә кертү буенча сынау проектында катнаша.

Безгә киң колачлы мәгълүмат кампаниясе уздыру һәм үзен үзе эш белән тәэмин итүче гражданнарга ярдәм күрсәтү чаралары системасын камилләштерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Тулаем агросәнәгать комплексында нәтиҗәлелеккә ирешү мөһим. Районнарның эш күрсәткечләрендә элеккечә үк зур аерма саклана. Нәтиҗәле эшләүче хуҗалыклар һәм көчле җитәкчеләр тәҗрибәләрен кулланырга кирәк. Алар һәр районда бар.

Бүген республика ил буенча сөт, бәрәңге, ит, ашлык җитештерү юнәлешләрендә алдынгылар сафында. Шул ук вакытта без, логистикага һәм продукцияне сату өчен тәэп-озатуга зур чыгымнар тотып, базарга, башлыча, эшкәртелмәгән продукция чыгарабыз. Авыл хуҗалыгы продукциясен тирәнтен эшкәртүне оештыру элеккечә үк тармак өчен төп бурычларның берсе булып кала.

Хуҗалык итүнең кече формаларын алга таба үстерү, беренче чиратта, продукцияне сату һәм аны эшкәртү мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле. Бу юнәлештә кулланучылар кооперативлары мөһим роль уйный. Республикада аларның саны – 261. Кооперация хәрәкәтен көчәйтү өчен, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм муниципаль район башлыкларының бергә килешеп эшләве таләп ителә.

Дөнья икътисадының төп трендларыннан берсе – цифрлаштыру. Ул дәүләт, иҗтимагый һәм икътисадый үсешләрнең барлык дәрәҗәләрендә яңа мөмкинлекләр ача. Хөкүмәткә дәүләт идарәсе, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә цифрлы технологияләрне һәм платформа чишелешләрен файдалануга кертүне тәэмин итәргә кирәк. Алар гражданнар һәм оешмалар өчен максималь дәрәҗәдә уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән булырга тиеш.

Татарстан Республикасының шанлы тарихы бар. Без үткәнебез белән горурланабыз, алдыбызга олы максатлар куябыз. Зур бурычларны бары тик нәтиҗәле, ныклап уйланылган карарлар нигезендә генә башкарып чыгарга мөмкин. Авырлыклардан курыкмыйча, бары тик алга барырга кирәк!

PRESSA

УМАРТАЧЫНЫҢ БАЛСЫЗ ТОРМЫШЫ

«Күпме хәсрәт кичерде халык. Кортлары үлгәннән соң минем бер танышым хәтта акылга җиңеләйде», – диде Мамадыш районының бер тәҗрибәле умартачысы. Әйе, быелгы җәй умартачылар өчен уңышсыз гына түгел, хәтта фаҗигале килде.

Бал кортларын кышкы йокыга озаткан көннәрдә без умартачылык өлкәсендәге проблемаларны күтәрергә булдык. Чананы – җәйдән, арбаны кыштан әзерлә, ди бит халык.

Автор:
Руфия Фазылова

ЯЗ КҮРСӘТЕР...

Башта умартачылар май, июнь аенда булган салкыннардан курыкты – кортлар тулы куәтләренә эшли алмады. Ләкин моның әле баш бәласе түгеллеге соңрак ачыкланды: республиканың төрле районнарыннан күпләп кортлар үлү турындагы хәбәрләр килә башлады. Хәер, бер Татарстанда гына да түгел, күршеләребез – Башкортостан, Мари Эл һәм Удмуртия республикаларында да шул ук хәл күзәтелде. Киров, Воронеж, Брянск, Ростов өлкәләре дә кушылды... Әлеге фаҗига Россиягә генә түгел, Израиль, Кытай, АКШ кебек чит илләргә дә кагылган икән. Мисал өчен, АКШта соңгы ун ел эчендә бал кортлары 80 процентка кимегән. Белгечләрнең фикере нигездә уртак: кортларны химик ашламалар юк итә. АКШ галимнәре исәпләп чыгарган: бал кортларының үлеме ил икътисадына ел саен 5 миллиард доллар күләмендә зыян китерә һәм, кимендә, 30 процент уңышны алып җиткермәүгә сәбәп булып тора.

Ә бездә хәлләр ничек? Шул хакта ТР Аквакультура һәм умартачылык идарәсе җитәкчесе **Фәиз Динмөхәмматов** белән сөйләштек.

Башта бер ачыклык кертим: без аның белән сентябрь башында ук элемтәгә кергән идек. Актуаль саннарны күтәргә булдык. Тик, кызганычка каршы, октябрь азагы җиткәндә дә конкрет саннар белән танышып булмады. Сәбәбе менә нәрсәдә:

– Рәсми мәгълүматларга караганда, республикада 5 меңнән артык оя корт үлгән, – диде Фәиз Динмөхәмматов. – Тик бу әлегә реаль саннар түгел. Беренчедән, кортлары үлгән бөтен кеше дә идарәгә хәбәр итми. Үзе өчен генә биш, ун оя корт асраучылар күп, аларның баш саны авыл җирлеге идарәсендә дә исәптә тормый. Икенчедән, районнардан үлгән кортлар турында һаман саннар килә тора. Агулы бал бит ояда калырга мөмкин, кортлар шуны ашап та харап була. Быелгы афәттән умартачыларның күпме зыян күргәнен төгәл итеп язга гына әйтеп булачак. Кышлыкка дип сарайларга кертеп куелган умарталарның күпмесе исәнимин язны каршылар, әйтүе авыр. Алдагы еллардагы статистика күрсәткәнчә, көз белән чагыштырганда, язын кортларның баш саны 7 процентка ким була иде. Киләсе язга бу сан 7 процент кына булмаячак, мин моны тәгаен әйтә алам. Төп сәбәбе – көчле оялар үлеп бетте. Күбрәк еракка оча алмаган көчсез оялар калды. Аннан соң, кортларның иммунитетлары какшады, алар төрле авыруларга бирешүчән хәзер...

Бу урында аңлатма бирү кирәктер. Фәиз Динмөхәмматов «Көчле оялар үлеп бетте», дигәндә, республиканың барлык районнарын да күздә тотмый, ә менә афәт килгән төбәкләр турында әйтә. Билгеле булганча, республиканың һәр районында диярлек умарта кортлары һәлак булган. Ләкин Мамадыш, Минзәлә, Зәй, Биектау, Саба районнары иң күп зыян күргән төбәкләр булып санала. Анда да нечкәлек бар: әйтик, Мамадыш районың бер өлешендә кортлар тулысы белән үлеп бетсә, икенче өлешендә исән-имин калган. Бер үк район бит. Сәбәп нәрсәдә?

Мамадыш районының Арташ авылына баргач, умартачылар сөенеп сөйләде:

– Безнең җирлектә эре инвесторлар юк, вак фермерлар гына. Ә алар шул авылда яшәүче гади кешеләр. Шуңа күрә дә рапс утыртмыйлар, ашлама белән сак эш итәләр. Мамадышта җирләре күп булган эре фермер бар. Әлеге җирләргә якын авылларда кортлар үлеп бетте.

Кортлар үлүенең төп сәбәбе – көчле ашламалар сибү, монысы белән берәү дә бәхәсләшми. Ләкин башка сәбәпләр дә бар. Мисал өчен, юкә урманнарының кимүе. Өченчедән, карабодай, кандала үләне (донник) мәйданнары кимегән. Бүген бит һәрнәрсәгә икътисадый яктан карыйбыз. Килосы тугыз сумнан булган бодай үстерергәме, әллә инде килосы егерме биш сум булган рапс чәчәргәме. Фермер, әлбәттә, соңгысын сайлый. Ә рапс ашлама сипмичә үсми. Авыл хуҗалыгы тармагыннан хәбәрдар кешеләр белә: рапс чәчәк аткан чорда вак кортлар барлыкка килә. Рапсны ашламасаң, әлеге корткычлар ашап бетерә. Янәшәдә башка чәчәкләр булса да, кортлар иң беренче булып шау чәчәктә утырган рапска оча. Ә ул нәкъ шул чорда агулы була да.

– Рапсны элек тә чәчкәннәр, – диде ТР Аквакультура һәм умартачылык идарәсе җитәкчесенең урынбасары Нәгим Әюпов. – Тик ул вакытта ашламалар мондый көчле булмаган. Хәзер авылларга да беренче класслы ашламалар кайта. Быел кортларның күпләп үлүе – шуның нәтиҗәсе.

«КОРТЛАРСЫЗ ИГЕН УҢЫШЫ ДА БУЛМЫЙ!»

Үз вакытында Альберт Эйнштейн язып калдырган: «Бал кортлары үлеп бетсә, кешеләр дә дүрт елдан үлеп бетәчәк». Әйе, атаклы физик арттырган, әлбәттә. Арыш, бодай һәм дөге җил белән серкәләнә, ачка үлмибез әле. Әмма бакчада үсә торган 80–90% яшелчә, җиләк-җимешне нәкъ менә бал кортлары серкәләндерә.

Фото: Лилиана Вәлитова

Ә бу организмга кирәкле витаминнар, минераллар, антиоксидантлар дигән сүз. ТР Умартачылар иҗтимагый оешмасы рәисе **Сергей Катков** та иң беренче бал кортларының шушы файдалы ягына игътибар итәргә чакырды:

– Балны ит, сөт житештерү, иген үстерү белән бер бизмәнгә салырга ярамый, – диде ул. – Кортларның функциясе бүтән. Монысы бер. Икенчедән, корт тоту мөгезле эре терлек кадәр чыгымлы эш түгел. Гадәттә, фермерлар иген бәясен, башкасын саный. Ә умартачыларга бу кагылмый. Безнең өчен төп шарт – һава торышының әйбәт булуы, бетте. Димәк, икътисадый яктан караганда, бал кортларын тоту кесәгә сукмый.

Умартачылар җәмгыяте җитәкчесе үзен борчыган проблемалар белән дә уртаклашты. Төп проблема – үзәкләштерелгән бал эшкәртү системасы булмауда икән. Ягъни балы булган фермер (йөзәр, ике йөз баш оя турында сүз бара) аны үзе сатуга урнаштырырга да тиеш. Икенчесе – балга бәя түбән. Ун ел элек тә балның килосы 250 сум булган, бүген дә якынча шул. Моның сәбәбен Сергей Катков менә нәрсәдә күрә:

– Бал сатучылар арасында кортларга шикәр ашаткан фермерлар да, сыйфатлы бал җыйсын, дип, умарта ояларын, бер җирдән икенче җиргә күчереп йөрткән умартачылар да бар. Әлбәттә, беренчеләре бәяне түбән куя. Халык бит аермый, күпчелек очракта, арзангарак алырга тырыша. Республикада бер кило балның уртача базар бәясе 250 сум икән, аны 400 сумга сатып булмый. Ит тә шулай бит: бөтен җирдә килосы якынча 300 сум булганда, минем ит яхшы дип, шундый ук итне фермер 400 сумга сата алмый. Бал очрагында да шул ук хәл.

Дөресен генә әйткәндә, умартачыларга дәүләт тарафыннан бармак аша гына карау бар, – дип дәвам итте ул сүзен. – Мин моны безнең республикада гына димим, гомумән, Россия буенча әйтәм. Мисал өчен, мөгезле эре терлек асраучы, җир эшкәртүче фермерларга дәүләт ярдәм йөзеннән грантлар бирә. Ә безгә – юк. Башка проблемалар да туып тора...

Сергей Катков белән бу сөйләшү сентябрь башында булган иде. Бер айдан соң кулыма документ килеп керде: быел беренче тапкыр умартачыларга 3 миллион сум тирәсе грант бирәчәкләр. Республиканың тугыз районыннан 23 умартачы грантка дәгъва итәчәк. Шуны искәртергә кирәк: бу республика тарихында беренче тапкыр. Моны хөкүмәт умартачыларга йөз белән борыла башлады, дип аңларга кирәктер.

ЕЛЫЙ ИКӘН ИРЛӘР ДӘ...

Бер-бер артлы бал кортлары үлү турында хәбәрләр килә башлагач, халыкта бер сорау туды: кортлары үлгән кешеләргә компенсация булачакмы? Җавап – булырга тиеш, тик барысына да түгел. Фәиз Динмөхәммәтов белән очрашуыбыз да шуның аркасында кичектерелеп килде. Компенсация түләнергә тиешле кешеләрнең исемлеге бар, тик әле ул расланмаган, имзаланмаган.

– Шулай да кортлары үлгәнлекне документлаштырган умартачыларга дәүләт акча бирер дип ышанабыз, – диде Фәиз Динмөхәммәтов.

– Документлаштыру ничек ул? – дидем.

– Беренчедән, кортларның паспорты булу зарур. Авыл җирлеге идарәсендә баш саны исәпкә куелган булырга тиеш. Тагын төп шарт – кортлар үлгәннән соң экспертиза үткәрелү. Кортларга паспорты булган умартачылар да экспертиза үтүдән баш тартты.

> **Сергей Катков, ТР Умартачылар иҗтимагый оешмасы рәисе:**
> – Натураль бал кристаллаша, ә составында шикәр комы булган бал кристаллашмый. Вакыт узса да, ул сыек булып тора.

Аның өчен Казанга үлгән кортларны, балын, ашлама сибелгән кыр туфрагын яки үсемлекне алып барырга кирәк иде. Бу процесс түләүле – якынча 30 мең сум тирәсе. Күпләрне шушы сумма куркытты. Хәер, кешене аңлап та була: фәлән баш кортын да югалткан, тагын акча да түләргә. Әле компенсациянең түләнәчәкме, юкмы икәне дә төгәл билгеле түгел иде. Компенсация бер баш умартага 6 мең сумнан түләнергә тиеш.

Мамадыш районында яшәүче Нурулла абый Гыймазов гомере буе умартачылыкта. Әтисенең 75 яшендә дә 50 баштан артык корт оясы булган. Нурулла абый исә улын, оныкларын өйрәткән. Гыймазовларның язын 300 оя корты булган. Яковка авылындагы 200 баш умарталары бер ай эчендә үлеп беткән.

– Гомерлек шөгыль, карап торган малыбыз иде бит, – диде тәҗрибәле умартачы. – Республикада җитештерелгән бөтен балның 17 процентын әлегә кадәр Мамадыш районы биреп килде. Быел исә бездә – афәт. Аерым авылларга гына кагылмый калды... Бездә бал кортларының «средний русский» төре үрчетелде, ә ул иң яхшыларыннан санала. Башка төр кортлар берьюлы 40 мг бал алып кайтса, безнекеләр 80 мг белән кайта. Көчле бер оя көнгә 15 кг бал алып кайтырга сәләтле.

Нурулла абыйның күңеле сүрелгән. Җитмешкә җитеп килгән умартачы хәтта елап җибәрде.

– Балаларым, оныкларым бу эшне алып барырлар дигән идем. Хәзер алар да кул селтәде, – диде. – Киләсе елга да теге көчле ашламаны сипсәләр, районда бер бал корты да калмаячак.

Гыймазовлар үлгән кортлары өчен дәүләттән компенсация алырга тиеш. Һәрхәлдә, алар экспертиза да узган, исемлеккә дә кергән. Ләкин Нурулла абый моңа әллә ни сөенми:

– Компенсацияне бирсәләр, кортлары үлгән бөтен кеше дә алсын иде. Гаделсезлек бит инде! Кортлар бер үк басуда йөри, димәк, барысы да бер төрле агуланган. Күпме хәсрәт кичерде халык. Кортлары үлгәннән соң, минем бер танышым хәтта акылга җиңеләйде...

– Экспертиза узмаганнар икән бит, – дим.

– Сеңлем, ул вакытта экспертиза кайгысы идемени?! Көн саен егермешәр оя кортың кырылып барганда, кем Казан юлында йөрсен? Безнең балалар барды, мин дә йөрмәгән булыр идем...

...Умартачылык өлкәсендәге проблемаларны өйрәнгәннән соң, Кытай хәленә генә калмасак ярый, дип уйлап куйдым. Әнә бит, кытайлылар хәзер җиләк-җимеш агачларын үзләре таяк белән серкәләндереп йөри. Тагын әле башта тирес түгеп, аннан шуңа чебен җибәреп (!) серкәләндерү ысулын да кулланалар. Безгә мондый «бәхет» тәтемәс дип бик тә ышанасы килә. Умартачылык өлкәсендә килеп туган фаҗигане вакытында туктатырга дәүләтнең көче җитәр, дип өметләник.

Саннар

Узган ел Татарстанда

6,9 тонна

бал җитештерелгән.

Агымдагы елда –

5,3 тонна

Корт ояларының баш исәбе исә узган ел **261 мең 200** булса, быел **245 мең 400** гә калган.

P.S. «Новые известия» газетасы, Россельхознадзор мәгълүматларына таянып бер хәбәр язды: Россиягә алдагы елларны химик ашламалар Европа илләреннән кайткан. Быел исә, бәясе арзанрак булганга, химикатларны Кытайдан кайтарганнар.

ЮЛЛАР: ҖИРДӘ ҺӘМ КҮКТӘ

Август аенда WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык дөнья чемпионатына, дип, Казанга йөз меңләгән кеше килде – транспорт системаларының нинди киеренкелек кичерүен күз алдына китерү авыр түгел. Әмма алар түзеп кенә калмады, ә лаеклы, сыйфатлы эш тә күрсәтте. WorldSkills International* җитәкчелеге чемпионатта барлык транспорт системалары эшенең оештырылуын әнә шул сүзләр белән бәяләде.

Чемпионат вакытында

668 000

пассажирга хезмәт күрсәтелгән

23 000нән артык рейс башкарылган

10 000 гә якын кеше бушлай йөрү хокукыннан файдаланган

Волонтёрлар һәм аккредитацияләнгән затлар Казан шәһәр транспортында һәм «Казан-1 вокзалы –Аэропорт» маршруты буенча шәһәр яны электр поездларында **95 000нән** артык сәфәр кылганнар

Чемпионатта катнашучыларны, журналистларны, волонтёрларны, килүчеләрне йөртү өчен файдаланылган:

206 автобус – туристлар өчен тибындагы

24 автобус – шәһәр өчен тибындагы

59 микроавтобус

99 җиңел автомобиль WorldSkills International делегацияләре һәм җитәкчелеге өчен.

– Кунакларга һәм ярышларда катнашучыларга транспорт хезмәте күрсәтүне оештыруның ни дәрәҗәдә мөһим булуын төгәл һәм анык аңлап, республика транспортчылары һич тел-теш тидермәслек итеп эшләде, шул рәвешле алар үзләренең һөнәри осталыкларын тагын бер кат раслады, – дип саный **Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин.**

– Ленар Ринатович, WorldSkills чемпионаты инде тарихта калды. Ә киләчәктә нәрсә? Әйтик, «Казан» халыкара аэропорты Габдулла Тукай исеме бирелүгә бәйле рәвештә ничек үзгәрәчәк? Хәзер Николай Лемаев исемен йөрткән «Бигеш» халыкара аэропорты да шул исәптән?

– Аэропортлар үзләренә бирелгән исемнәр нигезендә аэровокзал комплексларын үзгәртү юлларын һәм концепцияләрен тәкъдим итте. Сентябрьдә формалаштырылган республика оештыру комитеты әгъзалары бу тәкъдимнәрне җентекләп өйрәнде. Казанда Габдулла Тукайның иҗаты ягына игътибар юнәлтү планлаштырылса, «Бигеш»тә – Татарстанның сәнәгать потенциалына, Кама аръягы төбәгенең аякка басуына һәм үсешенә, аңлашыла ки, бу эштә Николай Лемаевның роленә басым ясала. «Бигеш» аэропортының бизәлешен уйлаганда, химия һәм нефть химиясе фәнен һәм сәнәгатен билгели торган мөһим элементлардан файдалану идеясе тормышка ашырылырга мөмкин.

Оештыру комитеты шулай ук аэропортларны бизәү эшен республиканың төрле категория гражданнарының фикерен исәпкә алып, халыкка ачык рәвештә эш йөртү бурычын да берсүзсез хуплады. Моның өчен архитекторлар, тарихчылар, журналистлар һәм барлык теләүчеләрне җәлеп итеп, фикер алышу оештырылачак. Куркынычсызлык, функциональлек таләпләрен үтәп, республиканың һава капкаларыннан файдалану уңайлылыгын саклаган хәлдә, аларны тагын да истә калырлык итү бу эштә төп бурыч булып тора.

– Якын арада Татарстан аэропортларыннан нинди яңа авиарейслар ачылырга мөмкин?

– Иң мөһим вакыйгаларның берсе – октябрь ахырында Казан һәм Будапешт арасында элемтә урнаштыру булачак. Яңа рейслар атнага ике тапкыр кабатланыр дип көтелә.

Кытай Халык Республикасы төзелүгә 70 ел тулу уңаеннан, 27 октябрьдә Казаннан Харбинга рейслар башлап җибәрә, Екатеринбургта туктап ала торган рейс атнага бер тапкыр ешлыкта булачак. Шулай ук 27 октябрьдә «Бигеш» аэропортыннан Истанбулга очышлар яңадан башлана. Рейслар даими рәвештә башкарылачак. Яңа чартер юнәлешләреннән октябрь ахырында Казаннан Ла Романага (Доминикана Республикасы) очышлар ачылачагын билгеләп үтәргә кирәк. Рейслар 14 көнгә бер тапкыр башкарылачак.

Без әчке авиация базарында үз урыныбызны ныгытуга, шулай ук республика халкы өчен төбәкара авиаочышларның кулай бәясен булдыруга юнәлтелгән сәясәтне дәвам итәбез. Шулай итеп, 27 октябрьдән Екатеринбургта туктап алу шарты белән Казан–Якутск маршруты буенча очышлар башлана. Рейслар атна саен якшәмбе көннәрендә башкарылачак. Көзгекышкы расписание кысаларында яңа маршрут – «Казан–Ханты-Мансийск–Красноярск» юнәлешен ачып җибәрәчәкбез. Самолётлар 2019 елның 27 октябреннән башлап, атнага өч тапкыр очачак.

– Күп кенә татарстанлыларны «Мәскәү–Казан» югары тизлекле магистраленең язмышы кызыксындыра. Проектның киләчәге ничегрәк күзалланганын сөйләсәгез иде.

– Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы әлеге проектны тулысынча хуплый һәм югары тизлекле магистральне Тихоново станциясенә кадәр төзү мөмкинлеген яклый. Бу – Кама агломерациясен (Түбән Кама, Яр Чаллы, Алабуга) тартып тору ноктасы. Әлеге агломерация составына актив үсештәге Кама инновация-җитештерү кластеры, «Алабуга» МИЗ, «Бигеш» халыкара аэропорты, «КАМАЗ» ГАҖ һәм «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ керә.

Хәзерге вакытта «Чабаксар–Казан» югары тизлекле магистраль участогы буенча проектсмета документлары «Россиянең баш дәүләт экспертизасы» федераль автоном учреждениесендә тикшерелә.

Һөнәри бәйрәмебез көнендә барлык хезмәттәшләремә сәламәтлек һәм уңышлар телим! Гомумән алганда, транспорт һәм юл хуҗалыгы – халык хуҗалыгының барлык тармаклары өчен диярлек локомотив булып тора бит. Җирдә дә, күктә дә. Һәм бу факт – безнең үсеш өчен зур этәргеч.

Фото ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыннан алынды

*WorldSkills International – ВорлдСкиллс Интернэшнл.

ГОРУРЛАНЫРЛЫК УҢЫШЛАР БУЛГАНДА

Республикабыз башкаласындагы «2 нче ПАТП» МУП өлешенә Казанда башкарылган пассажир ташуларның 30 проценты туры килә. Хәрәкәт итүче состав «МАЗ» һәм «НефАЗ» маркалы 320 автобустан тора. «2 нче ПАТП» көн саен ташыган пассажирлар саны 220 меңнән артып китә!

Директор **Альберт Мөхәммәтшинның** фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә предприятиене үсешнең яңа сыйфат дәрәҗәсенә чыгарырга мөмкин булды. Ул җитәкчелек иткән еллар эчендә 2нче ПАТП республиканың иң нык һәм икътисадый яктан нәтиҗәле эшләүче предприятиеләренең берсенә әверелде. Альберт Әхәтовичның бүләкләре арасында «РФнең мактаулы автотранспортчысы» һәм «Россия транспортының мактаулы хезмәткәре» күкрәк билгеләре, ТРның атказанган автотранспорт хезмәткәре исеме, ТР Министрлар Кабинетының мактау хаты, Казан башкарма комитетының мактау грамотасы бар.

«2 нче ПАТП»ның 40 елдан артык тарихы бар. Бу тарих көндәлек эшләр һәм бәйрәмнәр, сынаулар һәм җиңүләр, традицияләр һәм инновацияләрне гамәлгә кертүләрне үзенә сыйдырган. Предприятиедә ветераннарны кадерлиләр, бу бик мөһим, чөнки традицияләргә һәм үткәннәргә карата хөрмәт – алга таба уңышлы үсешнең нигезе.

Коллективның күп кенә хезмәткәрләре саллы бүләкләргә, мактаулы исемнәргә, муниципаль, республика һәм Россия дәрәҗәләрендә тапшырылган рәхмәт хатларына ия. Сүз уңаеннан, 2 нче ПАТПның үз музеенда Казанда автотранспорт барлыкка килү тарихы турында сөйләгән уникаль экспонатлар тупланган. Истә калырлык факт – 1989 елда предприятие Россия автомобиль транспорты системасында иң яхшысы дип табыла. Үткәннәрдә генә түгел, бүген дә предприятие саллы казанышларга ирешә. 2 нче ПАТП «Золотая колесница» Бөтенроссия конкурсының «Россиянең җәмәгать пассажир транспорты лидеры» номинациясендә җиңде.

Иң мөһиме: 2 нче ПАТП коллективы һәрвакытта да заман таләпләренә ярашлы үсә. Бу зур әһәмияткә ия, чөнки сүз камиллеккә чикләр булмаган тармак турында бара. Спутниклы навигация системасы да шәһәрнең шундый предприятиеләре арасында беренчеләрдән булып 2 нче ПАТПда урнаштырылды. Хәзерге көннәрдә гамәлгә кертелгән һәм кертелә торган барлык технологияләр пассажирларга ышанычлы һәм куркынычсыз хезмәт күрсәтүгә юнәлдерелгән. Автобуслар техник яктан гына түгел, төрле категория пассажирлар, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен уңайлылык ягыннан да заманча таләпләргә җавап бирәләр. «НефАЗ» һәм «МАЗ» маркалы автобусларга хезмәт күрсәтү буенча сертификация үткән сервис үзәге бар, пыяла-пластик эшләнмәләр һәм автобусларга пыялалар ясау цехы да эшли. Бу исә транспорт чарасын үз вакытында төзәтергә мөмкинлек бирә.

Шулай да иң мөһиме – кеше факторы, әлбәттә. «2 нче ПАТП» МУП җитәкчесе Альберт Мөхәммәтшинның бөтен профессиональ биографиясе дә әлеге предприятие белән бәйләнгән. Нәкъ менә биредә ул үсешнең барлык баскычларын үтә, эксплуатация бүлегендә инженер, автобус йөртүче, автоколонна башлыгы, баш инженер, эксплуатация буенча директор урынбасары булып эшли. Соңгы елларда Казанның үзендә, предприятиедә һәм, гомумән, транспорт сферасында гаять зур үзгәрешләр булды, ләкин 2 нче ПАТПны 2002 елдан бирле җитәкләгән Альберт Әхәтовичның профессиональлеге югары дәрәҗәдә кала бирә.

Хезмәткәрләр лаеклы социаль сәясәтне, җитәкче тарафыннан күрсәтелгән кайгыртучанлыкны күрә-бәяли беләләр һәм ышанычны максималь дәрәҗәдә акларга тырышалар. Баштан ук автобус йөртүчеләр, ремонтчылар, бөтен хезмәт коллективы арасында дисциплинаны ныгыту буенча директор тарафыннан күрелгән чаралар да дөрес кабул ителде. Ә бит дисциплина – нәтиҗәле җитештерүнең аерылгысыз элементы, бигрәк тә автотранспорт өлкәсендә, чөнки сүз сәгать иртәнге дүрттә башланып, төнгә кадәр дәвам иткән авыр хезмәт турында бара. Һава торышы нинди генә булмасын, эсседә дә, салкында да, теләсә кайсы шартларда рейска чыгарга кирәк.

Предприятиедә остазлыкка зур игътибар бирелә, яшьләр намус белән хезмәт куюның нәрсә икәнен аңларга тиеш. Сүз уңаеннан, предприятиедә кадрлар мәсьәләсе шактый уңышлы хәл ителә. Үз вакытында 2 нче ПАТП базасында Казан милли-тикшеренү техник университеты кафедрасы ачылуы да очраклы хәл түгел. 2 нче ПАТПның перспективалы планнары арасында – предприятиедә эшләүчеләрнең торак шартларын яхшырту. Ә хезмәт хакының күләме, озак еллар эшләгәнгә өстәмә түләүләр, хезмәт шартларын яхшырту, квалификацияне даими күтәрү өчен тудырылган шартлар, бергәләп табигатькә чыгулар, экскурсияләр – болар барысы да кадрларны саклауга, аларны туплауга юнәлдерелгән. Хәер, сүз күпләр озак еллар эшли торган коллектив турында бара. 2 нче ПАТПның тату коллективына, казанлыларның өметләрен тулысынча аклап, киләчәктә дә алдынгы урыннарда калуын теләргә генә кала.

Реклама

Фото 2 нче ПАТП матбугат хезмәтеннән алынды

ТИЗ, ИМИН, УҢАЙЛЫ

«Буревестник» ширкәтен транспорт хезмәтләре базары өчен бизнесны үстерү үрнәге дип атарга мөмкин. Кулланышта булган өч автобус белән 2004 елның ноябрендә эшли башлаган предприятие Татарстан Республикасының әйдәп баручы транспорт оешмаларының берсенә әверелә, штатында 250дән артык хезмәткәр һәм йөз илледән артык кыйммәтле, уңайлы автобуслары, микроавтобуслары һәм җиңел автомобильләре булган автопарклы ширкәт дәрәҗәсенә үсә.

БЕЛЕШМӘ

Вячеслав Михайлович Улитин 1963 елның 25 августында Чистай районының Волчья слобода авылында, «Буревестник» совхозында туа. Казанга беренче тапкыр 1980 елда килә. Казан төзелеш техникумын тәмамлап, чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. «Казремстрой» трестында прораб булып эшли, башкарма комитетта хезмәт куя, Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында инженер вазыйфасын башкара, 1989 елдан бирле – пассажир транспорты тармагында.
2002 елда читтән торып Мәскәү юридик институтын тәмамлый, ә ике елдан үз бизнесын башлый.

КЫЮ ҺӘМ ИРЕКЛЕ ОЧЫШТА

2004 елның 4 ноябрендә Вячеслав Улитин нигез салган һәм тәүге адымнарыннан башлап үзе җитәкләгән оешманы республикада гына түгел, ә аннан читтә дә яхшы беләләр. Компания эшчәнлегенең төп юнәлеше – автомобиль транспорты белән шәһәрара, өлкәара һәм халыкара дәрәҗәдә пассажирлар ташу эшен оештыру һәм гамәлгә ашыру.

«Буревестник» ҖЧҖнең транспорт хезмәтләре сыйфатына клиентлар баглаган ышанычны компания җәлеп ителгән шәһәр, республика, федераль һәм дөньякүләм масштабтагы бик күп чаралар; шулай ук «Россия – спорт державасы» Бөтенроссия спорт форумы, яшүсмерләр арасында хоккей буенча дөнья чемпионаты, «Ефәк юл» ралли-марафоны, Бөтендөнья татар конгрессы, Европа реконструкция һәм үсеш банкы форумы һәм башкалар раслый.

«Буревестник»ның башкарган эшләр портфолиосын предприятиенең дөньякүләм масштабтагы спорт ярышларына хезмәт күрсәтүе аеруча бизи. Бу хезмәтләр арасында 2013 елда Казанда узган Бөтендөнья җәйге универсиада, Сочидагы XXII Кышкы Олимпия һәм XI Паралимпия уеннары, 2015 елгы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2016 елгы FIFA Конфедерацияләр Кубогы җирәбәсе тантанасы бар. 2017 елда «Буревестник» ҖЧҖ – FIFA Конфедерациясе кубогына, 2018 елда – футбол буенча дөнья чемпионатына, 2019 елда һөнәри осталык буенча WorldSkills дөнья чемпионатына хезмәт күрсәтә. Әлеге спорт ярышларында пассажирлар ташу югары дәрәҗәдә башкарылды, бу эшнең сыйфаты оештыру комитетлары тарафыннан берничә тапкыр билгеләп үтелде.

Төрле чараларны транспорт белән тәэмин итү эшен оештыруда дәүләт министрлыкларына һәм ведомстволарга ярдәме һәм күрсәткән хезмәтләре өчен «Буревестник» ҖЧҖ күп тапкыр дипломнар һәм дәүләт органнарының рәхмәт хатлары белән бүләкләнде.

Бәйрәмнәр һәм форумнар узмаган вакытта да предприятие тик тормый. «Буревестник» ҖЧҖ автобуслары көн саен 4000 нән артык пассажирны ташый. 2018 елда ширкәт йөрткән пассажирлар саны, 2017 ел белән чагыштырганда, 19% ка арткан. Керемнәр дә 22% ка үскән.

Уңышның сере – шартларның уңай килүендә түгел, ә җитәкче шәхесендә булса кирәк, аның пассажирлар ташу базары конъюнктурасын тотып ала, команда туплап, аны бер йодрык итеп берләштерә, кул астындагы ресурсларны дөрес куллана белүендә.

Бу тармакта эшләп килгән, заказлы сәфәрләрне һәм маршрут буенча пассажирлар ташуны бергә алып барган көндәшләреннән аермалы буларак, предприятие башта ук заказлы нигездә пассажирлар йөртү эшен гамәлгә ашыру һәм оештыру өчен булдырылган.

2000 нче еллар башында ил 1998 елгы дефолттан айный инде, икътисад җанлана, эшлекле һәм дустанә элемтәләр ныгый, пассажирлар ташу тармагының туристлык һәм бизнес юнәлешләре үсеш ала. Бер урыннан икенчесенә илтеп куйган өчен генә түгел, ә уңайлылык һәм куркынычсызлык өчен өстәп

Реклама
Фотолар «Буревестник» ҖЧҖ матбугат хезмәтеннән алынды.

түләргә әзер пассажирлар категориясе дә барлыкка килә.

Вячеслав Улитин исемне үзенең кече Ватаны – туган ягындагы совхозыннан алган. «Буревестник» ширкәте әүвәл биш хезмәткәрдән һәм өч машина йөртүчедән торган. Директорның төгәл хисап белән эш йөртүе нәтиҗәсендә алар алдынгылар исемлегенә эләгә. Элек кулланышта булган Корея автобуслары банк кредиты ярдәмендә сатып алына. Туристлык тармагы өчен эшләнгән бу машиналар кондиционерлар һәм телевизорлар белән җиһазланган, клиентлар аларны шунда ук дөрес бәяли. Үсеш юнәлеше әнә шулай билгеләнә.

Бүген исә «Буревестник» ҖЧҖ хезмәт күрсәтү сыйфаты һәм пассажирлар йөртү күләме буенча рейтингларның беренче баскычларын били.

ГЕЛ ХӘРӘКӘТТӘ

Кайчандыр эшне нульдән башлаган «Буревестник» ҖЧҖ бүген заманча технологик җиһазларга ия куәтле җитештерү-техник базасы белән тәэмин ителгән. Предприятиенең автопаркына бары тик үз ремонт цехларында гына хезмәт күрсәтелә, территориядә юу комплексы һәм ике җитештерү цехы – тимер-эретеп ябыштыру һәм ремонт цехлары бар.

Автобусны парктан чыгарга әзерләү һәм юл йөрү кәгазен рәсмиләштерүдән башлап, туктальшка куелганчыга кадәр, технологик чылбыр автоматлаштырылган идарә итү системасы белән көйләнә. Диспетчерлар, механиклар, эксплуатация һәм финанс хезмәте эшен бердәм программа белән тәэмин итү, автотранспортны нәтиҗәле файдалану һәм эшләтүгә, шулай ук күчмә составны ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү нәтиҗәлелегенә кагылышлы карарлар кабул иткәндә, вакытны янда калдырырга булыша.

Барлык транспорт чараларына да машина йөртүчеләрнең эш вакытын исәпкә алу системасы (тахографлар), видеорегистраторлар, ГЛОНАСС навигация системалары һәм салон эче видеокамералары көйләнгән. Мондый җиһазлар транспорт чарасының урынын онлайн режимда күзәтеп торырга мөмкинлек бирә.

Бизнес үсә, яңа эш урыннары һәм юнәлешләре булдырыла. Әйтик, туристлык хезмәтләренең тулы комплексын булдыру максатыннан, 2013 елда «Буревестник» туристлык компаниясе ачыла. Шул ук «Буревестник» бренды астында Казанда «Южный» автовокзалы уңышлы эшләп килә, анда 25 кеше эш белән тәэмин ителгән. Әлеге автовокзал аша 30дан артык даими маршрут буенча пассажирлар ташу гамәлгә ашырыла. Көн саен 70 тән артык рейс башкарыла, 800 ләп пассажирга хезмәт күрсәтелә. Халык ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү өчен, яңа маршрутлар ачыла. Билетларны онлайн броньлау системасы кертелгән.

Яңа Чишмә халкы мөрәҗәгате белән, бу район үзәгендә төрле юнәлешләр буенча билетлар сату һәм пассажирларны утыртып җибәрү өчен автостанция ачыла.

Компания тарафыннан пассажирлар ташу иминлеген тәэмин итү буенча да зур эш башкарыла. Җитәкче сүзләренә караганда, юл хәрәкәте иминлеге беренче урында тора. Медицина хезмәткәрләре ягыннан көчле контроль оештырылган. Машина йөртүчеләр даими рәвештә профилактик медицина тикшерүе уза. Автомобильнең техник торышы бик каты күзәтелә. Көн саен, маршрутка чыгар алдыннан, комиссия автопаркның күчмә составын тикшерә. Компаниядәге шоферларга даими инструктажлар үткәрелә.

Ә хезмәткәрләр бу компаниядә эшләүләренең кадерен белә. Биредә кадрлар алышынып тормый, чөнки предприятиедә лаеклы хезмәт хакы түләнә, социаль яклау һәм пенсия фондларына кертемнәр тулы күләмдә күчерелә, хезмәткәрләргә өстәмә яллар бирелә. Мохтаҗларына матди ярдәм каралган. Күп кенә эшчеләр төрле курслар үтеп, һөнәри белем дәрәҗәсен дә күтәрә.

Хезмәткәрләрнең балаларына да зур игътибар бирелә: ел саен Яңа ел бүләкләре алына, бәйрәм чаралары, нәниләр өчен җәйге ял оештырыла. Ветераннарны да онытмыйлар: Җиңү бәйрәмендә һәм Өлкәннәр көне уңаеннан аларга матди ярдәм күрсәтелә.

Кредит оешмалары каршындагы зур йөкләмә-бурычларына карамастан, «Буревестник» ҖЧҖ хәйрия юнәлешендә актив эш алып бару өчен акча таба: республикадагы балалар йортларына һәм инвалидлар җәмгыятьләренә ярдәм күрсәтә. Аз керемле гаиләләр Санкт-Петербург, Мәскәү һәм башка шәһәрләргә бушлай экскурсия юлламалары белән бүләкләнә. Предприятие балалар йортларында тәрбияләнгәннәргә, дини оешмаларга, Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә даими булышып тора.

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы Волчья слобода авылында бары тик «Буревестник» ҖЧҖ һәм шәхсән Вячеслав Улитин акчасына гына төзелгән гыйбадәтханә 2015 елның мартында Татарстан епархиясе карамагына тапшырылды.

«Буревестник» транспорт компаниясе алга – пассажирлар ташуның тиз, уңайлы һәм куркынычсыз булган яңа стандартлары юнәлешендә хәрәкәтен дәвам итә.

ТУГАН ШӘҺӘРНЕҢ ЧӘЧӘК АТУЫ ХАКЫНА

Шәһәр автомобиль юллары идарәсе туган Әлмәтенә берничә дистә ел дәвамында ышанычлы хезмәт күрсәтә.

Альберт Халәпов, «Шәһәр автомобиль юллары идарәсе» МУП директоры

Чыннан да, шәһәр урамнарын һәм юлларын, тротуарларны һәм җәмәгать урыннарын, паркларны һәм скверларны төзү, ремонтлау һәм карап тоту, заманча велоинфраструктураны үстерү Әлмәт һәм анда яшәүчеләрнең тормышында гаять зур роль уйный. Бу зоналар беренче чиратта шәһәр мохитен, аның кешеләр һәм бизнес өчен кызыклылыгын формалаштыралар. ШАЮИнең өч йөздән артык хезмәткәре көн саен, калада уңайлылык һәм матурлык тудырып, шәһәрлеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту юнәлешендә эшли.

Предприятиенең төп эшчәнлеге юллар төзелешенә, ватылган юлларны ремонтлауга һәм профилактика ясауга, шулай ук шәһәрне төзекләндерүгә һәм яшелләндерүгә бәйле. Әлеге хезмәт нәтиҗәсендә нефтьчеләр башкаласы РФнең иң төзек шәһәрләренең берсе санала.

Сүз дә юк, боларның барысын да предприятиенең үсешеннән башка күз алдына китереп булмый. Техниканы яңарту, яңа технологияләр кертү хисабына шәһәр ихтыяҗларына хезмәт күрсәтү сыйфаты, башкарыла торган эшләрнең нәтиҗәлелеге

Фотолар «ШАЮИ» МУП матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

арта. 2017 елда яңа асфальт-бетон заводы сатып алынды, ул алдагысына караганда биш мәртәбәгә куәтлерәк, барлык маркадагы һәм типтагы асфальтларны җитештерергә мөмкинлек бирә. Әлеге хыялны җитештерүнең нәтиҗәлерәк итү һәм чыгымнарны кыскарту бәрабәренә тормышка ашырып булды. Бүгенге көндә нәкъ менә җитештерүнең өзлексезлеге асфальт-бетон заводына чыгарыла торган продукциясенең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирә.

Соңгы елларда махсус техника паркы яңартылды. Предприятие юл фрезасы, асфальт салу техникасы, катоклар, төягечләр, газмотор ягулыгында эшли торган комбинацияле юл машиналары – барлыгы 12 данә техника сатып алды. Юл машиналарының мөһим үзенчәлеге акчаны янга калдыруда гына түгел, беренче чиратта, аларның экологик яктан файдалы булуында. Боларга исә бозлавыкка каршы сертификацияләнгән реагентларны гаять төгәл күләмдә бүлеп тарату хисабына ирешелә.

Предприятие үзенең хезмәткәрләренә карата кайгыртучанлык күрсәтергә дә онытмый. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту максатында, эшчеләргә уңайлы булсын өчен, җитештерү корпуслары ремонтлана.

Болар барысы да туган шәһәр иминлеге өчен нәтиҗәле эшли.

Заказчы сыйфатында «Главтатдортранс» ДКУ булган республика программалары, Муниципаль юл фондының җирле программалары, һәм шулай ук «Татнефть» ГАҖ инвестицияләре ярдәмендә ишегалды территорияләре, җирле һәм кварталлар эчендәге үтү юллары, шәхси сектордагы урамнар ремонтлана, урам-юл челтәре норматив халәткә китерелә.

Төзелештә кулланылучы материалларның сыйфаты, һәм шулай ук башкарылучы эшләрнең дәрәҗәсе табигый рәвештә төп факторлар булып тора. Юлларны салганда барлык стандартларга туры килә торган заманча технологияләр һәм материаллар кулланыла. Эш барышында төгәл төзелеш контроле алып барыла. 2016 елдан башлап, юл эшләрен башкару процессына күзәтчелек итүче «Транспроект» бәйсез контроль оешмасы эшләп килә. Эш башында барлык инерт материалларның таләпләргә туры килүенә, паспорт мәгълүматларына контроль үткәрелә, җитештерелә торган асфальт-бетонның һәм җәйгәннән соң асфальт-бетонның сыйфаты тикшерелә.

Нефть төбәге башкаласында велоинфраструктура төзү – шәһәр тарихының аерым бер сәхифәсе. Өч ел эчендә предприятие тарафыннан 100 км дан артык велосипед юлы һәм тротуар салынды, бу Әлмәткә Россиядә велоюл инфраструктурасын үстерүнең дөнья дәрәҗәсендәге тәҗрибәсе кулланылган беренче шәһәргә әверелергә мөмкинлек бирде.

2017 елдан башлап, Шәһәр автомобиль юллары идарәсендә проект төркеме оештырылды, бу предприятиегә проектлаштыру, төзү, реконструкцияләү, төзекләндерүдән алып, юлларны карап тотуга кадәр булган тулы циклны башкарырга ярдәм итте. Бу төзелешнең барлык этапларында сыйфатның югарылыгын һәм килешенеп эшләүнең төгәллеген тәэмин итә.

Шәһәр автомобиль юллары идарәсе – беренче чиратта, кешеләр ул, аларның фидакарь хезмәте Әлмәт шәһәрен көннән-көн заманчарак һәм уңайлырак итә бара. Бу эшләрнең барысын да нефть төбәге башкаласын үстерүгә һәм баетуга гаять зур өлеш кертүче чын профессионаллар командасы гына башкарып чыга ала.

ЭССЕДӘ ДӘ, СУЫКТА ДА – ТРОЛЛЕЙБУСТА

Илдус Мәсләхов, «Әлмәт транспорт идарәсе» МУП директоры вазыйфаларын башкаручы

Татарстанның нефть башкаласында нинди генә һава торышы булмасын, шәһәрдәге барлык пассажирларның яртысыннан күбрәк өлешенә «Әлмәт транспорт идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе хезмәт күрсәтә. Былтыр җир өсте шәһәр электр транспорты 2 253 мең пассажир ташыган.

ЧИШМӘ БАШЫ

Шәһәр электр транспортында пассажирлар ташу тармагының «монополисты» «Әлмәт транспорт идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе (Әлмәттә метро һәм трамвай юк) 2020 елның 31 декабрендә 45 еллыгын билгеләп үтә. Миңлебай газ эшкәртү заводы директоры Х.С.Камаловның, предприятиенең яңа бүлекчәсе буларак, троллейбус хуҗалыгын оештыру турындагы боерыгы әнә шул көндә имзаланган.

1976 елның 13 гыйнварында ук инде завод белән Хастаханә шәһәрчеге арасында беренче троллейбуслар йөри башлый.

Әлбәттә, боларның берсе дә күктән төшми. Генераль подрядчы – «Татнефтестрой» берләшмәсенең 6 нчы Төзелеш-монтаж тресты тарафыннан троллейбус линиясе объектларын төзү буенча зур эш башкарыла, ә контакт челтәре төзелешендә субподряд оешмасы – «Татэлектромонтаж» трестының Әлмәт монтаж идарәсе эшләгән. Элемтә челтәре, депо, тарту подстанцияләре һәм троллейбуслар сатып алуга чыгымнарының төп өлешен Миңлебай газ эшкәртү заводы күтәрә. Шәһәрне электр транспорты белән тәэмин иткән төзелешне башлап җибәрүчеләр дә шул предприятие җитәкчеләре була. Ул чакта хуҗалыкта гомуми озынлыгы 31,5 км булган ике маршрутта 30 машина хезмәт куя, гомуми егәрлеге 3600 кВт булган дүрт тарту электр подстанциясе һәм 50 машиналык депо эшли.

1977 елның июленнән Миңлебай газ эшкәртү заводының троллейбус хуҗалыгы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты һәм ТАССР ТКХ министрлыгы карамагына тапшырыла. Шәһәр үсеше белән троллейбус линияләре дә озыная. 1982 елның декабрендә 7,2 км озынлыктагы «Хастаханә шәһәрчеге – АЗПЭН» маршруты ачыла. 2001 елның ноябрендә 2,9 километрлык яңа линия эшли башлый, ул Хастаханә шәһәрчеген «Радиоприбор» заводы белән тоташтыра, 2002 елның октябрендә 3,9 км лык линия ярдәмендә Хастаханә шәһәрчеге белән 2 нче сәүдә үзәге арасында юл салына.

Кайбер үзгәртеп корулардан соң, 2005 елдан әлеге оешма «Әлмәт транспорт идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе дип атала.

Аның шәһәр тормышы өчен социаль әһәмияте бәяләп бетергесез. Бүген троллейбус маршрутларының саны бишәү, аларның гомуми озынлыгы 55,48 км тәшкил итә.

Предприятие үзенә йөкләнгән бурычларны – пассажирлар ташу эшен намус белән башкара, моны бу тармакның республикакүләм җитәкчелеге дә билгеләп үтә. Мәсәлән, 2014 ел нәтиҗәләре буенча «Әлмәт транспорт идарәсе» МУП «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының транспорт предприятиеләре арасында (хезмәткәрләр саны 500 дән артмаган) хезмәт куркынычсызлыгы буенча иң яхшы оешма» номинациясендә 3 нче урын өчен диплом белән бүләкләнде.

СОСТАВЛАР АЛЫШЫНА ТОРА: ЯҢА ТРАНСПОРТ, ЯҢА КАДРЛАР

Предприятие хезмәткәрләренең инде ике буыны алышынды, техника да яңартыла. Иске ЗиУ троллейбусларын башта шул ук заводның яңа модельләре, соңрак Башкортостаннан УТТЗ машиналары алыштыра.

2013 елда Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты һәм ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы ярдәмендә, күчмә составны яңартуга субсидияләр бирү юлы белән, түбән идәнле 10 троллейбус сатып алына. 2016 елда тагын 5 шундый троллейбус кайтарыла. Ә инде быел Татарстан Президенты ярдәме белән тагын 10 яңа УТТЗ троллейбусы сатып алына. Аларның автоном хәрәкәт итү ераклыгы 50 чакрымга кадәр җитә, мөмкинлекләре чикләнгән пассажирлар йөртү өчен дә җайланганнар. Предприятие балансында коляскадагы инвалидларны йөртү хезмәте күрсәтү өчен күтәртү җайланмасы белән җиһазландырылган социаль такси да бар («Газель – Next»* микроавтобусы).

«Әлмәт транспорт идарәсе» паркын бүген дә, кайчангыдыр кебек, 30 берәмлек күчмә состав тәшкил итә, аларның уртача 25 е көн саен

* Газель–Некст.

Фотолар «Әлмәт транспорт идарәсе» МУП матбугат хезмәтеннән алынды.

Реклама

маршрутка чыгарыла. Әмма хәрәкәт графигы җайга салынганда, аварияләр һәм ватылулар минимумга кадәр киметелгән очракта, алар инде хәзер көн саен 17–18 мең пассажир йөртә.

«Әлмәт транспорт идарәсе»ндә 180 хезмәткәр эшли. Турыдан-туры пассажирлар белән эшләүчеләрдән – 18 кондуктор һәм 50 троллейбус йөртүче, аларның күбесе (95%) – хатын-кызлар. Пассажирлар ташу хезмәте гүзәл затларыбызның нәфис җилкәсенә йөкләнгән. Предприятие 2018 елда үз көче белән 5 кешене укыткан, бу эшне агымдагы елда да дәвам итә. Игъланнар урнаштыра, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгатьләр юллый. Әмма әлегә кадрлар проблемасы кискен тора, пассажирлар ташуны оештыру белән шөгыльләнә торган эксплуатация хезмәте мәсьәләне хәл итеп килә.

«Әлмәт транспорт идарәсе» предприятиесендә гомуми уңышка һич өлеш кертми торган икенчел дәрәҗәле бүлекчәләр юк. Административ-хуҗалык хезмәте, территорияне чистартудан тыш, сак эшен дә тәэмин итә. Күчмә составка, энергия хуҗалыгына һәм технологик җиһазларга ремонтның барлык төрләре дә предприятиенең үзендә башкарыла. Ремонт-механика остаханәсе күчмә составка техник хезмәт күрсәтүнең төрле эшләрен тормышка ашыра: көндәлек тикшерү, график буенча 1 нче һәм 2 нче техник хезмәт күрсәтүләр, планлаштырылмаган, гаризалы һәм агымдагы ремонт. Троллейбусларның хезмәт итү вакытын озайту өчен, капиталь-торгызу эшләре җайга салынган.

Челтәр электр белән тәэмин ителмәсә, хәтта төзек троллейбус та урыныннан кузгалмый. Шуңа күрә баш энергетика хезмәтенең төп бурычы – 55 километрлык (бер тарафка) контакт челтәрен техник яктан дөрес эксплуатацияләү һәм үз вакытында ремонтлау. Шул ук бүлекчә 6–10 кВ алмаш токны даими 600 вольтлыга үзгәртүне тәэмин итә торган 6 тарту подстанциясенә, 6 кВ лы бүлү җайланмасына (депо), 14 км электр чыбыкларына һәм 2 арадаш диспетчерлык пунктына хезмәт күрсәтә. Электр чыбыклары баганаларның һәм кронштейннарның даими юылып, буялып, төзәтелеп торуын да таләп итә. Тарту подстанцияләрен һәм элемтә челтәрен периодик һәм чираттан тыш тикшерү өчен, баш энергетика хезмәте көн саен шәһәрне йөреп чыга. Тарту подстанцияләренең эшләтеп җибәрү җиһазларына ревизия һәм ремонт ясала, элемтә челтәренең өзелгән, зарарланган урыннары төзәтелә, челтәрләрдә көчәнеш дәрәҗәсе һәм фазалар буенча йөкләнеш тикшерелә.

Ә Яңа ел бәйрәме алдыннан энергетика хезмәте ел саен үзәк урамны гирляндалар һәм консольләр белән бизи, 6 троллейбус бәйрәм иллюминациясе белән матурлана.

КИЛӘЧӘККӘ ОПТИМИЗМ БЕЛӘН

Әлмәт шәһәре үсә бара, җир өсте электр транспорты өлеше һаман да зур булган транспорт системасы исә – аның белән бергә үсештә.

Яңа, күптән түгел генә сатып алынган троллейбусларга «эш урыны» билгеләнгән инде – көн тәртибендә Шевченко урамы, Зарипов проспекты һәм Бигәш урамы буйлап ике яңа троллейбус маршруты ачу мәсьәләсе тора.

Шәһәр мәшәкатьләрен кайгырткан предприятие үз хезмәткәрләрен дә онытмый. Өлкән яшьтәге кешеләргә (эшләмәүче пенсионерларга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, сугыш балаларына, инвалидларга) аеруча игътибар бирелә.

2018–2019 нчы елларга коллектив шартнамә нигезендә гамәлдәге хезмәткәрләргә социаль гарантияләрнең барлык төрләре, компенсация һәм ташламалар билгеләнгән. Юбилейларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләр каралган, матди ярдәм күрсәтелә. Персоналның өчтән берен тәшкил иткән яшьләр белән эшләү программасы тормышка ашырыла. Җәйге чорда предприятие территориясендә волейбол мәйданчыгы корыла. Хезмәткәрләрнең ялын тиешле дәрәҗәдә оештыру өчен концертларга, циркка билетлар сатып алына.

Хезмәткәрләрнең балалары өчен бәйрәм чаралары оештырыла, Яңа елга чыршы бәйрәмнәре, бүләкле тамашалар үткәрелә. Беренче сыйныф укучысы көнендә дә кызлар-малайлар бүләксез калмый. Балаларның җәйге ялын оештыру эше дә көйләнгән.

Транспортчылар көненә, Яңа елга, 23 февраль һәм 8 март көннәрендә хезмәткәрләр өчен концертлы бәйрәм кичәләре уздырыла. Ник дигәндә, кем яхшы күңел ача, шуның эше дә күңеллерәк бара, аның күтәренке кәефе пассажирларга да бик җиңел күчә.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Сез һөнәри вазыйфаларыгызны намус белән башкарасыз, шәһәребезнең тормышын Сезнең авыр һәм үтә җаваплы хезмәтегездән башка күз алдына да китереп булмый.

Сабыр-түземлегегез өчен, һөнәргә тугрылыгыгыз өчен рәхмәт. Чын күңелдән имин юллар, яхшы пассажирлар, җиңел сәфәрләр, аварияләрсез, уңышлы һәм тотрыклы эш көннәре, лаеклы хезмәт шартлары һәм юлларда гел яшел ут януын телибез!

Сезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, бәхет һәм гаилә иминлеге насыйп булсын!

PRESSA

www.protatarstan.ru
Поиск...
Подписка!
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
«Исәнмесез!» белән генә чикләнмәсеннәр!
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
23 октября 2019
22 октября 2019
21 октября 2019
Данис Зарипов: Өстенлек – хоккейга
Хоккей йолдызы бездагы һәм «Инстаграм»дагы җиңүләре хакында
Хыял өчен таулар күчерергә кирәкми
Салаватка – кунакка
«Кеше яраткан эшендә эшләсә – бәхет...»
Кече Ватан патриотлары. Габдулла Шамуков бәхетне нәрсәдә күргән
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Арыш ипиен **НИЧЕК** пешерәләр

«Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» программасы **НИЧЕК** эшли

Ак чехлар Югары Осланга **НИЧЕК** эләккән

PRESSA

Халык әйтсә, хак әйтә:
«Кара икмәккә туйгач, ач түгел»
«Пешкән арыш икмәгенең исе –
һәр чәчәктән хуш исле»

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

АРЫШ ИПИЕ – ИҢ КАДЕРЛЕ СЫЙ

Әрмәннәрдә – матнакаш, итальяннарда – чиабатта, Кавказ халыкларында – ләвәш, Һиндстанда – наан, ә бездә – ипи... Әмирхан ага Еники аны «ипекәй» дип атый. Гомумән, классик әсәрләрдә әлеге ризыкка карата шулкадәрле мәдхия җырлана ки, ул заманда ипинең ни дәрәҗәдә кадерле булганын аңлыйсың. Әйе, бүген дә ипи –табын күрке. Тик, ипекәйгә карата мәдхия кылу бетеп бара кебек. Ипи пешерү дә Мөхәммәт Мәһдиев язганча, тәүлекләр буена сузылмый. Эштән кайтканда кибеттән генә сатып алабыз. Ә киштәләрдә аның нинди төре генә юк! Әллә шуңа да безнең буын ипи кадерен аңлап бетерми...

Бүген редакциябез кухнясында чын арыш ипие пешерергә булдык. Урып-җыю тәгәлләнде, көннәр салкынайтты. Ә яңа пешкән кайнар икмәк өйне дә җылыта, табынны дә ямьли...

«БАЛА УЛ – ЗУР ШАТЛЫК»

Кара әле, ипи турында яза башлагач туктап булмый икән. Күңел түрендәге мең хатирә уянып, йөрәкне җилкендерде. Без иписез заманда үсмәсәк тә, аның иң кадерле ризык икәнен аңлый идек. Аны ике көнгә бер ат белән төяп алып кайталар. Исе... урамга башны әйләндергеч, әчкелт бер хуш ис таралган икән, кибеткә таба йөгерергә кирәк – бетүе дә ихтимал. Син килгәнче, кайбер көнне чират су буе була. (Авыл зур, кеше күп). Сатучы, күп вакыт ипине санап кына бирә, гаиләдә дүрт кеше икән, димәк, ике ипи. Әле суынып та бетмәгән җылы икмәкне чүпрәк сумкаңа салып, кош тоткан кебек өйгә элдерәсең. Юлда ук кибән башын кимерә башлыйсың. Кайтып җиткәнче, ике кибән баш та бетеп куя. Әни бу хәлгә бер дә ачуланмый, чөнки ипигә нәкъ менә кибән баш ашар өчен барганлыгыбызны аңлый. Әле абый белән чиратка салабыз. Безнең заманның иң тәмле ризыгы, һичшиксез, кетердәп торган ипи кибәне иде.

Таһировлар гаиләсендәге балаларга да кызыгып карадым. Аларга әниләре әле яңа пешергән ипинең кибән башын кисеп бирде дә, кулларына тоттырды. Кечкенә Хәйдәр тып-тын булды. Бәхетле балалар, икмәк исен тоеп, сәламәт ризык ашап үсәләр, дип уйлап куйдым.

Хуҗабикә Лилия Таһирова – өч бала анасы. Һөнәре буенча югары

Сан

Җир йөзендә көн саен

9 000 000

чамасы ипи ашала.

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Лилиана Вәлитова

ЛИЛИЯ ТАҺИРОВАДАН АРЫШ ИПИЕ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (3 ипи өчен):

1. Оеткы
2. Арыш оны – 600 г
3. Эре бөртекле бодай оны – 300 г
4. Солод – 100 г
5. Камыш шикәре (коңгырт) – 80 г
6. Тоз – 20 г
7. Әнис (тмин) – 20 г
8. Су – 1 л

Оеткы (камыр башы) әзерләү тәртибе:
0,7 литрлы банкада 30 грамм арыш оны белән 30 грамм чиста суны яхшылап болгатканнан соң, капкач белән ябып, бер тәүлеккә суыткычка куясы. 24 сәгать узгач, яңа банкада бүтән камыр ясыйбыз. Моның өчен суыткычтан алынган 15 грамм камырга 30 грамм арыш оны һәм 30 грамм су салып болгатабыз. Әзер камырны бу юлы суыткычта түгел, ә бүлмә температурасында саклыйбыз. (24–26 градус иң яхшысы булып санала). Алдагы көнне суыткычта торган оеткы камырының калган өлеше кирәк булмаячак. Өченче көнне банкадан янә 15 грамм камыр алып, тагын чиста банкага камыр ясала. (Шул ук өлештә: оеткыны 30 грамм арыш оны, 30 грамм су белән кушабыз һәм бутыйбыз). Әзер массаны бүлмә температурасында бер тәүлеккә калдырабыз. Алдагы көнне ясалган камырның калган өлешен янә ташлыйбыз. Шушы тәртиптә 7 көн оеткы ясала. Җиде көннән соң оеткыны суыткычка алып куябыз.

1. Алабыз!

2. Салабыз!

3. Кушабыз!

4. Өстибез!

5. Тозлыйбыз!

6. Салабыз!

7. Бутыйбыз!

8. Кушабыз!

9. Басабыз!

10. Өстибез!

11. Изәбез!

12. Кабарды!

13. Салабыз!

14. Бүләбез!

15. Ясыйбыз!

16. Куябыз!

белемле юрист. Дистә елдан артык суд системасында эшләгәннән соң, бөтенләй икенче юнәлешкә – ипи пешерергә киткән. Мәскәүгә барып, чүпрәсез арыш ипие пешерү курсларында укып кайткан. Бүген ул бу затлы ризыкны сатуга да әзерли. Күптән түгел Үзмәшгульлек программасына кергән. Хәзер ипи саткан акчасының дүрт процентын дәүләт казнасына күчерә.

– Мин закон кушканча яши торган кеше, – диде Лилия. – Бөтен кеше хезмәт хакының күпмедер өлешен дәүләткә калдыра бит. Мин генә искәрмә була алмыйм. Бу сумманы күп дип санамыйм, моны чын күңелдән әйтәм, – диде. Ә эшеннән китүенең төп сәбәбен болай дип аңлатты:

– Мин бик бәхетле әни, өч улыбыз бар: Мансур, Әнвәр, Хәйдәр. Ирем, балалар – минем бөтен байлыгым, шатлыгым. Көне буе эшләп кайтканнан соң, хатын-кызның гаиләсенә вакыты аз кала. Бер бала белән әле ул бик сизелми, ә өч бала булганда аңлыйсың. Шуларны уйлап, Хәйдәргә алты ай чагында эштән документларымны барып алдым. Барысы да шаккатты: «Балаңа өч яшь тулганчы торсын, ашыгыч карар кабул итмә», – диделәр. Тик мин бер карар кабул иткәч, фикеремне үзгәртмим. Ипи пешерү буенча уңышка ирешәчәкмен, Алла боерса. Иң мөһиме – балалар да күз уңында, әниләре пешергән чын ипине ашап үсәләр.

Без килгәндә Лилиянең өч улы да үзе белән иде. Иң олы уллары Мансурга – ун яшь, Әнвәргә – җиде, бәләкәйләре Хәйдәргә – яшь ярым икән. Берсеннән-берсе сөйкемле балалар. Башта бик игътибар итмәгән идек, Әнвәр башкалардан үзгә – балада аутизм диагнозы. Дөрес, ул сөйләшә, хәтта гади мәктәпкә укырга да барган. Тик барыбер эш-гамәлләрендә аның бүтән икәне сизелә.

– Башта безгә аутизм диагнозы куймадылар, – диде ана кеше. – Ләкин ике яшендә үсеш буенча яшьтәшләреннән артта калганын аңладык. Шулай да яхшыга өметләндек, күп шөгыльләндек. Мансур биш яшендә үзлегеннән китаплар укып сөйләде. Ә менә Әнвәр... Нишлисең, ирем белән без бу хәлне кабул иттек инде. Башта бик авыр булды. Әнвәр белән атта йөрибез, тернәкләндерү үзәкләренә барабыз. Шуның өчен дә эштән китүне кулай дип санадым. Әле кечкенәбез дә бар бит. Алай гына да түгел, тагын сабый алып кайтасыбыз килә...

«ВАКЫТ ҺӘМ САБЫРЛЫК КИРӘК»

Башта шуны әйтим: Лилия рецепты буенча ипи пешерү шактый озак вакытны ала. Шуңа күрә дә хуҗабикә мичкә куясы камырны без килгәнче ясап куйган иде. Безгә аңлашылсын өчен, Лилия янә камыр басты. Бактың исә, башта камырның башы кирәк. Аның өчен суыткычта сакланган 10 грамм оеткыны (аны аерым бирдек), чиста банкага алып, шуңа 20 грамм арыш оны белән су салып болгатасы. Һәм банканың капкачын ябып 6 сәгатькә җылы урынга куясы. (Оеткы ике тапкырга артырга тиеш).

Лилия банкада алты сәгать торган, вак күбекләр хасил иткән әзер камыр башын чиста савытка салды да шуңа 180 грамм арыш оны белән 180 грамм су салып камыр басты. Аны янә алты сәгатькә җылы урынга куйды. Тылсымлы кинодагыча, хуҗабикә алты сәгать кабарып торган камырга (әйткәнемчә, алдан әзерләгән) 0,5 литр су, 100 грамм арыш солоды, 80 грамм камыш шикәре, 20 грамм тоз (Лилия Гималайда чыккан алсу төстәге тоз куллана) һәм 20 грамм әнис салып, яхшылап болгатты. Аннан 400 грамм арыш оны салып камыр басты. Камыр әле сыеграк иде. Шуннан хуҗабикә 300 грамм эре бөртекле бодай оны кушып, янә камыр басты. Аннан аны төреп, җылы урынга куйды.

– 3–4 сәгать кабарып торганнан соң, ипи камыры әзер булачак, – диде.

Без исә эш барышының ни дәрәҗәдә озак барганлыгына аптырап, эндәшмичә генә торабыз.

Хуҗабикә елмаеп җибәрде:

– Аның бер авырлыгы да юк, борчылмагыз. Ничек пешерергә кирәк икәнен аңлатам да танышлар: «Юк, кирәк түгел, син пешергәнне генә ашыйбыз», – диләр. Ә чынлыкта,

бер пешереп карасаң, гади икәненә инанасың.

– Эшкә йөргән кеше ипи пешереп ашый алмый икән, – дим.

– Елларда пешереп була. Оеткың булса, камырны кичтән куеп ятасың да, иртән торгач басасың. Ул кабаргач, тәмләткечләр кушып янә бер камыр басасың. Ул кабаргач, форма ясап, мичкә генә тыгасың, бетте. Безнең әбиләр дә шулай ипи пешергән бит. Чүпрәсез ипи пешерер өчен тәүлеккә якын вакыт кирәк, тәртибе шулай. Ләкин ул үз-үзен аклый. Сыйфатлы ипи шулай әзерләнә. Мондый ипи озак саклана. Ә ашкайнату системасы өчен файдасын сөйләп, аңлатып бетереп булмый. Мин сару кайнаудан интегә идем, хәзер бу турыда бөтенләй оныттым.

Лилия табактан өч сәгать элек басып куйган камырын алды. Аны онлы тактага төшерде. Коңгырт төстәге камырны өчкә кисте дә озынча формалар ясады. Моның да сере бар икән:

– Камырның онлы ягы эчкә калырга тиеш түгел, – диде ул. – Югыйсә матур булмый, ипи пешкәч тә, оны күренеп калачак.

Лилия арыш ипиенә көнбагыш, кабак орлыклары да сала икән.

– Кем ничек ярата инде, – диде.

Озынча формалы ипиләрне хуҗабикә 1,5 сәгатькә җылы урынга кабартырга куйды.

– Кабармаса, тәмле булмый, – диде.

Ипине пешерер алдыннан электр мичен 240 градуска кадәр җылытырга кирәк. Шул температурада ул 10 минут пешә. Аннан соң температураны азрак киметеп, 220 градуска калдырасы, аннан соң 30 минут пешерәсе генә кала.

ТҮГӘРӘК БӘХЕТ

Шуны күзәтәм: Лилия искиткеч сабыр, кабаланмый. Балаларның әле берсе, әле икенчесе килеп нидер сорый: ана кеше берсен дә җавапсыз калдырмый. Тормыш иптәше Айрат кайткач, бөтенләй ачылып китте. Бергә гаилә коруларына 14 ел тулган икән.

– Лилия ипи пешерә башлагач кына, «ипи – барысына да баш» дигән әйтемнең асылын аңладым,- диде Айрат. – Мин хәзер ипинең тәмен дә, кадерен дә күбрәк беләм.

Гаилә башлыгы хокук саклау юнәлешендә эшли – подполковник. Аралашыр өчен бик кызыклы кеше. Тарих, нәсел-нисбәтенең чишмә башы белән кызыксына. Өч бүлмәле фатирларының бер бүлмәсен китапханә, эш бүлмәсе итеп ясаган. Түрдә, иң күренә торган җирдә нәсел шәҗәрәсен элеп куйган.

– Казан шәһәренең 2 нче лицей-интернатын тәмамладым, – диде Айрат. – Безнең чорда лицей төрек телен өйрәнүгә йөз тотты. Әллә шуңамы, татарчам бик яхшы түгел иде. Ләкин соңгы елларда максатчан рәвештә татар телен өйрәнәм. Иң кечкенә улыбыз Хәйдәр белән бары татарча гына сөйләшәм, теле татарча ачылсын. Без бит шәһәр балалары, Лилиянең татарчасы бөтенләй начар. Бу мине борчый: кеше туган телен, тамырларын белергә тиеш. Өйдә татарча радио, телевизор карыйбыз, үзара аралашабыз...

«Аллаһы Тәгалә сынауларны күтәрә алган кадәрле генә бирә», – диелгән бер хәдистә. Бер-берсенә сөеп, аңлашып яшәгән ир белән хатынны күргәч, менә шул искә төште. Алар бердәм, бергә атлыйлар.

...Түгәрәк өстәл артында сөйләшеп утырып, вакыт узганын да сизми калганбыз. Өйгә гаҗәеп хуш ис таралды. Тик аңа кадәр без арыш ипиенә май, каймак ягып тамак туйдырган идек. (Хуҗабикә ипине алдан пешереп куйган иде). Ризыкның тәменә килгәндә, чын арыш ипие. Дәү әниләр аны мич төбенә салып пешерә иде.

Лилия мичтән ипиләрне алып, өстәлгә куйды. Әллә арыш ипиенең хуш исе, әллә гаиләдә булган җылы мөнәсәбәт хикмәте: Таһировлар фатиры шәһәрдәге иң җылы, иң нурлысы кебек тоелды.

«Ипи салу... Дөньяда иң игелекле, мәгънәле, иҗади бер эш ул. Ипи салу – хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше. Бу тәүлектә йортта зур, тыныч шатлык, тынлык, тантана. Ипи салган тәүлектә ир белән хатын арасында ызгыш-талаш булмый. Ыбыр-чыбырлы балачага да бу тәүлектә тынып тора. Беләләр: әни ипи сала. Татар халкында әни белән ипи сүзе бергә йөри, аларның мәгънә кондицияләре бертигез. Халык үзенең телен ясаганда ук иң газиз әйберләргә ике яки өч кенә аваз сарыф итеп сүз ясаган. Тел галимнәре шуны беләме икән? Ике яки өч авазлы сүзләр – халкыбызның иң беренче, димәк, иң кадерле сүзләре...

Мөхәммәт Мәһдиев, «Бәхилләшү» повесте

«АЛАРГА ХӘЕР-ДОГАДА...»

«Тәрбиягә алынган бала» төшенчәсе безнең өчен ят түгел. Ә менә «тәрбиягә алынган әби, бабай» дигән сүзләр тормышыбызга чагыштырмача яңа килеп керде. Соңгы очракта күз алдына мескен бер карт яки карчык килә. Кеше гаиләсендә яшәгәч, якыннары баш тарткандыр инде, дип тә уйлап куясың. Ләкин һәр очракта да алай түгел, тормыш күпкырлы, катлаулы. Биектауда Сафиннар гаиләсендә яшәүче Низаметдинова Шәмсеруй әбинең дә язмышы гади генә түгел.



Автор:
Руфия Фазылова

«УЛ БЕЗГӘ ЯТ ТҮГЕЛ»

Баштан ук искә төшереп узыйм: «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» программасы республикада 2017 елның 1 гыйнварыннан эшли башлады. Аның максаты – үзе турында кайгырта алмаган өлкәннәрнең яшәү дәрәҗәсен яхшырту, ягъни гаиләдә, тәрбиядә яшәтү. Биектау район үзәгендә ялгыз карчыкны тәрбиягә алган бердәнбер гаилә – Сафиннар. Телефоннан сөйләшкәндә:

– Программа чыкмаса да, Шәмсеруй әбине үзебездән калдырмаган булыр идек, ул безнең гаилә әгъзасы кебек, – дигән иде Энҗе Сафина.

Шәмсеруй апа Сафиннар белән Биектау районының Казаклар авылында күрше булып яшәгән. Әби аларның өч балаларын карап үстерешкән. Өч ел элек ир белән хатын, Биектауда йорт салып, Казаклардан күченгәндә, әбине дә үзләре белән алганнар.

Иң кызыгы – «Өлкән кешене тәрбиягә алган гаилә» программасы барлыгын беренче булып әби белеп алган.

– Мин газета-журналлар күп укыйм бит, – диде Шәмсеруй әби. – Караучысыз кешеләрне шулай тәрбиягә алган гаиләләргә акча бирәчәкләр икән, дип укыдым. Туктале, мин әйтәм, яшь барган саен үзем генә барыбер яши алмыйм. Илнур белән Энҗе, үз балаларым шикелле, көн дә керәләр. Күршеләрнең үзләренә бу турыда әйткәнче, башта районның социаль яклау бүлегеннән яңа программа турында белештем. Аннары инде Энҗегә әйттем.

– Каршы килмәделәрме? – дим.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Нинди каршы килү? Гомер буе мунчага да чакырдылар, камыр ашы пешерсәләр, хәзер күтәреп керделәр. Бер гаилә кебек инде. Биектауда йорт салганнарын белгәч тә, авылдан китәләр, дип борчылмадым. Алар белән яшәячәгемне күңел сизде, ахрысы...

Шәмсеруй әби генә түгел, Сафиннарның уртанчы, бердәнбер уллары Алмаз да берничә тапкыр: «Әби, борчылма, без сине үзебез белән алып китәбез», – дигән. Юраган юш килә, диләрме әле.

Әби телгә оста, хәтере дә яхшы. Сафиннарның баларын ничек багуы турында кызык итеп сөйләде:

– Энҗе, Алмазны тапкач, эшкә иртә чыкты. Мәктәптә пешекче булып эшли иде. Олы кызы Айсылу белән Алмазны миңа калдыра. Айсылу бик тә кибет-кибет уйнарга яратты. Мин бер тәлинкәләргә ипи турап куям, икенчесенә – конфетлар. Айсылу аларны «сата». Алмаз исә өстәл астындагы тартмада торган сабыннарны ала да, машина юлы ясый. Мин дә шулар янына утырып уйный идем. Кечкенәләре Әдилә генә бик минем кулда үсмәде, абый-апалары зур иде бит инде.

– Бала карашырга үзегезнең әти-әниләрегез юк идеме? – дим Шәмсеруй әбине елмаеп тыңлап утырган Энҗе апага.

– Минем әти-әнием күрше авылда иде, ә каенанам белән каенатам бөтән урамда яшәде. Аларга да баралар иде. Тик Шәмсеруй әби күршедә яшәгәч, бала карау ешрак аңа эләкте. Ул балаларны үзе дә бик яратты. Айсылу белән Алмаз аңа керергә гел атлыгып торды.

Айсылу исә Шәмсеруй әби турында бик җылы бер истәлеге белән бүлеште. Ул сөйләгәндә минем дә хатирәләр яңарды, чөнки без дә нәкъ шулай үстек.

– Шәмсеруй әбине еш ашка чакыралар иде. Безгә ул аны алдан әйтеп куя. Әбинең кайтканын еракка китмичә көтеп торабыз, чөнки безгә пакетыннан тәмтомнар алып бирәчәк. Ураза айларында, ифтардан кайтканда безнең тәрәзәне шакый. Тиз генә киенәбез дә Шәмсеруй әбигә кереп китәбез. Ул аштан кайткан ризыкларны өстәлгә тезеп куя, чәен кайната. Бергәләп чәй эчәбез. И, Шәмсеруй әби белән бәйле вакыйгалар күп инде ул. Җиләккә, чишмәгә бергә йөрдек. Үз әбием кебек ул...

Гаилә башлыгы Илнур абый, уллары Алмаз белән танышып булмады – эштә иделәр. Әби аларны да мактап телгә алды:

– Рәхмәт яусын, эштән кайткач та, иң беренче булып, минем янга киләләр. Киткәндә саубуллашып чыгып китәләр. Мин аларга гел хәер-догада, – диде.

«ҮГИ ӘНИ БЕЛӘН ЯШӘДЕМ»

Шәмсеруй апа кияүдә булмаган, балалары юк. Гаиләдә биш туган үскәннәр. Кызганыч, аларның берсе дә исән түгел икән. Сеңлесенең кызлары Казанның Каравай бистәсендә яши, әби берничә ел аларга кышын барып яшәп кайткан. Тик хәзер китәсе килми:

– Үлеп китсәм, алып кайтырга да бер мәшәкать бит, – диде.

Әбинең яшьлек елларын да искә алдык. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 16 яшь булган. Окоп казу, урман кисү, колхоз эше – барысында да катнашкан. Авыр елларга туры килсә дә, әби яшьлек чорын яратып, сагынып искә ала.

– Безнең гаиләгә сугыш зур югалтулар алып килмәде, – диде Шәмсеруй апа. – Әтинең яше бар иде, сугышка алмадылар. Ике энем кечкенә иде әле. Дөрес, апам фронтка барды, исәнимин кайтты. Әти булгач, ачка да тилмермәдек, бар белгәнебез эш булды. Хәер, ул чорда бөтен кеше эшләде. Ирләре сугыштан кайтмаган хатыннар бик интекте, билгеле. Япа-ялгыз балалар үстерделәр. Мин инде үзем турында әйтмим, ялгызым иске, әти салган йортта гомер иттем. Йорт салыгыз, дип сорап йөрмәдем. Бала-чагам да булмагач... Ә менә тол калган хатын-кызларны хәзер дә кызганып утырам.

Шәмсеруй апаның әтисе туксан икегә кадәр яшәгән. «Мин әтине дә уздырдым», – ди әби. Туганнары берсе дә аның кебек озын гомерле булмаган. Әнисе шактый иртә – алтмыш алты яшендә дөнья куйган. Аннан соң әле әтисе туган тиешле урта яшьтәге хатынга өйләнгән. Шулай итеп Шәмсеруй әби утыз елдан артык үги әни белән яшәгән. Үги әнисен, тәрбияләп, бакый дөньяга озаткан.

– Үги әнинең балалары юк иде, – ди әби. – Шуңа күрә ул безнең тәрбиядә булды. Тормыш бит, гомер иткәндә төрле хәлләргә каласың. Сүзгә дә киләсең. Бервакыт мин Казандагы апаларга ашка җыенам. Нишләп мине дә алып бармыйсың, ди үги әнием. Бар, сүз әйтәмме әллә, дим. Аны алдан хәбәр итәләр, башың бетеп кайтсын шунда, дип калды. Казанга күрше кызы белән киттек. Юл буе еладым. Автобустан төшкәч, колхоз базарына кереп чыктык. Шунда үги әнигә бишмәт алдым. Күрше кызы, аптырап: «Юл буе үги әниеңә үпкәләп елап бардың, хәзер шуңа бишмәт аласыңмы?» – диде. Ачу саклый белмим мин. Ачу саклап йөрсәң, бер туганың, бер күршең белән дә сөйләшмәскә кирәк.

...Әгәр әйтмәгән булсалар, Энҗе апаны Шәмсеруй әбинең кызы дип уйлар идем. Икесе дә тыныч, сабыр. Сер килешү дигәннәре шушыдыр.

– Безгә аның бер авырлыгы юк, – диде саубуллашканда хуҗабикә. – Шәмсеруй әби үз-үзен йөртә, биш вакыт намазын калдырмый. Әле газеталар укып, безгә хәбәрләр җиткерә. Бер генә теләк – гел шулай үз акылында булсын, аягында йөрсен. Әби үзе дә гел шулай дип дога кыла.

«КАРАУЧЫГА ТАЛӘПЛӘР БАР»

Рафаил Гыйниятуллин, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге җитәкчесе:

– 2019 елның 1 октябренә булган мәгълүматлар буенча, 36 муниципаль районда, 37 гаилә өлкән яшьтәге кешеләрне тәрбиягә алган. Бу максатлар өчен республика бюджетыннан ел саен 3,7 млн сум акча бүленә. 2021 елга өлкәннәрне тәрбиягә алучы гаиләләр санын кырыкка җиткерергә планлаштырыла.

Гаиләгә өлкән кешене тәрбиягә алган гражданнарга ай саен 4–8 мең сум күләмендә түләү каралган. Бу сумма өлкән яшьтәге кешенең инвалид булу-булмавына бәйле. Шулай ук тәрбиягә алынган әбинең яки бабайның пенсиясенең дә бер өлеше караучысына күчеп бара. Ә менә өлкән кешенең мөлкәте караучыга күчми, үзе теләсә генә бүләк итеп калдыра ала.

Караучыга куелган аерым таләпләр бар. Мәсәлән, ул өлкән кешенең туганы булмаска һәм яше 60 тан узмаска тиеш. Кандидатның һәм аның гаилә әгъзаларының хөкем ителмәве, билгеле бер чирләр белән авырмавы да зарур. ■

СӘЛАМӘТ АКЫЛ САГЫНДА

Академик В. М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе лаек булган күп кенә бүләкләр арасында «Кече алтын күбәләк» тә бар. Ул кеше күңелен, аның нечкәлеген, йомшаклыгын, яңа тормыш өчен кабат яңару сәләтен гәүдәләндерә. Хастаханә белгечләре авыру токтыкына эләккән һәр «күбәләк»не бик сак һәм оста кайгырта белә.

Фәрит Җиһаншин, «Академик В. М. Бехтерев ис. РКПХ» ДАССУ баш табибы.

В. М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе – Россиядәге иң зур махсуслашкан учреждениеләрнең берсе. Аның 2 мең хезмәткәре тулы бер төбәкнең психик иминлеге өчен җавап бирә. Әлеге хастаханә, Республика психиатрия хезмәтенең оештыру-методик үзәге буларак, үз эченә Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һәм Яшел Үзәндәге филиалларны берләштерә. РКПХ белгечләре көндәлек медицина хезмәтен күрсәтүдән тыш, кризиска дучар булган яки гадәттән тыш хәлдә калган кешеләргә дә ярдәм итә.

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ КИРӘК БУЛГАНДА – «СЕРДӘШ» ТЕЛЕФОНЫ

2011 елның җәйге бер көне республика халкына коточкыч фаҗига алып килә: «Булгария» теплоходы һәлакәте 122 кешенең, шул исәптән 28 баланың, гомерен өзә. Ашыгыч ярдәм хезмәтләренең «кайнар линия» телефоннары бу көннәрдә тынып тормый. «Арабелла» судносы экипажы тарафыннан коткарылган теплоход пассажирлары тирән шок хәлендә була, күпләр үз-үзенә кул салу чигенә җитә.

Зыян күрүчеләрнең психик хәле турында кайгыртуны РКПХның суицидология хезмәте каршында тәүлек буе эшләп килүче «Сердәш 129» психологик ярдәм линиясе белгечләре дә үз өстенә ала. Табибларның авырулар янына барып та, телефон яки онлайн режимда да ярдәм күрсәтергә әзерлеге урынлы була: фаҗигадән соң ул җәйдә мөрәҗәгатьләр бик озак тукталмый әле... Бүген дә РКПХ психологларының мобиль бригадаларда көндәлек хезмәте җиңелләрдән түгел. Гадәттән тыш хәлләр булганда нәкъ менә алар беренчеләрдән булып ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен вакыйга урыннарына килә. «Боинг-737» һәлакәтендә, «Адмирал» сәүдә үзәгендәге янгында, Зәйдәге автобус катнашындагы авариядә һәлак булганнарның туганнары белән дә аларга эшләргә туры килә...

АҢСЫЗЛЫККА БЕР АДЫМ КАЛГАНДА

«Сердәш 129» хезмәтенең төп бурычы – мохтаҗ булган һәркемгә психологик-психиатрия ярдәмен күрсәтү. Суицид очракларын профилактикалауга зур игътибар бирелә. Бу юнәлештә хезмәт белгечләре сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль яклау оешмалары, Эчке эшләр органнары вәкилләре белән тыгыз элемтәдә тора, республиканың Яшьләр эшләре министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм башка ведомстволар белән уртак программаларны тормышка ашыра. Бу эшнең нәтиҗәләре дә күренә: соңгы 5 елда үз-үзләренә кул салу очраклары өлкәннәр арасында – 48 процентка (2013 елда – 17,7 очрак / 2018 елда – 9,6 очрак) *; балигъ булмаганнар арасында 62 процентка (2013 елда – 1,3 / 2018 елда – 0,49 очрак) ** кимегән. Төбәктә суицид сәбәпле үлем очраклары Идел буе федераль округындагы күрсәткечләр белән чагыштырганда түбәнрәк. Хастаханә җитәкчелеге белгечләргә нәтиҗәле эш өчен кирәкле шартлар булуын һәрдаим кайгыртып тора.

* 100 мең кешегә. ** 100 мең кешегә.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

САВЫГУ ӨЧЕН УҢАЙЛЫ ШАРТЛАР

РКПХ өчен төп ориентир – авыруларның ихтыяҗларына җавап бирү. Бередә инде берничә ел медицина ярдәмен күрсәтү комплекслы башкарыла. Функциональ диагностика бүлеге, рентгенография, УЗИ, физиотерапия кабинетлары һәм башкалар эшли. Пациентларны көн саен тәҗрибәле стоматологлар, терапевтлар, хирурглар, неврологлар, гинекологлар һәм башка белгечләр кабул итә. Күптән түгел хастаханәдә стационар хезмәт күрсәтүгә өстенлек бирелә башлады, моның өчен тәүлек буе эшли торган 600 койка үзгәртеп корылды, көндезге стационар һәм өйдәге стационарлар саны арттырылды, шул ук вакытта белгечләрнең штат саны сакланып калды. Әлеге үзгәрешләр күрсәтелә торган медицина хезмәтенең уңайлылык дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек биргән. Нәтиҗәдә, хастахәнә госпиталь үлем очракларын 2009 елдагы 2,1 күрсәткеченнән 2018 елда 0,3 очракка кадәр киметә алды.

ПАЛЛИАТИВ ЯРДӘМ

РКПХ илебезнең психиатрия тарихында 100 кешегә паллиатив ярдәм күрсәтергә сәләтле ике бүлек ачылган беренче хастаханә булды. Табиб-психиатрлар һәм профильле белгечләр пациентка медицина социаль-психологик реабилитация үткәрә һәм аның хәлен күзәтеп тора, туганнары өчен консультацияләр һәм белем бирү семинарлары уздыра. Деменциянең төрле формаларыннан, шул исәптән терминаль стадиясендәге Альцгеймер авыруыннан да интегүче пациентларга мондый шартлар җиңеллек бирә, аларның якыннарына да уңай тәэсир итә.

ПСИХЕЯНЫҢ КАЙТУ

Катлаулы авырулар, пациентлар һәм аларның туганнарының газапларын күреп, үз-үзләренә һәм якыннарына караганда да күбрәк көч һәм энергияне эшләренә бирүче табибларга үз тормышларын һәм эшләрен якты, күңелле мизгелләр белән бизәргә кирәк. Бервакыт баш табиб Фәрит Җиһаншин хезмәттәшләре өчен тылсымлы бәйрәм ясарга карар кыла. Шулай итеп, «Бехтерев балы» – XIX гасыр биюләре һәм атмосферасы белән костюмлаштырылган бал оештырыла. Хәзер бу чараны үткәрү гадәтән тыш матур гадәткә әйләнгән, елга бер тапкыр борынгы йорт паркы яктылык, шатлык, музыка белән тула.

2019 елда, Татарстан психиатрия хезмәтенең 150 еллыгы хөрмәтенә, паркта борынгы грек мифологиясендә җанны гәүдәләндерүче Психеяга багышлап, нәфис скульптура урнаштырыла. Мәрмәр сынның карашы хыялый, иңнәренә кечкенә күбәләк канатлары ясалган... Психея куелган ташка хастаханәнең барлык җитәкчеләре, профессионаллар, гуманистлар, тикшеренүчеләр һәм галимнәрнең исемнәре язылган. Аларның барысы да тормышларын кеше күңелләрен дәвалауга багышлаган.

Гаять зур практик тәҗрибәләрен РКПХ табиблары яшь белгечләргә тапшыра. Учреждение базасында КДМУ, КДМА һәм КФУның 6 клиник кафедрасы эшли, аларда ел саен 700 дән артык студент, интерн, ординатор әзерлек үтә, ә Россиянең төрле регионнарыннан 500 дән артык табиб белемнәрен камилләштерү курсларын уза.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Реклама Фотолар Республика клиник психиатрия хастаханәсеннән алынды

PRESSA

101 ЕЛ ҮТКӘЧ

Сентябрьнең төксе бер көне. Югары Осланда, һаваны ярып, яу гөрелтесе ишетелә. Мылтыкларның кыска гына тонык шартлавы, пулеметларның усал тыкылдавы, артиллериянең кытыршы залплары. Яу кырында, Соколка тавының иң биек ноктасында кызыллар белән аклар кушылган. Кемнең кайда икәнен аңлавы кыен, аларны аера торган билгеләр ерактан күренми. Кайчандыр бу солдатларның күбесе бер армиядә булган, ә бүген алар окопларның төрле ягында, соңгы тамчы канга кадәр сугышырга әзер...

PRESSA

Автор:
Ксения Сёмина

ТАГЫН ҖИҢҮ!

Урманнан кинәт кенә килеп чыккан ак кавалериянең башлыгы: «Һөҗүмгә!» – дип кычкыра. Әмма кылычлар мылтыкларга каршы торырлык түгел. Җайдаклар яу кыры аша үтәләр дә урманга кереп качалар.

Кызыллар һөҗүм итә: Чехословакия корпусы яугирләре, казаклар һәм Каппель армиясенең җәяүле гаскәриләре окопларда посып ятарга мәҗбүр, алар хәлдән тайган, ярдәм көтәр җир дә юк. Кызылларның исә, киресенчә: Идел хәрби флотилиясенең ике кораб матрослары Соколкага марш-бросок ясап, кызыл отрядларга килеп кушыла һәм һөҗүм итәр өчен теләсә кайсы мөмкинлектән файдалана. 5 нче армиянең һәрбер кызылармиячесе иптәш Троцкийның вәгъдәсе турында ишетеп белә: «Кем кача – һәркайсын атып үтерәм». Димәк, алга гына йөгерәсе.

Озакламый аклар камалышта кала. Соңгылардан булып, оборонаны казаклар тотып тора, әмма бу каршылык та сүнә бара.

Алып баручы: «Югары Ослан кызыллар кулында!» – дип игълан итә. Кыр өстендә тамашачыларның шатлыклы итеп «ура!» кычкырганы ишетелә, кемдер «молодцы!» дип куя, Идел буеның «яуда» катнашкан реконструкторлык клублары хөрмәтенә алкышлар бүләк итеп, тамашачылар әкренләп таралыша башлый.

Әлеге алышны реконструкцияләү буенча төп оештыручы булып, Татарстан Милли музееның фәнни реконструкция бүлеге мөдире Владислав Хабаров җитәкчелегендә Казанның «Витязь» хәрби-тарихи клубы чыгыш ясады. Яңадан торгызу өчен 1918 елның 7 сентябрендәге Соколка тавы түбәсендәге алыш Гражданнар сугышындагы төп вакыйгаларның берсе булганга сайлап алынган.

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫНА КАЗАН АЧКЫЧЫ БЕЛӘН

1918 елның августында акгвардиячеләр гаскәре подполковник Каппель җитәкчелегендәге Чехословакия корпусы һәм Халык армиясе флотилиясе белән берлектә Казанны ала. Каппельнең телеграммасында: «Алган трофейларның исәбе-саны юк, Россиянең 600 миллионлык алтын запасы алынды» дип язылган була. Акгвардиячеләрнең Мәскәүгә юлын Зөя шәһәрен тотып торучы кызыллар отряды гына бүлеп тора.

Зөядәге вазгыятьне коткару өчен хәрби диңгез флоты буенча халык комиссары Лев Троцкий килә. РККАның Көнчыгыш фронтын Зөя янына күчереп, ул каты кулы белән яулардан арып, йончыган солдатлардан алга таба акгвардиячеләрне җимерелгән Россия империясенең сәяси мәйданыннан чит илгә куган Кызыл армиянең нигезен чүки башлый.

Ләкин әле 1918 елның августында моңа ерак була әле. Каппельчеләр «Азат Россия» бронепоездын алып, аны юк итеп, кыю маневр ясый. Контрһөҗүм ясауны озакка сузарга ярамый. 5 сентябрьдә кызыллар акларның РККА көчләренә Казанга якын килергә комачаулап, Югары Ослан янындагы Соколка яссы таулыгында Идел фарватерын контрольдә тоткан артиллериясенә һөҗүм итә. Алыш өч көн дәвам итә. Бу Казан янындагы иң масштаблы хәрби каршылыкларның берсе була. Идел хәрби флотилиясенең кораблары Соколкадагы батареяне утка тота, шул ук вакытта үзенә дә акларның «Лагерь» станциясе тирәсендә торган бронепоездан җавап утына каршы торырга туры килә. 6 сентябрьдә Югары Ослан РККАның 20 аэропланыннан берьюлы бомбага тотыла. Шушы ук төнне Соколкага якын бер җирдә Идел хәрби флотилиясенең кызыл корабларыннан десант килеп төшә, шулар ярдәме белән 7 сентябрьдә акгвардиячеләрнең батареясы алына. 10 сентябрьдә кызыллар Казанны ала.

> «...Биш тулып ярты сәгатьләп вакыт узгач, таң белән, авыр кыймылдаучы, күпкатлы теплоходлар миноносецлар сагы астында Казан пристаньнарына төште... Ә бит гигант кыяфәтле кораб тавыш-тынсыз гына йөзеп килгән ул упкын әле кичә генә актарып ташланган һәм коточкыч тизлектә агучы корыч белән сөреп чыгылган иде... Атыштылар, снарядлар яңгырыннан качтылар, кире кайтып, палубаны каннан чистарттылар, ә хәзер тып-тыныч, Идел дә мең ел элек ничек акса, шулай агып ята, тагын йөз еллар шулай агачак әле... Томан, кешеләр суыктан һәм киеренкелектән калтырана, машина мае, аркан сумаласы исләре килә. Корал-пушка янындагы наводчикның зәңгәр якасы гаҗәпләнеп, аслыгында әйләнә-әйләнә кешесез, кабер тынлыгы белән ял итеп яткан ярны күзәтә. Бу – җиңү».
>
> ***Лариса Рейснер,***
> *«Пролетарская революция» журналы, 1923 ел.*

ТЕЛӘСӘ НИНДИ ХӘЛДӘ ДӘ ТӨГӘЛЛЕК **ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК**

Сентябрьдә «Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» генераль директорының беренче урынбасары Олег Кузьминга «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелде. Предприятиенең иң төп белгечләреннән берсенә әйләнер өчен, аның үз һөнәре буенча җитди тәҗрибәсе дә, кирәкле белеме дә хәттин ашкан.

«Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» коллективы **Олег Анатольевич Кузьминны** «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелүе белән тәбрик итә һәм аңа күңел күтәренкелеге, яңа идеялар, гаилә бәхете тели:

– Хөрмәтле Олег Анатольевич, безнең предприятиенең уңышларында Сезнең өлешегез бик зур, тырышлыгыгыз чиксез!

Үзенең хезмәт юлын ул моннан кырык елдан артыграк элек «Татсантехмонтаж» трестының төзелеш монтаж идарәсендә 2 нче разрядлы слесарь-монтажчы булып башлаган. Казанда туган, Приморье краенда Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайткан егет С.М.Киров исемендәге химия-технология институтын тәмамлый. Аннары Казахстанга җибәрелә, туган ягына әйләнеп кайткач, Казанда һәм Түбән Камада төрле вазыйфаларда эшли. 2014 елдан бирле Олег Анатольевич – «Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» генераль директорының беренче урынбасары.

Кузьмин предприятие базасында эретеп-ябыштыру лабораториясе оештыруда турыдан-туры катнаша. Бүген, инде биш ел эшләү дәверендә, лабораториядә 9,2 меңләп эретеп-ябыштыру ялганмасы ясалган. Шул вакытта ук предприятие базасында аена 100 тонна җитештерү куәтенә ия изоляцияләү цехы да төзелә. Компаниядәге цех объектларны комплекслап, чит оешмаларны җәлеп итмичә төзү мөмкинлеген бирә. Бу – Түбән Кама монтажчыларының көндәшләреннән бәхәссез өстенлеге. Олег Кузьмин җитәкчелегендә оештырылган электр лабораториясе исә шәхси саклану чараларын, электр җиһазларын нәтиҗәле сынау, электр кабельле продукцияне изоляцияләү каршылыгын үлчәү мөмкинлеген бирә. Кирәк булганда, лаборатория белгечләре объектларга да бара.

Бүген «Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» заказлары портфелендә «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «ТАИФ-НК» АҖ, «Татнефтегазпереработка» Идарәсе объектлары өчен җиһазларны, технологик торбаүткәргечләрне һәм металл конструкцияләрне монтажлау буенча җитди хезмәтләр бар. Түбән Кама монтажчылары башкарган күп хезмәт бик шәп булуы белән аерылып тора. Соңгы ике елда гына да 4948 тонна металл конструкция монтажланган. 141 418 метр озынлыктагы технологик торбаүткәргеч монтажланган һәм файдалануга тапшырылган.

Җитештерү мәсьәләләре, туктаусыз яңа идеяләр эзләү һәм тагын да камилрәк технологияләр эшләү артыннан куып, биредә иң мөһим нәрсә – үз хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләре өчен социаль җаваплылык турында да онытмыйлар.

Хезмәткәрләргә вакытында лаеклы эш хакы түләү, аларны шәхси саклану чаралары, кирәкле махсус техника, вахта автобуслары белән тәэмин итү генә түгел, идарәче компания эшчеләрен тулай торакка урнаштыру кебек мәсьәләләр дә биредә оператив хәл ителә.

Идарәче компания, шәһәрне төзекләндерү буенча күпләгән чараларга үз өлешен кертеп, Түбән Кама тормышында актив катнаша. Иҗтимагый, спорт, хәйрия фондларына, ярдәмгә мохтаҗ аерым кешеләргә булыша, төнге лигада уйнаган «ТНХМ» хоккей командасының иганәчесе булып тора.

Бүген республиканың нефть химиясе һәм нефть эшкәртү комплекслары объектларында капиталь ремонт үткәрүнең, аларны реконструкцияләүнең, төзелеш алып баруның һәрвакытта да бик югары дәрәҗәдә оештырылуы «Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясенең» фирма стиле булып тора. Аеруча куркыныч объектлардагы хезмәте өчен компаниянең һөнәри җаваплылыгы – Татарстанның нефть химиясе һәм нефть эшкәртү сәнәгате үсешенә керткән зур өлеше ул. Һәм монда Олег Кузьминның да хезмәте шактый кергән, дип әйтү гадель булыр.

«ТНХМ» ИК» ҖЧШ генераль директоры Сергей Зотов үзенең беренче урынбасарын искиткеч профессионалга саный:

– Олег Анатольевичның эрудициясе, принципиальлеге, аның фикердәшләр командасы булдыру һәм коллективта дустанә мохит урнаштыру осталыгы зур хөрмәткә лаек. Теләсә нинди хәлдә дә аның өчен иң мөһиме – куелган бурычларның төгәллеге, җаваплылык, катгый дисциплина һәм кешелеклелек.

УПРАВЛЯЮЩАЯ КОМПАНИЯ ТНХМ ТАТНЕФТЕХИММОНТАЖ

Фото «ТНХМ» ИК» матбугат хезмәтеннән алынды.

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Совет Татариясе 60 нчы елларда **НИЧЕК** яшәде

Никита Хрущев **КАЙЧАН** ТАССРга килде

Американы юкка чыгарырлык самолётлар **КАЙДА** җыела

Казан циркы **НИ ӨЧЕН** СССРда беренче була

БУЫННАР

«Татарстан» журналының махсус проекты

Киләсе елга Татарстан Республикасы төзелүгә 100 ел булачак. Түгәрәк һәм мөһим юбилей – гасыр гына түгел, тулы бер тарихи дәвер! Шул ук 2020 елда 100 еллыгын билгеләп үтәчәк «Татарстан» журналы уртак юбилей хөрмәтенә «Буыннар» проектын эшли. Без анда Татарстаныбыз тарихында эз калдырган шәхесләр, вакыйгалар, күренешләр турында сөйлибез. Бүген без 60 нчы еллар буынын – бөтен ил белән бергә беренче космонавтларны галәмгә озатучыларны, Камада нефть химиясе комплексын һәм Түбән Кама ГЭСын төзүчеләрне, хәрабәләрдән беренче Казан «хрущёвка»ларына күчүчеләрне һәм, һава торышы көйсезлекләренә һәм югарыдан төшкән мәгънәсез карарларга карамастан, икмәк үстерүчеләрне – искә алырбыз.

ГАЛӘМГӘ АТЛАУЧЫЛАР БУЫНЫ

60 нчы елларда совет Татариясе ничек яшәгән соң? Казанны бизәп торачак биналарны кемнәр төзегән? Нефть химиясе гиганты ничек башланган? Американы юкка чыгарырга сәләтле самолётлар кайда туган?

1 НЧЕ ТАРИХ
ЗУР ХИМИЯНЕҢ ЧАНА ПОЕЗДЫ
Түбән Кама шулай башланган

2 НЧЕ ТАРИХ
ИСӘНМЕ ҺӘМ САУ БУЛ
Никита Хрущёв ничек ТАССРга килгән

3 НЧЕ ТАРИХ
ТИЗРӘК, ЮГАРЫРАК, КӨЧЛЕРӘК
Авиапром – «дәүләт эчендә дәүләт» рулендә кем торган

4 НЧЕ ТАРИХ
БӘХЕТ БЕЛӘН ТУЛЫ ЙОРТЛАР
«Хрущёвка»ларда беренче өй туйлары

5 НЧЕ ТАРИХ
«ОЧА ТОРГАН ТӘЛИНКӘ»НЕҢ ДЕБЮТЫ
Казан циркы ни өчен СССРда беренче булган

ХРОНОГРАФ





1960

- Чаллы районының Афанас авылы янына булачак нефтехимия комплексын һәм шәһәрне төзүчеләрнең беренче чана-трактор поезды килеп җитте

1961

- Яшел Үзәндә «метеорлар» – су асты канатлары булган югары тизлекле теплоходлар төзи башладылар

1962

- Беренче тапкыр Мәскәү тапшыруларын трансляцияләделәр

1963

- Казанда Планетарий ачылды. Аны Петропавловск соборының Түбән Сретение храмында урнаштырдылар
- Яр Чаллы янында Түбән Кама ГЭС төзелә башлады
- «Оргсинтез» заводы гамәлдә булганнар сафына кушылды

1965

- Казанда Ми-8 вертолётлары чыгарыла башлады

1966

- Казанда Ил-62 самолётларын сериялә чыгару башланды
- Казанда Беренче май мәйданында герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды

1967

- ТАССРның Дәүләт симфоник оркестры төзелде
- «Түбән Кама Нефтехим» комбинатында беренче продукция чыгарылды
- Казан консерваториясендә концерт залы ачылды
- Казан циркының яңа бинасында беренче тамашалар күрсәтелде

1969

- «Түбән Кама Нефтехим» комбинаты сафка бастырылды
- Яр Чаллыда автомобиль заводлары комплексын төзү турында карар кабул ителде
- Казан авиация заводында Ту-22М стратегик бомбардировщикларын сериялэп чыгару башланды

1960 нчы еллар

КЫЮЛЫК ҺӘМ МӘХӘББӘТ БЕЛӘН ТӨЗЕЛГӘН КАЛА

«Мы счастливее очень многих
И, пожалуй, богов сильней:
Если землю творили боги,
Мы творим города на ней...» –

Александра Пахмутова һәм Николай Добронравов әлеге җырны 1960 елда бөтен илдән ТАССРның комсомол төзелешенә юл тоткан яшьләрнең омтылышы белән рухланып иҗат иткән. «Татарстан» хәбәрчеләре «Түбән Кама» исемле урын өчен кайчандыр тормышын яңабаштан башларга курыкмаган кешеләр белән очрашты.

– «Без кая эләктек? Йа Хода, бу бит узган гасыр!» – отрядыбыз билгеләнгән урынга килгәч, мине шундый уйлар биләп алды. Тирәякта кечкенә вагоннар гына тырпаеп тора, ә калганы – кар каплаган басу-кырлар… Электр да, эчәргә яраклы су да, радио да, телевидение дә юк. Без әллә кайда еракта, тайгада кебек идек, – дип искә ала Рафаил Глянц. 1961 елның гыйнварында ул Түбән Кама төзелешенә эшчеләрнең һәм белгечләрнең иженче дулкыны белән килә. Татарстанның нефть эшкәртү сәнәгате үзеге төзелеше узган гасырның 60 нчы елларында әнә шулай шып-шыр буш кырда һәм хәзерге заман өчен гаҗәеп, акылдан язарлык энтузиазм белән башлана.

Автор:
Олеся
Бондаревская

Проект идеясе яхшы аңлашыла: 50 нче елларда ТАССРда нефть ятмаларын, шул исәптән, илдәге иң зурларның берсе булган Ромашкино ятмасын үзләштерү дә, тулы куәтенә бара. Ә республикада аңа кадәр нефть эшкәртү сәнәгате, нефть химиясе бөтенләй юк иде. 1958 елда СССР Министрлар Советы Татарстан АССРның төньяк-көнчыгыш өлешендә Түбән Кама сәнәгать районы төзеләчәген билгели торган ике карар кабул итә. Аның үзәген алга таба эшкәртү өчен яраклы пластмасса, синтетик каучук һәм углеводород чималының яңа төрләрен чыгарачак завод – Европада иң эре нефть химиясе комплексы тәшкил итәргә тиеш була.

БЕРЕНЧЕЛӘРГӘ САЛЮТ!

«Мин яңа шәһәр төзергә киттем», – дип язган хатынына экскаваторчы Иван Коршин. Ул үзе кебек 24 эшче белән, махсус техниканы чаналы трактор поездына төяп, 1960 елның 25 декабрендә Лениногорскидан юлга чыга. Кич белән беренче төзүчеләр Актүбә авылына килеп җитә. Ату тавышыннан куркып калган халык аларны каршы алырга чыга, баксаң, җирле аучы әлеге кунаклар хөрмәтенә мылтыктан салют аткан икән. Алдагы елын Иван Коршин тулысынча диярлек экскаватор кабинасында үткәрә.

Марафон берничә ел дәвам итә. Булачак шәһәр берьюлы бөтен нәрсәгә мохтаҗлык тоя: төзелешне алып барырга кирәк, аның өчен материаллар, һәм бу тирәдә әсәре дә булмаган юллар зарур. Бервакыт чистарту корылмалары өчен нигез чокырын тиз казыганга, «Татэнергострой» җитәкчесе Евгений Королёв бригадага бер банка спирт һәм 10 шешә аракы алып килә… һәм шунда ук яңа объектка озата. Иван Коршинның комлы вак таш катнашмасын КРАЗ белән БЕЛАЗларга тиз төяү күнекмәсе алтын бәясенә тиң була. Бервакыт шоферлар нигез чокыры казырга җибәрелгән Коршинны алмаштыручы экскаваторчының акрын эшләве турында Евгений Королёвка зарлана. Җитәкче исә Коршинны кире кайтарырга куша һәм экскаватор белән төяп алып кайтыр өчен «Кировец» кичке сәгать унда килеп тә җитә. Билгеләнгән пунктка ярты чакрым калгач, тагылма салулап, 46 тонналы экскаватор платформадан юл читендәге үтеп булмаслык лайга оча. Куркынычсызлык техникасын төгәл үтәү Коршинны коткарып кала: ул «Кировец» кабинасында барган була. Ә экскаваторны тартып чыгару төн буена сузыла…

ЯУЛЫКЛЫ ГҮЗӘЛКӘЙЛӘР

«Гел егетләр генә. Мин патша кызы кебек вагонда яшим. Патша кызлары вагоннарда яшәми, дисезме? Алар күп нәрсәне югалта,



дияр идем. Авыр, әмма күңелле яшибез», – дип яза көндәлегендә 1961 елда комсомол Зина Златковская. Кызлар егет-җилән белән иңгә-иң торып эшли, вагоннарда яши. Бу вагоннар янәшәдәге бараклар белән бергә Төзүчеләр бистәсе дип атала башлый. Торак биналар эчендә мичтән һәм ике катлы караватлардан башка берни дә юк. Бистә һәм төзелеш базасы – бөтен дөнья шуннан гыйбарәт. Якындагы авылга кадәр 5 чакрым барасы. Тирә-якта үтеп булмаслык сазлы пычрак. Бар юаныч – күршеләрдән алган керосин лампасында китап уку яки кәрт сугу. Ипи хәтле ипине дә Чаллыдан китерәләр. Кайчагында ул шакырдап туңа – балта белән чабарга туры килә. Мондый шартларда кәттәлек турында уйларга да түгел, тик ул еллардагы фотосурәтләрдән безгә чын гүзәлләр карап тора, аларның күзләре шатлык, тормыш дәрте белән яна. Бу кызларга өчпочмаклы кыек яулык белән тупас эш киемнәре – комбинезоннар, свитер һәм эшче чалбарлары да искиткеч килешә. Аннары, 70 нче елларга таба, биредә беренче чәчтарашханә, тегү остаханәсе, кием кибете пәйда булачак, ә әлегә җылы су белән юыну да – зур бәхет.

– Кызлар, чыгыгыз, су алып киләләр! – бу чакыруга чиләк, чәйнек, кәстрүлләрне күтәреп, шунда ук чыгып йөгерергә кирәк. Актүбә тирәсендә эчәргә яраклы су түгел, гомумән, бернинди су да булмый. Аны 9 чакрым читтәге Кызыл Чишмә авылыннан трактор китерә. Су ташучы трактор көн буе йөреп тора. Су һәркемгә дә җитсен өчен, мондагы халык торба кисәкләреннән ябыштырып ясаган савытларны әллә ничә тапкыр тутырырга туры килә.

ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕЗ АЛГАРЫШ

Татарстанда Түбән Кама дигән кала төзелүе турында хәбәр бөтен ил буйлап тарала. Күпләр өчен зур төзелеш торак, азык-төлек һәм товарлар белән яхшы тәэмин итүне, һөнәри үсеш мөмкинлекләре дигәнне аңлата. Сугыш кичкән һәм аның тәэсирләреннән әле яңа гына зур тырышлык белән арынып килгән кешеләр өчен зур төзелеш тотрыклы тормыш дигәнне дә белдерә. Актүбәдәге бистә һәм тирәюньдәге авыллар төзелештә хезмәт куючы меңләгән кеше белән бик тиз тула. Аз-маз мөмкинлек булган бөтен җирдә, хәтта кул астындагы төзелеш материалларыннан әмәлләнгән алачыкларда да яшиләр. 1963 елда төзелешкә «Татэнергострой» идарәсе төзүчеләре җитәкчесе Евгений Королёв һәм «Түбән Кама Нефтехим» оешмасының булачак директоры Николай Лемаев килә һәм алар процессны үз кулларына ала. Ләкин галәмәт зур проектны гамәлгә ашыручылар бу вакытка кадәр үзләрен үзләре кайгыртып гомер кичерә. Иң якын хакимият органнары, район советы, партия райкомы, район башкарма комитеты Яр Чаллыда урнашкан. Шунда ук Круглое поле станциясенә, материаллар да китерелә, аннан аларны йөк машиналарында стройбазага ташыйлар.

АЛГА ҺӘМ БЕРНИГӘ КАРАМАСТАН

Проектны «Лениногорскнефтестрой» тресты алып бара. Аннан килгән күрсәтмәләр кайчак төзелештәге бурычлар белән бөтенләй ярашмый. 1962 елның язында хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткечләрен яхшырту максатыннан 300 кешене кыскартырга дигән боерык килә. 46 нчы төзелеш-монтаж берләшмәсе җитәкчесе Иван Точилин, бу хәлнең мәгънәсезлегенә ачуы чыгып, иң кыйммәтле хезмәткәрләр – механизаторларны эштән җибәрү турында боерыкка кул куя. 1 май бәйрәменә туры килә бу. Механизаторлар туп-туры Алабугага, КГБ бүлекчәсенә барып, Бөтендөнья хезмәт көнендә югары тәҗрибәле 300 белгечне эшсез калдырган Точилинны хокук саклау органнары тарафыннан күз уңында тотуларын сорыйлар. Тиздән төзелешкә килгән комиссия Иван Точилинны вазыйфасыннан куар өчен җитәрлек хокук бозулар таба. Шулай итеп, 46 нчы төзелеш-монтаж идарәсен 28 яшьлек Рафаил Глянц җитәкли башлый. Шул ук елны ул беренче сынавын уза: 1 сентябрьдә шәһәрнең беренче бинасын – 1 нче мәктәбен кулланылышка тапшыра. Соңрак Рафаил Григорьевич «Түбән Кама Нефтехим» директорының гражданлык төзелеше өчен җаваплы урынбасары булачак. Түбән Кама шәһәрендәге торак һәм социаль объектларның күп өлеше аның җитәкчелегендә төзелә.

ТОРМЫШ ҺӘМ ҮЛЕМ МӘКТӘБЕ

Киң урамнар, күп катлы йортлар, парклар һәм скверлар – булачак Түбән Каманы 1955 елда Гидрологик экспедиция инженерлары Алабугадагы студент-практикантларга әнә шулай тасвирлый. Искиткеч матур һәм кызыктыргыч картина кузаллана. Шул кадәр ямьле ки, студентларның берсе – Владимир Власов, физика укытучысы дипломын алгач, төш-хыялдагы шәһәргә юл тота. Әмма анда 1964 елда гына төпләнә ала ул. Һәм шунда ук үзе хезмәт куячак 2 нче номерлы мәктәп төзелешенә эләгә. «Мәгариф бүлегеннән куратор булырсың», – диләр аңа, төзелешнең генераль планын тоттырып. Июнь ае үтеп бара. Июль аенда инде Владимир Власов, мондый темплар белән эшләгәндә, мәктәпне сентябрьгә тапшырып булмаячагын аңлый. Евгений Королёвка кадәр керә. Тегесе хәлне төшенә, төзелеш ике сменада бара башлый. Августта исә өчәр сменалы эш оештырыла. Бу вакытта физика укытучысы республика буйлап парталар, мебель, җиһазлар эзләп йөри. Мәктәпне вакытында тапшыралар. Ә Владимир Власовка торак бирелә – кечкенә кухнясы һәм душы булган 4 квадрат метрлы каравылчы бүлмәсе. Ул анда хатыны һәм ике баласы белән яши башлый. Тиздән идән астында су тула торган чокыр булуы ачыклана. Кыш буе – юешлек, дымлы ис. Власовларның кече улы сал-

кын тидерә. Малайны коткарып кала алмыйлар… Берничә елдан соң, тормышларына яңа мәгънә биреп, кызлары туа. Власовлар гаиләсе – Түбән Камага бар гомерләрен багышлап, шәһәр үсешенә күп тырышлык салган затлар. Владимир Федорович тәрбияләгән укучылар хәзер Мәскәү, Санкт-Петербург, Киев фәнни-тикшеренү институтларында эшли. Аңа, Татарстанның атказанган укытучысы һәм Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданына, хәзер 84 яшь. Ә укучылары килә дә килә…

АФАНАС КЫЗЫ

– Әгәр мин Роза Зариповна янына кайтмасам, ул миннән аерылып китәчәк! – Афанас хастаханәсенең баш табибы Фатыйх Хәйбуллин яшь Валентинага әнә шулай дип белдерә, Казан дәүләт медицина университетын кызыл диплом белән тәмамлаган кыз авыруларны кабул итү бүлекчәсенең бусагасын атлап кергәч. Хастаханә Төзүчеләр бистәсеннән берничә чакрым ераклыкта урнашкан була. Кыз биргә юллама буенча килә, беренчел карау-тикшерү һәм операция бүлмәләре булган яңа иркен бина күрергә өметләнә. Ә чынлыкта баракка килеп чыга, пациентларны әнә шунда кабул итәләр һәм 30 авыруга исәпләнгән стационар да шунда урнашкан икән. 1961 ел үтеп бара. Үзәк район хастаханәсе («Түбән Кама Нефтехим» медсанчасте) ачылышына кадәр 6 ел бар әле. Хастаханәнең «ашыгыч ярдәме» булып ат җиккән Ваня абый эшли. Шәфкать туташларының тәҗрибәсе зур, барысы да яхшы булачак, дип, Валентинаны ышандырып, Фатыйх Миңлебай улы терапевт хатыны янына чираттагы ялга кузгала. Якын-тирәдәге берничә авылга, ә хәзер әле яңа бистәгә дә хезмәт күрсәткән ике табиб өчен, әлбәттә, бу ял бик кирәк. Белеме буенча теш табибе булган Валентинага кәтмәгәндә терапевт, аннары хирург, аннары гинеколог ролендә керергә туры килә… Төп диагностика коралы – куллар, ә төп күнекмә – салкын канлылык.

Бервакыт тәнлә комбайн астына эләккән ир-атны алып киләләр. Баш тиресе тулысынча салдырылган диярлек, кан елга булып ага. Пациентны Яр Чаллыга җибәрү аны бакыйлыкка озату дигән сүз. Бу көнгә кадәр Валентина үзен яралар тегә белмим, дип уйлый. Белә икән. Ир исән кала. Гомумән, Фатыйх Хәйбуллин Валентинага ышанып тапшырганнарның барысы да исән кала.



Геннадий Сумароков, 1 нче музыка мәктәбе укытучысы, 3 нче Балалар музыка мәктәбе директоры.

– Ул чорның иң яраткан җыры – «Ах, ты зимушка-зима». Казан музыка училищесын тәмамлагач, 1965 елда мин Мәдәният министрлыгы юлламасы белән Түбән Камага килдем. Башта Соболеково авылында яшәдем. Эшкә 1 нче музыка мәктәбендә баян дәресләре укытырга биш ай җәяү йөрдем. Аннары Камадан ком-чуерташ катнашмасы ташый торган шоферлар белән дуслаштым, барасы юлның яртысын шулар белән үтә идем. Шәһәрдә фатир биргәч, күпкә җиңелрәк булды. Әмма эш күп иде. Ул елларда һәр шәһәр бәйрәмендә халык уен коралларында уйнаучылар программаның иң төп номерларыннан саналды. Мин аккомпаниатор да булып эшләдем. «Түбән Кама Шин»га да бардым. Җыю цехында хор оештырганнар иде, төшке аш вакытында без «Подмосковные вечера», «Сормовская лирическая», «Уральская рябинушка» җырларына репетиция ясыйбыз… Аннары мине 3 нче музыка мәктәбе директоры итеп сайладылар. Ул торак йортның берничә фатирында урнашкан иде. Бүлмәләр арасындагы кайбер диварларны сүтүгә ирештем – шулай итеп актлар залы барлыкка килде. Хәзер боларның барысын да искә алу үзе бер кызык. Миңа 83 яшь, хәзер уйнамыйм инде. Әмма укучыларым уйный. Шуларның унысы профессиональ укытучы булды.

МАТУР ЯШЬЛЕК

Ул чорларның иң зур бәласе криминаль абортлар була. Әйләнә-тирәдә гел яшьләр, ә контрацепция турында сөйләшүләр юк дәрәҗәсендә, бала табар урын да юк дияргә мөмкин. Бервакыт шундый аборттан соң авырайган хатын-кызны алып киләләр. Аның бөерләре эшләми башлаган, хәле авыр. Чаллыдан килгән акушер хатын пациентны коткарып калып булмаячак, дип белдерә. Валентина Фатыйх Хәйбуллинның Казанга, диализ ясарга мөмкин булган тимер юл хастаханәсенә шылтыратуын үтенә. Казанда аппарат ватылган, дип хәбәр итәләр, тик Мәскәү белән элемтәгә кертергә ышандыралар. Валентинаның гаҗәпләнүенә каршы, Афанас хастаханәсенә, чыннан да, Мәскәүдән шалтыратып, пациентканы Казанга озатырга тәкъдим итәләр, ә аннан башкалага алып китәр өчен самолет җибәрәчәкләр икән. Валентина авыру хатынны озата бара. Мәскәүдән самолет килеп, аны алып та китә. Хатын исән кала һәм соңрак өч тапкыр әни дә була әле.

Бераздан шәһәргә табиблар – искиткеч, талантлы, намуслы белгечләр килә башлый. Медицина хезмәте үсә. 1966 елда Валентина Шишонина үзен тулысынча төп белгечлегенә багышлау мөмкинлеге ала. Стоматология сырхауханәсе мөдире вазыйфасын калдырып, ул хәзер дә теш табибы булып эшли. Улы – Түбән Кама үзәк район хастаханәсенең гинекология бүлеге мөдире. Оныгы Ижевскида табиблыкка укый…

«ХИМИЯ» ТАҢЫ АТА

*«За ночь ровно на этаж
Подрастает город наш,
Раньше всех к нам приходит рассвет.
Снятся людям иногда,
Голубые города,
У которых названия нет».*

60 нчы елларда бу җыр Түбән Камада бик еш яңгырый. Тормыш җайга салына бара, күпкатлы йортлар, балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханәләр төзелә. Яңа шәһәргә кешеләр килә дә килә. Анда яшәүчеләр өчен эшли алмастай нәрсәләр булмый. «Түбән Кама Нефтехим» турбиналары күккә ыргыла, «Түбән Кама Шин» заводының мәйданнары киңәя. Николай Лемаевның үҗәтлеге нәтиҗәсендә күп нәрсә тормышка ашырыла. Ул Мәскәүдәге бу тармак җитәкчелеге белән уртак тел табып, теге яки бу карарларның кирәклегенә ышандыра белә. Әйтүләренчә, нәкъ менә ул, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев ярдәме белән, иң башта ук «Түбән Кама Нефтехим» проектының зарурилыгын яклап чыга, һәм ил өчен бу предприятиенең кирәклек дәрәҗәсе автомобиль төзелеше яки энергетика предприятиеләреннән бер дә ким булмаганлыгын исбатлый. Николай Лемаев өчен кечкенә мәсьәләләр булмый. «Түбән Кама Нефтехим» өчен Мәдәният йорты салынырга тиеш түгеллеген ачыклагач, ул төзелешне барыбер килештерүгә ирешә – Техниклар йорты дигән булып…

ҮТКӘННӘР – БҮГЕНГЕДӘ

Үткәннәргә борылып караганда һәм тирә-юньгә күз салганда, геройларыбыз үз-үзләренә ышанмый. Бөтенләй тәҗрибәсез килеш, энтузиазм һәм үз Ватаннарына ышаныч белән генә коралланып, чыннан да, алар яшьтәшләре белән шушы искиткеч шәһәрне, киң, яшел проспектларны, куәтле заводларны төзи алдылармы? Әйе, чыннан да, бу – алар эше, менә фотографияләрдә төзелешкә, заводка, хастаханәгә, мәктәпкә баралар. Һай вакыт ничек тиз үтеп киткән! Бу урын белән беренче очрашудан соң узган еллар аны бүгенге хәлгә китерү өчен сарыф ителгән. Алар үзләре моңа үкенмиме? Юк, үкенмиләр. Ул чакта сайлау мөмкинлеге булса, алар янә шул ук юлны – яраткан Түбән Кама каласында яшәүне һәм аны төзүне сайлар иде.

Галина Исмәгыйлова, табиб – акушер-гинеколог.
– Гамир Гарифович белән без Төзүчеләр бистәсенә 1964 елның июнендә килдек. Эссе вакыт. Хастаханә барагыннан каршыбызга шәфкать туташы йөгереп чыкты. Хирург Фатыйх Миңлебаевич чыгып киткән, ә шуннан соң сукыр эчәгә ялкынсынган авыруны алып килгәннәр икән. Гамир Гарифович кичекмәстән операция ясарга тиеш иде… Ул кереп китте, ә мин әйберләр белән юл уртасында калдым. «Кайда соң без?»… Әмма ничек кенә булса да табиб хастаханә янында яшәргә тиеш дип уйлый идек. Табибларның ул буыны акча турында уйламады да. Соңрак, безгә ике бүлмәле фатир биргәч: «Менә сиңа мә! Без монда нәрсә эшләрбез икән?!», – дип, анда әрле-бирле йөрдек тә әле.

Гамир Исмәгыйлев алга таба шәһәрнең баш хирургына әйләнә, 3 нче шәһәр хастаханәсенә нигез сала һәм аның баш табибы була. Түбән Камада медицина үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Хәзер – Россиянең һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы. Хатыны, акушер-гинеколог Галина Ивановна хатын-кызлар консультациясен ачу, 1 нче бала тудыру йортын төзү, 2 нче һәм 3 нче шәһәр хастаханәләрендә гинекология бүлекләрен булдыру эшендә башлап йөри.

Түбән Кама каласының төзелеше хакындагы гаҗәеп тарихларны сез шәһәрнең комплекслы музеенда ишетә аласыз. Редакция музей хезмәткәрләренә материал эшләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен зур рәхмәтен белдерә.

ХРУЩЁВ ТАТАРСТАНДА. БЕРЕНЧЕ ҺӘМ СОҢГЫ СӘФӘР...

1964 елның 10 октябрь таңы. Казанга якынлашып килгән «Омик» бортында тенор тавышлы берәү хисле итеп «Вдоль по речке, вдоль да по Казанке...» дип моңлана. Аңа сак кына баритон кушыла. Солист – КПСС Үзәк Комитеты беренче секретаре Никита Сергеевич Хрущёв. Кушылып җырлаучысы исә вазыйфасы буенча моңа лаек кеше – партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев...

Автор:
Әскәр Сабиров

Никита Сергеевич хисләре ташудан җырлый – бирёдән, су өстеннән, Казан әкияттәгедәй матур күренә. «Җепшеклек» һәм хрущёвкалар тудыручының үзенең кәефе дә бик шәп. Никита Сергеевич һәм аны озата йөрүче затлар «Ом-290» белән Боровое Матюшинодагы обком дачасыннан кайтып бара. Кичә аларны патшадай каршы алдылар, милли ризыклар белән сыйладылар, балык тоту да көтмәгәндә уңышлы булып чыкты.

КАРШЫЛАУ. ИХЛАСТАН ҺӘМ БОЕРЫК БУЕНЧА

«Тарихи сәфәре өчен рәхмәтле һәм аның тарафыннан хезмәттә яңа батырлыкларга илһамландырылган елга флоты хезмәткәрләре» исеменнән чәчәк бүләк итүче яшь матрос ничек тәэсирле кызара! Никита Сергеевич, билгеле ки, аның елгачы булмавын да, элегрәк әзерләнгән сценарийны бозып, дулкынланудан сөйләм сәләтен югалткан командир урынына тырышуын да белми. Ярый әле, органнарда эшләүче уңган егетләр теләсә нинди уңайсыз хәлдән чыгу өчен гел кул астында...

Ә кичә Казанда ничек каршыладылар Никита Сергеевичны! Аэропортта – пионерлардан гладиолуслар! Хәрәкәт маршрутының буеннан-буена – сокланулы йөзләр! Елмаялар, кул селкеп сәламлиләр. Ачык «Чайкада» баскан, пиджагына дүрт Герой йолдызы кадаган Хрущёв канәгать, ул үзе дә халыкны бәйрәмгә генә кия торган эшләпәсен селкеп сәламли. Әйтерсең, юлбашчыны күреп калырга дип, үз теләге белән бөтен шәһәр чыкан.

Чыннан да, беркемне дә куып китерергә туры килми – Хрущёвны күрергә дип күпчелек үз теләге буенча, кызыксынып җыела. Әмма инде барыбер партия җитәкчелегеннән башка моның кадәр үк бердәм килеп чыкмас иде. Казанлы Борис Милицынның дистәләрчә ел узгач республика басмаларының берсендә дөнья күргән хатирәләреннән өзектә: «Мин эшли генә башлаган Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институтына, Хрущёв җитәкчелегендәге хөкүмәт кортежын каршылаганда хезмәткәрләрнең кайсы нинди урамда басып торырга тиешлеген күрсәтеп, алдан ук разнарядка килде...» – дип искә алына.

Милицынның коллегаларына Лумумба урамында «кизү торырга» боерыла, тик алар Хрущёвны күрми кала – әлбәттә инде, маршрут үзгәртелә. КДУда планлаштырылган очрашу да булмый кала. Югары дәрәҗәле кунакны берничә сәгать буе бушка көткән университет укытучыларын һәм студентларны нәтиҗәдә өйләренә кайтарып җибәрәләр. Никита Сергеевичны «Оргсинтез» заводында да, авиация заводында да көтеп җиткерә алмыйлар, гәрчә химиклар һәм самолёт төзүчеләр белән очрашу программада соңгы минуткача була. Моңа кадәр, Хрущёв сәфәренә бер ай кала ук, юлларга асфальт җәяләр, коймаларны буйыйлар һәм хәтта Ленин районындагы Кизический монастырь зиратындагы авышкан чардуганнарны, кабер ташларын да алып ташлыйлар...

Ил өчен стратегик булган предприятиеләргә (берсендә тиздән этилен һәм полиэтилен җитештерү сафка бастырылачак, икенчесендә Ту-22 бомбардировщикларын җыялар) барудан Хрущёвның ни өчен баш тартуы сер булып кала. Ихтимал, программа куркынычсызлык ниятеннән үзгәртелгәндер. Бәлки



исә, нинди дә булса авылда, кырда үзен бик ышанычлы сизгән Никита Сергеевичның бу өлкәләрдә үзенең бәһасез киңәшләрен бирергә хәленнән килмәгәнгәдер.

КУЛДАН ИДАРӘ ИТҮ МОГҖИЗАСЫ

Ә менә инде икенче көнне Татарстанның көньяк-көнчыгышында Хрущёв үзен судагы балык кебек хис итә. Бигрәк тә «Авангард» колхозы кырларында, анда дәүләт җитәкчесенә «кыр патшабикәсенең» үрнәк плантацияләрен күрсәтәләр. Әмма әле эш кукуруз белән генә бетми бит. Колхоз рәисе Газизулла Кәрамуллинны яхшы уңыш өчен мактаганнан соң, Хрущёв сорау бирә: «Әйтегез әле миңа, чиста пардан нинди уңыш аласыз, колхоз пар басуыннан яки туңга сөрүдән ике елда күпме уңыш җыя?» Дәүләт җитәкчесенең һичшиксез шәхси катнашуын таләп иткән әлеге сорау бик озак һәм тәфсилләп тикшерелә.

Аннары исә Никита Сергеевич бәрәңге үстерүнең колхоз һәм Татарстан өчен нинди гаҗәеп перспективалар ачуы турында әңгәмәдәшенә тулы бер лекция укый: «Сез Ростов-на-Дону, Азәрбайҗан, Үзбәкстан өчен бәрәңге җитештерә аласыз...» – ди. Бүлбеләрдән мул уңыш җыю өчен кирәкле агротехниканы, табигый ки, Хрущёв рәискә шундук җентекләп үзе аңлата, мөмкин кадәр күбрәк минераль ашлама кулланырга киңәш бирә.

Минераль ашламаларның колхозга бик аз күләмдә генә бүленүен белгәч тә, Никита Сергеевич югалып калмый: «Без сезгә сатылачак бәрәңге үстереләчәк бөтен мәйданга җитәрлек минераль ашлама бирә алыр идек. Әмма бу ашламаларны билгеле бер вексель хисабына гына бирергә кирәк. Ашлама аласыз икән – вексель бирегез: әлеге ашламаны кулланудан сез сатарга яраклы күпме бәрәңге үстерәчәксез», – ди.

Хрущёв Татарстанда кулдан идарә итү могҗизасын да күрсәтә. Колхозда «Мироновская-88» уҗым бодаен чәчәргә теләүләрен, әмма орлык булмавын белеп алуга ук, өч көннән орлык могҗизалы рәвештә табыла да. Кирәкле сортлы өч тонна бодай ашыгыч рәвештә самолет белән Харьковтан кайтартыла – махсус «Авангард» колхозы өчен...

НЕФТЬ ГАЗЛЫ СУДАН АРЗАНРАК

Никита Сергеевич колхоз кырларына нефтьчеләр янында экскурсиядә булганнан соң ук килә. Байлыкны күрсәтү Карабаш тавыннан башлана, аннан әйләнә-тирәдәге берничә чакрымдагы бөтен нефть суырткычлары, бораулау вышкалары, нефть җыю парклары уч төбендәгедәй күренә. Хәтта Ромашкино чыганагының зур картасы янына куелган күзәтү торбасының да кирәге чыкмый. Нәкъ менә биредә, Карабаш тавында, Хрущёвка нефть чыгаручыларның казанышлары турында сөйләгәндә, җаваплы иптәшләрнең берсе мәгълүм гыйбарәне әйткән диләр: янәсе, татар нефтенең бер чиләге дәүләткә бер стакан газлы судан арзанракка төшә.

Сәнәгать пейзажлары белән хозурланганда, Никита Сергеевич янып торган иярчен газ факелларына игътибар итә һәм шундук кызыксына: аларның җылысын, мәсәлән, су җылыту яисә теплицаларда яшелчә үстерү өчен кулланып булмыймы икән? Яраннары дәшми калуны артыграк күрә, чөнки, Табиев фаразынча, иярчен газны берничек тә болай гына файдаланып булмый. (Бик кыйммәтле нефть чималы, иярчен газ, шуннан соң да ике дистә ел буе бер файдасызга күкне җылытуын дәвам итә – ред.иск.).

Аннары иң алдан броняла «ЗИС» барган кортеж Азнакай ягына юнәлә, юлда барганда, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Тимченко бригадасы Никита Сергеевичка бораулау җайланмасын ничек күчереп йөртүләрен күрсәтә. Җиде «С-100» тракторының аны яңа урынга өстерәвен күзәткәндә, дәүләт җитәкчесе тагын кызыксына: моны азрак трактор белән эшләп булмыймы? Була, әмма дәүләт нефтьчеләргә куәтлерәк тракторларны бирми, дип җавапльйлар. Биш көннән соң «Татбурнефть» трестына куәтле дүрт «С-400» тракторы килеп җитә.

ЫШАНЫЧЫҢ БУЛМАСА – УЗМА

Никита Сергеевич белән хушлашу табыны Азнакайдан унике чакрым ераклыктагы Сәпәй (шул заманнардан бирле аны Хрущёв урманы дип йөртәләр) урманында әзерләнә. Зур чатыр, корылган табын, данлыклы Юныс Әхмәтҗанов пешергән затлы татар халык ашлары – барысы да бик югары дәрәҗәдә була. Хрущёвка токмач та, өчпочмак та ошый, әмма барыннан да бигрәк тутырган тавык күңеленә хуш килә. Фикрәт Табиев искә төшерүенчә, аны авыз иткәч, Хрущёв: «Бу тавыкларны миңа юлга куегыз», – дип боера. Юныс Әхмәтҗанов исә тиздән Ленин ордены белән бүләкләнә...

Хрущёв республикадан күтәренке кәеф белән китә. Аның «Татарстан миндә яхшы тәэсир калдырды», дигән сүзләрен китерә 1964 елның 12 августында «Советская Татария» газетасы. Сәфәр, чыннан да, бер кимчелексез диярлек үтә. Бер кечкенә генә вакыйганы исәпкә алмаганда. Кортеж бара торган маршруттагы юл буендагы бер плакатта: «Ит һәм сөт җитештерү буенча АКШны куып тотыйк!» дигән шигарь язылган була. Тик шул юл белән үк кире кайтканда плакатның икенче ягындагы ДАИ язган сүзләр күренә: «Ышанычың булмаса – узма!»

Ике айдан соң Никита Сергеевич Хрущёвны КПСС ҮК беренче секретаре һәм совет хөкүмәте башлыгы вазыйфасыннан азат итәчәкләр һәм пенсиягә җибәрәчәкләр.

БӨЕК ПЁТРНЫҢ ҺАВА ФЛОТЫ



1967 елның июле. Домодедово күгендә стратегик бомбардировщиклар гүли, реактив «МиГлар» мәтәлчек ата. Самолётлар «Ленин» сүзен яза! Тамашачы таң кала, Көнбатышның хәрби атташелары исә уйга чума... Генераль секретарь Леонид Ильич, кулын маңгаена куеп, күкне күзәтә һәм канәгать елмая. Авиация сәнәгате министры Пётр Дементьев исә бик бәхетле. СССРда беренче авиасалон уздыру һәм илебездә җитештерелгән иң шәп очкычларны бөтен дөньяга күрсәтү – аның акылга сыймаслык идеясе. Һәм барып та чыга бит!

БЕЛЕШМӘ

Пётр Васильевич Дементьев. Татарстанның Чүпрәле районында туган. 1953 елдан 1957 елга һәм 1965 елдан 1977 елга кадәр СССРның авиация сәнәгате министры. 1957 елның декабреннән 1963 елның мартына кадәр – СССР Министрлар Советы Авиация техникасы буенча дәүләт комитетының беренче рәисе, 1963 елның мартыннан 1965 елның мартына кадәр СССР Министрлар Советы Авиация техникасы буенча дәүләт комитетының беренче рәисе – СССР министры. Генерал-полковник-инженер. Ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое. Сталин премиясе лауреаты. Мәскәүдәге Новодевичье зиратында җирләнгән.

Бөек Пётр булсын да, ниятләгәнен булдырмасын, имеш! Авиаконструкторлар Ильюшин, Туполев, Сухой, Яковлев Дементьевның үз теләгенә һичшиксез ирешәчәгенә тамчы да шикләнми. «Бөек Пётр» кушаматы күктән төшмәгән бит, аны халык үзе шулай зурлаган. Гәрчә министрның Пётр патша белән охшашлыгы бөтенләй булмаса да. Тәбәнәк буйлы, пеләш башлы, кысык күзле... Шәҗәрәсендә дә аксөякләр юк. Татарстанның Чүпрәле районындагы чуваш авылы Үбигә патша җәнапларының гомердә дә аяк басканы булмаган...

Ә менә Пётр Васильевич кул астындагы империя Пётрныкы ише генә түгел, шаккатырырлык. Эстониядән алып Үзбәкстанга кадәр булган территориядәге өч йөздән артыграк предприятие – заводлар, конструкторлык бюролары, институтлар – Көнбатышныкыннан һич калышмый торган самолётлар, вертолетлар уйлап таба һәм җитештерә. Һәм дөньядагы һәр бишенче самолёт – безнеке, советлар иленеке. Бөек Пётр түгелмени? Тик аның хуҗалыгын империя дип атамау хәерлерәк – СССРда бу сүзне яратмыйлар. Дәүләт эчендәге дәүләт, дисәк, дөресрәк булыр...

Автор:
Әскәр Сабиров

ТОРМЫШТАН МӨМКИН БУЛМАГАННЫ ДӘГЪВАЛА

Илебезнең авиация куәтен җиһанга күрсәтү идеясе ни өчен гайре табигый тоела соң? Лубянкада һәм Иске мәйданда утыручыларның бу җәһәттән фикерләре уртак диярлек. Салкын сугыш бара, һәм анда, тимер пәрдә артында, тоташ дошманнар. Ә без аларга үзебезнең өр-яңа «МиГ», «Як», «Су», стратегик «Ту-22» самолётларын күрсәтикме?! Башка өлкәләрдә исә яшеренлек белән тулы тәртип: СССРда кайбер шәһәрләргә чит ил кешеләре бөтенләй кертелми, хәтта юллар киңлеге, күперләр озынлыгы һәм кайбер футбол командаларының исеме дә дәүләт сере булып тора – аларны матбугатта телгә алырга да ярамый...

Дементьевка хәрби сернең нәрсә икәнен аңлатасы түгел – ул инде Сталин вакытында ук авиация сәнәгате халык комиссары урынбасары булган кеше. Әмма ул артта калмас өчен чит илләрдән яшеренмәскә кирәклеген дә яхшы аңлый. Министр барыбер үз дигәненә ирешә: 1965 елда Ле-Бурже авиасалонына илдәге иң яхшы һава транспорты – Ил-62, Ан-22 – «Антей» гигант самолёты, дөньяда иң зур Ми-6 һәм Ми-10 вертолётлары җибәрелә... 1967 елда аларга «Восток» космик корабле макеты өстәлә. Нәтиҗә – совет экспозициясенең шаккатыргыч уңышка ирешүе.

Хәзер инде уңышны ныгытырга кирәк, дип уйлый Дементьев һәм үзебезнең авиация казанышларын илебездә дә күрсәтү зарурлыгын кайгырта башлый. Идеяне

Домодедовода һавада очышлар. 1967 ел.

хупламыйлармы? Бу җәһәттән Бөек Пётрның яраткан гыйбарәсе бар: «Тормыштан мөмкин булмаганны да дәгъвала, шул очракта гына барысына да ирешәчәксең», – ди ул.

«Мөмкин булмаганны» даулап, Дементьев иң югарыга, КПСС Генераль секретарена юнәлә. Министрны идеяне файдалы итеп күрсәтү осталыгына өйрәтәсе түгел: СССРда хәтта иң даһи самолёт проектын да, югарыда ошатмасалар, җитештерергә рөхсәт итмәскә мөмкиннәр... Бу юлы ул партиягә кагылышлы дәлилләр китерә: тиздән Совет хакимиятенең 50 еллыгы җитә, нишләп әле казанышларыбызны бөтен дөньяга күрсәтмәскә ди?

– Иптәшләр, шәп идея бит бу! – дип мөрәҗәгать итә Леонид Ильич очрашуда катнашкан ҮК әгъзаларына. – Авиаторлар совет халкын үз уңышлары белән сөендерсен әйдә...

Әлбәттә инде, хәзер каршылар юк. Дөрес, нәтиҗәдә авиасалонны «күрсәтү» дип атаячаклар, ә аны үткәрү вакытын нибары бер көнгә калдырачаклар. Әмма бу инде барыбер Пётр Дементьевның чираттагы җиңүе булачак.

Ничәү соң алар, мондый җиңүләр? Кимендә, Домодедово салонындагы самолётлар саны кадәр бар. Шул җиңүләрдән бирсе – Домодедоводагы күрсәтү мәйданчыгында тарихи реликвияләр рәтендә торучы «Як» истребителе. Ә бит әлеге очракта җиңелү карьерадан колак кагуга гына түгел, бик күңелсез нәтиҗәләргә китерергә мөмкин була...

ИКЕ АТНАЛЫК СЫНАУ ВАКЫТЫ

Бу хәлләр 1943 елда була. Халык комиссарының сериялэп самолётлар чыгару өчен җаваплы урынбасары Дементьевны көтмәгәндә Кремльгә чакыртып алалар. Сталин янына. Сәбәбе: очучы-истребительләр җитәкчеләргә зарлана икән – полкларга бирелгән яңа «Як»ларның тышлыгы ике-өч очыштан соң ук катлау-катлау булып кубып төшә.

Югары башкомандующий ачулы, гаеплене шәхсән үзе тапмакчы була. Авиаконструктор Яковлев гаепне тиз генә үз өстеннән төшерә: янәсе, машина яхшы, җитештерүчеләре начар, алар брак ясый...Яковлев хаклы булганмы-юкмы, хәзер инде билгесез, ә менә Дементьевның акланырга маташмавы һәм гаепне башкаларга аударырга тырышмавы – хак.

– Ни өчен совет кешеләренең эчке дошманнары да бар соң әле? – Сталинның әлеге соравыннан соң яхшыга өметләнеп булмый инде.

Дементьев, шулай да, каушап калмый. Җавап бирә: ике атна эчендә барлык дефектлы самолётларны да сафка бастыруны гарантияли.

– Ике атна эчендә дисезме? Алайса, сезнең язмышны да ике атнадан соң хәл итәрбез, – ди Сталин, озак кына дәшми торганнан соң...

Еллар үткәч, бу вакыйганы Ерак авиация командующие Василий Решетниковка сөйләгәндә, Дементьев яшермичә әйтә: ул вакытта аңа кабинеттан ничек тә чыгып китәргә һәм кулга алынмаска кирәк була – чөнки кабул итү бүлмәсендә Лаврентий Берия көтеп тора...

Ә аннары? Аннары нарком урынбасары кабат үзенең булдыклы идарәче икәнен күрсәтә. Авиация заводлары директорларына иң оста хатын-кыз белгечләрдән тиз арада бригадалар оештырырга һәм аларны, сыйфат һәм тизлек өчен өстәмә акча түләп, фронт аэродромнарына, авиация полкларына – дефектларны төзәтергә җибәрергә боера.

Анда, полкларда, хатын-кыз белән аралашуга сусаган техниклар, хәтта пилотлар да, командировкага килгән белгечләргә хәлкадәри булышачак. Ике атнадан соң Дементьев Сталинга хәбәр итәчәк: күрсәтмә үтәлде. Тормыштан мөмкин булмаганны дәгъвала...

Дементьев Сталин чорында ничек исән кала алгандыр – моны без берничек тә белә алмыйбыз инде. Сугыш вакытында да, аннан соң да Хуҗаның аны вазыйфасыннан, ирегеннән, ниһаять гомереннән мәхрүм итү өчен сәбәпләре күп була.

Як-28 бомдировщиклары.

Петр Дементьевны Ленин ордены һәм икенче «Урак һәм Чүкеч» медале бүләкләү. 1977 ел.

Мәсәлән, 1941 елның декабрендә, Куйбышевка эвакуацияләнгән авиазаводка Сталин телеграмма-хөкем җибәргән вакытта: «Бу – илдән, Кызыл Армиядән көлү. Әгәр завод илгә көненә нибары бер Ил-2 самолёты җыеп бирергә җыена икән, бик нык ялгыша һәм моның өчен каты җәзага тартылачак...» – диелгән була анда. Яисә инде 1942 елда, Казанда җыелган серияле Пе-2 завод дефекты аркасында ватылып, авиаконструктор Петляков һәлак булган чакта...

Бу ике очракта да нәкъ менә серияләп самолётлар чыгару өчен җаваплы нарком урынбасары шәхсән җавап тотарга тиештер кебек. Ике очракта да нәкъ менә нарком урынбасары Куйбышевта һәм Казанда көнне төнгә ялгап эшли. Сәбәпләрне ачыклый, оештыра, яңый, катгый карарлар кабул итә. Нинди бәя белән икәнне фаразлап кына була, әмма ул һәрвакыт нәтиҗәгә ирешә. Куйбышевта картлар, хатын-кызлар һәм балалар, салкын цехларда, ярымач килеш, 1942 елның гыйнвар азагына инде көненә сигезәр Ил-2 җыя...

Сталин эштән башка бернәрсәгә исе китми торган яшь нарком урынбасарына тәгаен хәерхаһ була. Һәм, шуңадыр мөгаен, башкаларга кичермәгәнне аңа кичерә.

1946 елда, Җиңүдән соң, авиация наркомы Алексей Шахурин кулга алына – янәсе хәрби самолётларның начар сыйфатлы булуы, сугышта акланмаган югалтуларга китергән күпләгән брак өчен. Бу самолётларны чыгару өчен җаваплы нарком урынбасары Петр Дементьев исә, гайре табигый булса да, үз вазыйфасын саклап кала. Һәм безнең самолётлар тизрәк, югарырак, көчлерәк очсын өчен, әле тагын бик күп нәрсә эшләү мөмкинлеге ала.

Хәер, самолётлар гына да түгел. Бүген, 1967 елның июлендә Домодедовода хөкүмәт трибунасыннан министр Дементьев күзәткән вертолётлар – аның катнашыннан башка алар булыр иде микән, юк микән?

«Әйтергә кирәк, Дементьев масштабындагы кешене йөзләрчә кыры балкыган бриллиантка тиңләп була, һәм беркем дә аларның барысын берьюлы күрә алмый. Министр үзе аралашкан кешеләрнең һәркайсына үзе күрсәтергә теләгәнне генә күрергә рөхсәт итә. Ул кырыс та, рәхимле дә, кире дә, шәфкатьле дә була белә, кирәк икән – мактый, кирәк икән – сүгә, кешене якынайта да, билгеле бер дистанциядә тота да ала – ул күпкырлы һәм, министр янәшәсендә эшләүчеләр фикеренчә, нәкъ менә шуңа күрә кызыклы һәм кадерле була да инде».

Генрих Новожилов, РФА академигы, генераль конструктор, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое.

ЗӘҢГӘР КҮКТӘГЕ ПОЛИТБЮРО

Ми-8 вертолётларын серияләп җитештерү булачакмы-юкмы турындагы мәсьәлә КПСС ҮК Политбюросының бердәнбер тапкыр күктә – «сигезле» бортында үткәрелгән утырышында тикшерелгән, диләр. Булган хәлме бу? Мөгаен, дөрестер. Эш шунда: аннары дөньяның дистәләрчә илендә югары бәя бирелгән бу машинаның күкне яулау тарихы шактый катлаулы була. Дементьев «сигезлегә» Никита Хрущёвны гашыйк итә, әмма бу гына җитми – бөтен нәрсә Кремльдәге бер генә кабинетта хәл ителгән вакытлар үткән шул инде... Һәм Никита Сергеевич, Дементьевның басымына түзә алмыйча, мәсьәләне тикшерү өчен Политбюро әгъзаларын күккә дәшә. Эксперименталь машина бортына.

Хрущёвның чираттагы яңалыгын Политбюро әгъзаларының ничек кабул итүен күз алдына китерү җиңел. Артык сак Анастас Микоян хәтта бортка һичшиксез конструктор Михаил Мильне һәм министр Пётр Дементьевны да алырга тәкъдим иткән, диләр. Әмма Никита Сергеевич аның бу фикерен хупламаган. Янәсе, берәр нәрсә була калса, җаваплылыктан барыбер кача алмаячаклар.

Тарихи очыш 1963 елның язында булачак. Мәскәү һәм аның тирәюне белән кошлар югарылыгыннан хозурланып, партия җитәкчелеге Ходынка кырына исән-имин төшеп утырачак. Кояштай балкыган Никита Сергеевич конструктор һәм министрга бик шәп машина төзегәннәре өчен рәхмәтен җиткерәчәк һәм шундук үзе өчен вертолёт-салон ясарга фәрман бирәчәк. «Сигезлене» серияләп җитештерә башлау рөхсәт ителәчәк.

Нәтиҗәдә Ми-8 Казанда җитештерелә башлый, 1969 елга бу машиналар җыю линиясеннән Ми-4 вертолётларын тулысынча кысрыклап чыгара, тора-бара биредә елына берничәшәр йөз «сигезле» җыела. Вертолёт 50 дән артык илгә сатылачак. Азиядә, Африкада, Европада, Америкада...

Кемдәдер мондый фикер дә туарга мөмкин: гүя министр Дементьев перспективалы хәрби һәм гражданлык самолёт һәм вертолётларын җитештерә башлау максатында югарыда «юл ачу» белән генә шөгыльләнгән. Чыннан да, юл ачкан, һәм моны, дипломатия могҗизасы күрсәтеп, бик оста эшләгән. Кабатлап әйтәм, СССРда авиация техникасының һәр яңа тибының киләчәге югары җитәкчелек дәрәҗәсендә хәл ителгән. Һәм, мөгаен, генсекларның эше аларга бу техниканы партия номенклатурасыннан чыкмаган министр тәкъдим иткәнгә уңгандыр.

Дементьевның тормыш багажында – аэродромда эшләү, Жуковский академиясе, Мәскәү авиазаводында цех башлыгы вазыйфасы... Утызынчы елларда ул – авиация заводында баш инженер, аннары – директор, авиация җитештерүен оештыруны өйрәнү өчен АКШка һәм Германиягә бара һәм илнең иң яхшы конструкторлары белән тиң булып аралаша. Инандыру һәм үзенең дөреслеген дәлилләү өчен белеме хәттин ашкан. Булачак министр бервакыт хәтта авиаһәлакәткә дә юлыга – 1934 елның кышында Ерак Көнчыгышка очкан «Юнкерс», гадәттән тыш хәл аркасында Амур бозына төшеп утырганда, ватыла. Командир һәлак була, сынаучы-инженер Дементьев һәм экипажның калган әгъзалары могҗиза белән исән кала һәм, утыз градуслы салкында берничә тәүлек буе баргач кына, кеше яши торган торакка килеп җитә...

Әйе, самолётларның язмышы югарыда хәл ителә, әмма аларны үзләштерү, җитештерүне оештыру, серияләп чыгаруны җайга салу министрлык эше була һәм еш кына бик авыр бара. Әмма Бөек Пётр эшенең бу өлешен хәтта Сталин, Хрущёв яки Брежнев каршында үз фикерен яклаудан да кырысрак итеп башкара. Казан вертолёт заводы ветераннары, мәсәлән, Дементьевның тоташ металлдан эшләнгән калакларны (элеккеләре бик тиз вакыт эчендә сафтан чыга торган була) үзләштерү процессын ничек катгый



Чүпрәле районында яңадан торгызылган әлеге йортта 1905 елдан 1920 елга кадәр Елена Герасимовна һәм Василий Степанович Дементьевлар гаиләсе яшәгән. Монда аларның балалары, шул исәптән уллары Пётр – булачак авиация сәнәгате министры туган.

контрольдә тотуын хәзергә кадәр хәтерли. Технологик проблемалар бик күп була, әмма 1961 елгы соңгы зур киңәшмәдә министр «объектив сәбәпләр» турында тыңлап та тормый – хисап аенда берьюлы алтмыш комплект җитештерү графигын раслау өчен үзенә бирергә боера! Һәм бернинди өзеклек тә булмаска тиеш!

Бирелдә, үзенең идарәсендә, ул инде патша да, алла да. Бик усал һәм кире дә, кирәк икән – рәхимле һәм юмарт та була, җәза да бирә, ак-лый да ала. Һәм боларның барысын да эшли – иң мөһиме нәтиҗә бит.

МИНИСТРЧА ШАБАШКА

Авиация сәнәгатенең барлык предприятиеләренә минуты-сәгате белән барып ирешкән әлеге вакыйга завод аэродромнарының берсендә була. Реактив бомбардировщиклар конструкциясендә ашыгыч рәвештә нәрсәдер үзгәртәсе бар. Моның өчен исә аларның барысын да – егерме дүрт машинаны – ангарга кертергә кирәк. Әмма аэродром хезмәтләре, конструктор һәм инженерлар никадәр генә баш ватмасын, ангарга моннан ике тапкыр кимрәк кенә самолет сыя. Министр кара көйгән. Әмма бу такелажчылар бригадирын куркытмый:

– Пётр Васильич, бөтен 24 машинаны да ангарга кертсәк, бригадага ун мең сум акча бирәсезме?

– Ә ничек кертмәкче буласың?

– Үзем беләм мин... Акча бирәсезме?

– Бирәм!

Ярты сәгатьтән соң 24 машина да ангарда тора. Барысы да бик гади булып чыга: шассиның сул тәрәкләрендә шинадагы басымны киметәләр, һәм күрше машиналарның бер-берсенә комачаулаган канатлары берсе өстенә берсе кереп урнаша...

Иң мөһиме – нәтиҗә. Министрлыктан китерткән акча тәргәген биргәндә, Дементьев бригадирдан сорый:

– Санап аласыңмы?

– Юк, әлбәттә. Мин сезнең сүзегезгә ышанам...

Авиация сәнәгате хезмәткәрләре Дементьевны кырыс, әмма гадел җитәкче дип саный. Бу очрактан соң министрның абруе күккә кадәр күтәрелә. Шулкадәр югары күтәрелә ки, хәтта тарихның күңелсез дәвамы күпләргә мәгълүм дә түгел. Берничә елдан соң авиаконструктор Ильюшин «хуҗалыгында» шундый ук хәл килеп чыга – ангарга самолетлар сыймый. Козлов фамилияле бригадир министрдан акча каермакчы була. Тик бу юлы Дементьев көлемсери генә:

– Әгәр Сергей Владимирович (Ильюшин – ред. иск.) бераз акча бирсә, моны ничек эшләргә кирәклекне мин үзем сөйләп бирәм...

Аннары, машиналар ангарга кертелгәч, министр бригадирны чакырып ала һәм ихластан әйтә:

– А для вас, Козлов, денег не прислали...

– Карагыз нинди безнең министр, эшчеләргә дә «сез» дип һәм фамилия белән эндәшә, – дип соклана бер хезмәткәр.

– Син нәрсә, ул хәтта директорларга да «син» дип кенә эндәшә...

Дементьевның Ильюшинга (министр аңа да, кул астындагы кешеләргә мөрәҗәгать иткәндәй, «син» дип эндәшә) мөнәсәбәте дустанә диярлек – кагыйдә буларак, аның тәҗрибә-конструкторлык бюросына претензияләр юк. Әмма бу эшкә кагылмый. 1962 елның декабрендә беренче Ил-62 җыелгач, Дементьев үзенең бөтен номенклатура куәте белән Ильюшинга басым ясамакчы була – самолёт ел азагына кадәр һавага күтәрелсә, матур итеп рапорт биреп булыр иде! Әмма Сергей Владимирович бирешми – тагын бер тапкыр «чистартырга», тикшерергә кирәк...

Нәтиҗәдә исә нинди матур самолёт килеп чыга! Менә ул, илебез авиатөзелешендә эпохага әйләнгән континентара реактив лайнер – Домодедово өстеннән түбәннән генә очып бара. 1967 елның июленә ул инде Казан авиация заводында елдан артык серияләп җитештерелә. Беренче очыштан алып серияләп чыгаруга кадәр өч елдан азрак вакыт китү – Бөек Пётр империясе казанышы.

ИЛЛЕ ЕЛГА АЛГАРАК

1967 елның июле, Домодедово. СССР авиациясендә соңгы елларда җитештерелгән иң яхшы самолёт һәм вертолётлар дөньяга һәм илгә күрсәтелә. Бу – Дементьевның министр вазыйфасындагы эшенә иң зур бәя бит инде. Әмма Пётр Васильевичның үзенә хәзер шулай дип әйтсәң – үпкәләячәк.

Аңа әле нәтиҗәләр ясарга бик иртә. Ул үзе һәм тагын бик аз кеше генә белгән перспективалы темалар бар. СССР Министрлар Советы НАТО илләренең һава һөҗүменә каршы оборонасын үтеп керерлек яңа стратегик ракета-йөрткеч төзү турында карар кабул иткән инде, шул документтан туып, Казаныбызда Ту-160, безнең «Ак аккош» төзеләчәк. 1968 елда Ту-154 беренче тапкыр һавага күтәреләчәк – ул әле бүген дә оча. 1969 елның июнендә дөньяда беренче тапкыр пассажир самолеты тавыш барьерын үтәчәк – һәм бу Англия-Франция «Конкорды» түгел, безнең Ту-144 булачак. Якынча шул ук вакытта Ильюшинның тәҗрибә-конструкторлык бюросында илдә беренче аэробус эскизлары ясала инде – аннары шулардан Ил-86 пәйда булачак...

Барлык бу техника Пётр Дементьев министрлыгында дөньяга килә. Ул – үз заманы министры. Кырыс, авторитар. Аның кайсы карарлары ил авиациясе өчен бик файдалы, кайсылары ялгыш булыр (Аллаһ кына ялгышмый) – дистәләрчә елдан соң гына мәгълүм булачак. Әмма инде алтмышынчы елларда ук шунысы ачык: ул министр булган чорда безнең авиация көнбатышныкына тиң булып тора, бөтен ил исә үзебездә җитештерелгән самолетларда оча.

1960 нчы еллар

БӘХЕТ ТУЛЫ ЕЛЛАР...

Якты, шатлыклы 60 нчы еллар… Аларның кайтавазы безне бүгенгә кадәр озата килә – модалы кием коллекцияләрендә, йорт җиһазлары һәм интерьер дизайнында, музыка һәм кинода. Әле ул гынамы? Ул еллар сәламе – тулы бер микрорайоннар. Бай тарихлы, энергетикалы йортлар. «Җепшеклек» рухы һәм ул буынның тормышны яңартуга һәм яхшы киләчәккә өметләнүенә шаһит өйләр.

Автор:
Алсу Троицкая

1960 елның 17 май иртәсе, Казан. Ларионовлар гаиләсе кечкенә кухняда алмаш-тилмәш иртәнге аш ашый – берьюлы биш кеше бер өстәл артына сыеп булмый. Чәчен күпертеп ясарга өлгергән әни кеше плитә янында мәш килә. Ап-ак нейлон күлмәк кигән әти кеше тәрәзә янында «Известия»нең яңа санын укый: «Ышанасыңмы, кичә Михаил Бонч-Бруевич исемендәге Ленинград электротехник элемтә институтыннан тәҗрибә рәвешендә беренче төсле телетапшыру үткәрелгән! Тиздән төсле телевизорлар да пәйда булыр, мөгаен…»

Йомырка тәбәсе, «докторская» колбасасы һәм көйгән сөт исе тарала. Ә стена артыннан өчпочмак исе «сызып керә» – күптән түгел Казанга күченгән Ибраһимовлар әбиләрен кунакка алып килгән. Ларионовлар белән Ибраһимовларны уртак кухня дивары гына түгел, ә ике гаиләнең дә Ленин районындагы яңа йортка ярты ел элек кенә күченеп керүе берләштерә.

Ларионовларның яңа өч бүлмәле фатиры – чын җәннәт. Иң әүвәл, әлбәттә, аш бүлмәсе. Кечкенә – нибары 5,7 квадрат метр гына, аның каравы, үзебезнеке! Монда ни генә юк: газ плитәсе, савыт-саба юу өчен раковина, шкаф-буфет, тәрәзә астындагы суыткыч, ишек өстендәге антресоль, түшәм астында гына ванна бүлмәсенә караган тәрәзә. Газ колонкасы исә Ларионовларны тәүлек буе кайнар су белән тәэмин итә торган уңайлыкның иң югары ноктасы.

Ә җәмәгать мунчасында чиратта утырмыйча, үз ваннаңда юыну – нинди бәхет, нинди рәхәтлек! Дөрес, ванна бүлмәсе сыерчык оясы кадәр кенә, бәдрәф белән берләштерелгән, әмма анысы мөһим түгел. Монда тагын әле шулкадәр нәрсә куярга мөмкин! Әни кеше күрше хатын аша танышлык белән алган «Волга» кер юу машинасы өстендә эти кеше саллы гына киштә кадаклый. Анда гаиләнең уртак байлыгы – «Зенит» фотоаппаратына төшерелгән фотографияләрне ясау өчен өчен кирәк-яраклар урын ала. Ванна бүлмәсе генә димәгән бит! Безне зал, йокы һәм балалар бүлмәсе кызыксындыра.

Ларионовлар залының диварында – ясанып-бизәнеп төшерелмәгән, аклы-каралы, «тере» фотографияләр, бу һәвәскәр сурәтләр өйгә тормыш рухы һәм җылылык хисе бирә. Биредә үк трюмо бастырып куелган, чөнки үтәли уза торган зал – бер үк вакытта ата-ананың йокы бүлмәсе дә әле. Дивар янында диван-софа торуы әнә шуның белән аңлатыла. Тагын әле шудырып ачыла торган пыялалы ялтыравык сервант, почмакта – торшер, ике кәнәфи һәм озын гына авыш аяклы тәбәнәк өстәл…

Әлбәттә инде, бигрәк тә кызларына бәхет ишелеп килде – Любаның хәзер үзенең аерым бүлмәсе бар. Хәер, җиһазлар малайларныкы кебек үк – бер кешелек караваты һәм гади генә шкаф. Аның каравы, «Кызыл Октябрь» дип аталган пианино бар…

КОММУНИЗМГА КЕРЕШ

Әйе, нәкъ менә 60 нчы елларда «Ларионовлар», «Ибраһимовлар», «Ивановлар» һәм «Әхмәтовлар» гаиләләре бер гаиләгә бер газ плитәсе була алуын, ванна һәм бәдрәфкә чиратта торырга да кирәк түгел икәнен белде. Һәркем аерым фатир ала алсын өчен, рекордлы санда торак төзи башладылар. Үзенчә бер социаль торак революциясе миллионлаган совет гаиләләренә бәхет китерә. Кешеләрнең комму-

Фото: Александр Ефремов, ачык мәгълүмат чыганакларыннан.

– Вот передняя наша, вот и вешалка наша…
Вся квартира наша, наша. Кухня тоже наша, наша…
Наши окна, наши двери. Я глазам своим не верю, –

Дмитрий Шостаковичның «Москва-Черёмушки» опереттасының яңа иҗтимагый күренеш белән бәхеткә күмелгән геройлары әнә шулай дип җырлый иде. Нәкъ менә Черёмушки СССР ның 50 нче еллар ахыры – 60 нчы еллар уртасында эксперименталь торак төзелеше районына әверелә. Биредә беренче биш катлы «хрущёвка»лар күпләп төзелә, аннары алар бөтен Советлар Союзы буенча, шул исәптән Татарстанда да тарала. Шуңа күрә, мөгаен, республиканың теләсә кайсы шәһәрендәге архитектура бездә дежавю халәтен – «моны кайдадыр күргән бар» тойгысын уята.

«Хрущёвка»лар төзелеше.

наль фатирдагы күршеләреннән башка гына шәхси тормыш алып бару мөмкинлеге барлыкка килә.

«БЕР ТӨНДӘ НӘКЪ БЕР КАТКА ҮСӘДЕР БЕЗНЕҢ КАЛА»

– Әйдәгез, Хрущёв индустриализациясе башланганчы, СССР халкының 80 проценты, шул исәптән Татарстанныкы да, ничек һәм нинди шартларда яшәгәненә күз салыйк, – ди Россиянең мактаулы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган төзүчесе **Борис Кадников.** – Бөек Ватан сугышы тәмамланугa бары тик 15–20 ел вакыт узган. Илнең Европа өлешендәге 40% территория 3–4 ел немецлар оккупациясендә булды, йөзләгән шәһәр, меңләгән сәнәгать предприятиесе, заводлар, фабрикалар җимерелгән, яндырылган. Меңләгән торак йорт, мәктәп, хастаханә, колхоз һәм совхозлар ишелгән. Бәхеткә, фашистик Германия ТАССРга кадәр килеп җитә алмады. Ул вакытта СССР хөкүмәте һәм КПСС Үзәк комитеты бар көчне илнең халык хуҗалыгын торгызуга юнәлтте. Һәм эш башкарылды да.

Хрущёв заманындагы төзелешләргә, күпләп йортлар төзи башлаганчы, һәркем диярлек бик кысанлыкта яшәде. СССРда йөз меңләгән гаилә революциягә кадәрге таш йортларда, агач бараклaрда яки хәтта подвалларда урын алган коммуналь фатирларда яши. Ә коммуналкаларда – берничә гаиләгә бер кухня һәм бәдрәф…

Мин Казанга 1958 елда килдем. Хатыным һәм ике игезәк балабыз белән җәмәгатемнең әнисендә 18 квадрат метрлы бүлмәдә яшәдек – Карл Маркс урамындагы 38/5 номерлы ике катлы иске йорт опера театры каршында иде. Әллә ничә бүлмәле озын коридордан гыйбарәт иде ул – бөтен уңайлыклары ишегалдында булган чын кырмыска оясы. Утыз ел элек ул йортны сүттеләр. 1960 елда КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы «СССРда торак төзелешен үстерү турында»гы атаклы карарны кабул итте. Шуннан соң тормышка ашырылган массакүләм социаль төзелеш проекты күп гаиләләргә аерым фатирлар – бушлай торак алырга мөмкинлек бирде.

– 60 нчы еллар башында зур панельле йорт төзелешенең үсеш темплары бүген дә шаккатыра, – дип ассызыклый Борис Александрович. – Аның механизмы күз ал-

«Хрущёвка» йортлар төзү 1959 елда башлана һәм сиксәненче елларда тәмамлана.

Гадәттә, мондый йортларның фатирлары бердән дүрткә кадәр бүлмәле.

1-
бүлмәле фатир
30 м²

2-
бүлмәле фатир
43 м²

3-
бүлмәле фатир
54 м²

Түшәм биеклеге
260 см

Кухня мәйданы
4,5 – 6,8 м²

Бәдрәф һәм ванна бүлмәсе бергә

дында камилләштерелә. Төзүчеләр монтаж эшен шундук үзләштерә барды, хуҗалык хисабындагы беренче бригадалар һәм участоклар барлыкка килде. «Бер төндә нәкъ бер катка үсәдер безнең кала» дигән җыр сүзләре – шул кызу төзелеш вакытыннан. 1961 елда 2 нче трест төзүчеләре өч ай эчендә Совет районында 80 фатирлы биш катлы йорт торгызып, аны файдалануга тапшырды, хәзерге Вахитов районы, Әмәт бистәсе. 1962 елда «Татстрой» идарәсенең беренче тресты коллективы 146 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырды, ә ун ел эчендә төзүчеләр 1 миллион 565 мең квадрат метр торак күтәрде, шул рәвешле дистәләрчә мең казанлы гаиләне яңа фатир белән сөендерде.

Ул вакытта төзелеш 4–5,9 катлы йортлардан гыйбарәт иде. Аз катлы йортлар салу төзелеш темпын тизләтте һәм дәүләткә шактый арзанга төшә иде, чөнки йортлар лифтсыз гына төзелде бит. Һәм тагын бер үзенчәлек – төзелеш комплекслы алып барылды. Торактан тыш, татарстанлылар өчен ел саен йөзләгән мәктәп һәм балалар бакчасы, хастаханәләр һәм сырхауханәләр, сәүдә предприятиеләре һәм клублары сафка бастырылды.

Хәзерге яңа өй-биналар фонында халык «хрущёвка» дип атаган биш катлы өйләр бүген, бәлки, шыксызрак та күренәдер, алардагы фатирлар да заманча фатирлар белән чагыштырырлык түгел. Хәер, һәр нәрсәнең үз вакыты. Әмма нәкъ менә 60 нчы еллардагы зур панельле йорт төзелешенең шундый үсеше бик кискен торган торак проблемасын гына хәл итеп калмыйча, мондый мөһим социаль бурычны алдагы унъеллыкларда да киң колачлы һәм иҗади тормышка ашыру өчен нигез дә салган, дип саныйм. Совет кешесенең тормышы тамырдан үзгәрде.



АЛДА – ЯКТЫ КИЛӘЧӘК

– 60 нчы елларда төзелгән йортлар, аларны ничек кенә сүксәк тә, революциядән соң халык өчен беренче торак булды, – дип саный Казанның хәзерге Мәскәү районындагы Ленская урамында урнашкан шундый өйләрнең берсендә яшәүче **Татьяна Вершинина.** Ул ире белән әлегәчә гомер кичергән фатирны 1962 елның 3 мартында ала:

– Ирем хәрби иде, аны демобилизацияләгәндә, балаларны әнием янына, Псков өлкәсенә кайтарып куйдык. Ә үзебез Казанга күчендек. Восстание урамындагы подвалда кайнана янында яшәдек. Анда 11 квадрат метрлы бүлмәсе һәм кечкенә генә кухнясы бар иде. Ә 1962 елда иремә шушы фатирны бирделәр.

Без бәхеткә күмелдек дип әйтү генә аз. Ул чакта «хрущёвка»лар гына түгел, бараклар да куаныч иде. Иремнең абыйсының гаиләсе баракта тагын ике гаилә белән бергә яши иде. Барысының да балалары бар. Аларның «диварлары» урынына – шифоньерлар һәм кара пәрдәләр. Уңайлыклардан шул электр уты гына. Суны колон-

60 нчы елларда ярдәмче хуҗалык алып бару максатыннан җир кишәрлекләре өләшү дәвам итә. Ул вакытта күп кенә татарстанлыларның да бакчалары, дачалары барлыкка килә. Дөрес, бер гаиләгә 6 сутый гына бирелә. Тик, икенче яктан караганда, яшелчә, җиләк-җимеш, яшел тәмләткечләр үстерү өчен бу бик җиткән. Өстәвенә, бакча кишәрлекләре эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә файдалану өчен чикләнмәгән вакытка бушлай бирелә.

кадан ташыйлар, ашарга керогаз белән әзерлиләр. Ә бөтен Казан, бөтен Татарстан халкы кебек үк, җәмәгать мунчаларында юынды. Бөтен ил буенча шулай булды… Һәм менә без фатирлы булдык, ремонт ясадык, җыештырдык, аз-маз җыелган акчага күпмедер җиһазлар да сатып алдык. Шунда ук әнием Казанга балаларыбызны алып килде.

Минем өчен ул вакыт – һәркем дә бер төрлерәк яшәгән чор, – дип елмая Татьяна Константиновна. – Һичкемнең артык мөлкәт-байлыгы чекерәеп тормады. Фатирлар бикләнми иде диярлек. Кемнән? Өстәлләр бик еш зурайтыла, күчерелә иде – кунаклар күп килә. Аларны тозлы кәбестә һәм кайнар бәрәңге белән сөенә-сөенә каршылый, сыйлый идек. Үзебез дә кунакка йөрдек. Болай гына, сөйләшер-аралашыр өчен. Бер атна алдан телефоннан шалтыратып, кисәтеп тормыйча гына.

Ишегаллары. Агачтан агачка кер бавы суза идек. Һәр гаиләнең үз бавы бар. Ишегалларында агачлар утырттык. Без бирегә күченгәндә, монда шәхси йортлар тора иде. Тирә-яктагы биш һәм тугыз катлы йортлар соңрак калкып чыкты. Агач бура өйләрдә яшәгәннәрнең күбесе хәзерге Ленская, Декабристлар һәм Тверь урамнарына күченде. Агачлар, куаклар һәм чәчәкләр – боларның барысын да үзебез утырттык. Элек ишегалдына агач утыртырга һәркем чыга иде – бала-чагадан алып иң өлкән яшьтәгеләргә кадәр.

Гомумән, 60 нчы елларда күпләрнең бакчасы пәйда булуга карамастан, ишегалды безнең өчен аерым дөнья кебек иде. Ишегалдында һәрвакыт кем дә булса бар иде: әбиләр дисеңме, комлыкта уйнаучы сабыйлар һәм әниләрме, домино һәм кәрт сугучылармы. Яхшы, һәркемгә аңлаешлы тормыш иде. Агачлар утырттык, балалар үстердек һәм алар коммунизмда яшәячәгенә чын күңелдән ышандык. Алда безне якты киләчәк көтә иде. Бәхет тулы еллар… Т

Мондый «типлаштырылган» проект буенча салынган йортларның якынча хезмәт итү вакыты – 100 ел. 50 елдан соң тулы капиталь ремонт уздырган очракта. Финляндия һәм Германиядә панель йортлар бүген дә әр-яңа кебек күренә. Кайчак аларны тыштан җылыталар, бу очракта хезмәт итү вакыты тагын да арта.

1960 нчы еллар

ЯКТЫ КИЛӘЧӘК НИЧЕК ТӨЗЕЛГӘН

Сталин ампирлары юкка чыксын! 1960 нчы еллар – космик биеклекләрне яулаган, таң калдыргыч фәнни ачышлар, мәдәни революцияләр ясаган һәм яңа, җиңел архитектурага өстенлек биргән чор. Шул вакытта Казанда күп кенә бүген безнең күзне ямьләгән объектлар төзелә. Аларның кайберләрен соңрак совет модернизмы дәверенең шедеврлары дип атаячаклар.

Автор:
Катерина Котова

«КОСМИК» МАСШТАБЛЫ

Автобус Казанның Ярминкә мәйданыннан узып бара. Сигезенче сыйныфта укучы Валя Слесарева көн саен шул автобуста мәктәпкә барганда, Казан Кремле итәгендә урнашкан ниндидер гадәти булмаган төзелешне күзәтә. Әле кайчан гына җирдән тимер казыклар чыгып тора иде, хәзер алар урынында галәмәт зур тәлинкә барлыкка килде! Аннан соң ул тәлинкә өстенә шундый ук зур гөмбәз капладылар. «Ул гаҗәеп бер нәрсә булачак, ниндидер космик нәрсә!» – дип сөйли кыз, таң калып, әти-әнисенә...

«Ниндидер гаҗәеп нәрсә» дигәне яңа цирк проекты була. Чыннан да, анда бөтенесе дә шаккатмалы – объектның архитектурасыннан алып, аны төзү тарихының буеннан-буена хакимлек сөргән авантюризм шаукымына кадәр.

Яңа цирк төзелешенә рөхсәтне хакимият 1963 елда ала. Ярославльдә шундый бер цирк бар инде – казанлыларга проектны кабатлыйсы гына кала. Әзер сызымнарны җирлеккә һәм инженерлык челтәрләренә яраклаштыру эшен «Татаргражданпроект» институтына йөклиләр. Ул вакытта аның белән Үзбәк Алпаров җитәкчелек итә. Әмма архитекторлар әллә ни күзгә бәрелеп тормаган проектны кабатларга бер дә атлыгып тормый. Һәм үзләренекен уйлап чыгарырга карар кыла.

ДӨНЬЯДА БЕРДӘНБЕР

Әллә никадәр рәсем һәм эскизлар арасыннан берсе – архитектор Мөнир Хәйруллин уйлап чыгарганы аерылып тора. Рәсемдә – әйләндереп куелган кисек конус, өстенә гөмбәз капланган. Кыяфәте белән оча торган тәлинкәне хәтерләтә, бер күргә истә кала торган. 60 нчы елларның космос темасымы? Нәкъ үзе! Техник ягын хисаплауларга күчәләр.

«Исәп-хисапта иң кыены конус үзе булды, тамашачылар өчен күпсанлы ишек-уемнар, киң форганг (артистлар өчен уем), оркестр өчен раковина – болар барысы да конус стеналарының ныклыгына зыян сала иде, – дип искә ала ул чакларны Үзбәк Алпаров. – Безне шулай ук конусның чагыштырмача сөзәклеге дә борчыды – нибары 30 гына градус».

Моңа охшашлы проектның әле дөньяда булганы булмый! Бразилия хөкүмәтенең данлыклы архитектор Нимейер авторлыгында төзелгән, тар ягына утыртылган кисек конус формасындагы бинасы гына кайсыдыр ягы белән Казан идеясен хәтерләтә. Тәҗрибә уртаклашыр өчен Бразилиягә үк китмәссең бит инде! Үтә дә катлаулы аналитик исәп-хисаплар ясалып, модельләрдә сынаулар үткәрелә, шулай ук Киевта электрон-хисаплау машиналарында санап чыгаралар. Останкино телевизион башнясы авторы профессор Никитинның язмача биргән йомгаклау сүзе генә ни тора! Ул да Казан архитекторларының кыюлыгына сокланган.

Ләкин төзелешне финансларга тиешле Союзгосцирк проектны



кабул итәргә теләми. Ул чагында Ярминкә мәйданындагы «оча торган тәлинкә» ничек барлыкка килгән соң? Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты тарихының музее сайтында Үзбәк Алпаровның… сызымнарны алыштыруы турындагы хатирәләре сакланып калган. Ягъни Казан өчен яраклаштырылган Ярославль проектын раслап, Алпаров төзүчеләргә өлешләп-өлешләп… Казан идеясенең сызымнарын бирергә карар кыла. Эш башлана! Хәйлә булачак бина тәлинкә кыяфәтен ала башлагач ачыла. Билгеле, гауга куба. Шул вакытта архитекторларны КПСС шәһәр комитетының беренче секретаре Рәшит Мусин яклап чыга. Шәһәрдә уникаль объект булуын проект авторлары гына теләми бит…

СОЛДАТЛАР БЕЛӘН… СЫНАУ

1967 елның ноябрендә төшерелгән фото. Анда – циркның эчке ягы, ул тамашачылар белән шыгрым тулы. Юк, гади тамашачылар түгел алар. «Тере йөк» файдалану карарын КПСС шәһәр комитеты кабул итә. Шулай итеп, ком тутырылган капчыклар урынына залны ике мең солдат һәм Суворов училищесының югары сыйныф укучылары белән тутыралар. Сынау үткәрүчеләр әйтүгә, хәрбиләр кычкыралар, кул чабалар, аяк тибәләр – имештер, моның өчен аларны вакыт-вакыт циркка бушлай тамаша карарга чакырачаклар.

Солдатлар зал тутырып утырган арада экспертлар үтә дә катлаулы исәп-хисап эшләре алып бара – уникаль бина формасын үзгәртмәдеме, тулы көенә сынау үтә алдымы? Үтә! Ә аңа кадәр күпме бәхәсләр һәм куркулы-шөбһәле көннәр кичерергә туры килә! Проектлаган архитекторлар үзләренең хаклыгына ышанса да, төзүчеләр бертуктаусыз шик белдереп тора. Бер очрак булмаса – дөнья әлеге «тәлинкә»не күрә алмый калыр иде.

– Конструкцияне күтәргәндә, төзүчеләр аны бөтен әйләнәсе буйлап металл баганалар белән әйләндереп алды, – дип сөйли «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесенең баш архитекторы Герман Бакулин. – Бетон койдылар, шуннан подрядчы оешманың җитәкчесе, билгеле төзүче: «Терәү булып торган баганаларны алмыйбыз, алай ышанычлырак. Аларны пыяла белән каплап була, менә дигән цилиндр килеп чыгачак, өстә исә гөмбәз – матур!» – ди.

Төзүчеләр тәкъдим иткән нәрсә нефть саклау өчен газгольдерга охшаган иде. Андый нәрсә безнең нәфис Кремль янәшәсендә торырлык бизәк була аламы соң инде? Әлбәттә, безгә шок булды.

КЫЮЛЫК ӨЧЕН БҮЛӘК БУЛЫП…

Шулай килеп чыга: гаҗәеп бинаның язмышын кешеләр хәл итми. Хәтердә кала торган шушы бәхәстән соң берничә көн үткәч, көтелмәгән хәл килеп чыга. Бетон каткан арада үзенең кыяфәтен үзгәртә. Нәтиҗәдә, бинаның билбау озынлыгы 30 сантиметрга кыскара, һәм өстәге терәк божра терәүләрдән аерыла – аларның кирәге калмый. Проектлаучыларның шатлыгының чиге булмый – аларның исәп-хисаплары дөрес, димәк. Шәһәр уникаль бинаны булып кала, дөнья моңа кадәр күрелмәгән архитектура энҗесенә байый.

Казан циркын совет модернизмы дәверенең шедевры дип атая-



«Оча торган тәлинкә» Казанга «Татаргражданпроект» институты директоры Үзбәк Алпаровның һәм аның җитәкчелегендәге кыю архитекторлар – Валентина Панова, Геннадий Пичуев, Осия Берима, Ефим Брудныйның тәвәккәллеге нәтиҗәсендә «төшеп куна».

СПОРТ ТОРМЫШЫ ҮЗӘГЕНДӘ

чаклар. Аңа сокланып кына калмыйлар, аны кабатлаячаклар. Иҗади кыюлык өчен проект авторларына СССР Министрлар Советының премиясе биреләчәк.

...Цирк төзелешен күзәтеп барган Валя Слесарева аның ачылышын әле дә хәтерли. Ул вакытта аренада дрессировка остасы Наталья Дурова чыгыш ясый – яшь, күз явын алырлык көлмәктән! Ә аның хайваннары ни генә эшләп күрсәтми! Диңгез арысланнары кыршау әйләндерә һәм команда буенча ишкәк аяклары белән кул чапкандай итә. Тамашаны Валя сыйныфы белән карый.

1960 елның августы. Трибуналар шыгрым тулы. Казан «Искра»сы үзендәге Каменско-Уральскиның «Металлург»ын ышанычлы итеп җиңә ул чакта. Бу Казанның яңа гына ачылган Ленин исемендәге Үзәк стадионындагы беренче матч...

– «Искра» белән «Металлург» уенын карарга дип бөтен ишегалды белән килдек! – дип хәтерли ул көнне Сергей Архипов. Аңа 1960 елда тугыз яшь булган. – Көнчыгыш трибунада утырдык. Халык һәр матчка стадион тутырып йөрде – бөтен танышыңны очратырга була иде анда! Стадионга керә торган капкаларны пилоннар бизи. Түндырма – эскимо, пломбир саталар... Өлкәннәр өчен – сыра...

Стадион төзелешенә архитектор Владимир Портянкин җитәкчелек итә. Ачылыш Ленинның 90 еллыгына туры килә, һәм стадионга дөнья пролетарийларының юлбашчысы исемен бирергә карар итәләр. Ә менә архитекторлар һәм төзүчеләр стадионны үзара әле озак еллар Казан «Лужникие» дип йөртә.

– Стадион 1960 нчы елларның җиңелчә модернистик формалары буенча төзелде – ул яңа архитектура, гади, бер җире дә артык булмаган, заманча эзләнүләр чоры иде, – дип сөйли Герман Бакулин. – Хәтердә: безгә, булачак архитектор-студентларга, үзәк өлештәге трибуналар өстендә зур кошны хәтерләткән төз лапас, зур пилонлы капкалар, тулаем күренешне капламый торган рәшәткәле биек коймалар искиткеч зур тәэсир калдырган иде.

ДӨНЬЯКҮЛӘМ ҖИҢҮЛӘРГӘ ХИРЫСЛЫК

– Стадион тиз арада якын-тирә йортларда яшәүчеләрнең тормыш үзәгенә әйләнә, хәер, аларныкына гына да түгел. Ул беркайчан да буш тормый иде, – дип хәтерли Сергей Архипов. – Төп кыр матчлар вакытында гына ачылса, тренировкалар кырына теләсә кайчан кереп була. Малайлар гына түгел, зурлар да футбол уйный. Урын барысына да җитә. Капкаларны кирпеч белән генә билгеләп куясың да – хәлдән таеп егылганчы уйна! Кышларын запас кырда боз катыралар – футболга алмашка хоккей килә. Төп кырда, төньяк трибуна янында, хоккей тартмасы куялар, һәм халык Урицкий исемендәге СК уеннарына (хәзерге «Ак Барс») йөри.

Казанның меңъеллыгы алдыннан Үзәк стадионны реконструкцияләү турында сүзләр йөри башлады. Бу вакытка инде ул концептуаль яктан искергән һәм шактый тузган иде. Өстәвенә «Рубин» Премьер-лигага чыкты, үзендәге аренасы яңа кырыс таләпләргә туры килергә тиеш дип табылды. Иң яхшы реконструкция проекты халыкара конкурсында «Татинвестгражданпроект» җиңеп чыкты. Нәтиҗәдә стадион башка архитектур кыяфәттә яңа тормыш белән яши башлады. Реконструкция өлешләп башкарылды, димәк ки, «Центральный»да матчлар өзлексез үтә ала иде.

Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты: амфитеатр янәшәсенә төзелгән корылма нәтиҗәсендә трибуна астында пространство барлыкка килә, анда административ кабинетлар, спорт заллары, буфетлар, кассалар, Кремльгә карап торган галерея урнаша... Стандартларга ярашлы, көнбатыш трибуналарда ВИП-персоналар өчен урыннар барлыкка килә. Яктырту көчәйтелә. Иң мөһиме: стадионга яңа чирәм түшәлә! Искесе белән проблемалар шактый була – газон тиз таптала, пеләшләнә. Махсус эшләнгән яңа чирәм япманың мондый җитешсезлекләре юк.

Стадионны реконструкцияләгәннән соң, җиңел атле-

ПЫЯЛАДАГЫ МУЗЫКА

тика манежы төзелеше башлана, ул 2007 елның августында ачыла. Тагын өч елдан соң Казанга УЕФА инспекторлары килеп төшә, алар объектка уңай бәя биреп, дүртенче – иң югары категорияне биреп китә. «Центральный»ның яңа тормышы әнә шулай башлана, анда УЕФА һәм ФИФА канаты астында үтә торган иң эре ярышлар дәрте дә, җиңүләре дә булачак әле, дип ышанырга җөрьәт итәбез.

ПЫЯЛАДАГЫ МУЗЫКА

Пыяладан гына торган өч кат – архитектура телендә бу гүя дөньяга ышаныч гимны. Тыштан караганда, Казан консерваториясенең Актлар залы бинасында рәхәт һәм җылы дигән тәэсир генә кала! Халык аны «стекляшка» – «пыяла» дип кенә йөртә...

1967 елда Казанда гадәти булмаган (ул чорда беренче!) пыяла бинаның барлыкка килүе консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов белән проектның авторы архитектор Мөнир Агишев исеме белән бәйле. Ректор бик зур тырышлыклар куеп, Мәскәүдән әлеге төзелешкә рөхсәт алуга ирешә, архитектор яңа стиль идеясен тормышка ашыра.

– Элек биналар ныгытма кебек кабул ителә иде – калын диварлар, ныклы түбәләр... Фасадларны классик рәвештә кору ысулы шундый булган. Әлеге империалистик стильне Иосиф Виссарионович та хуплаган, – дип сөйли Герман Бакулин. – Ләкин Агишевның консерваториядәге Актлар залын бөтенләй башка стильдә – җиңел, үтәкүренмәле итеп эшлисе килде. 1960 елларда андый демократик архитектура модага кереп килә иде инде. Аның идеясе мондый: кешеләр әйләнә-тирә дөньядан куркырга тиеш түгел, бинада булып та үзләрен шәһәрдәге хәрәкәтнең бер өлеше итеп тойсыннар, һава торышындагы үзгәрешләрне сиземләрлек булсын. Әлеге яңа стиль сыйфат ягыннан да, хис-кичерешләр куәсе ягыннан да башка төрле иде.

Кирпеч яки бетон диварлар урынына – пыяла? Шәп! Тик әгәр дә бүген әлеге «көпшәк» идеяне пыяла пакетлар һәм тыгызландыруның заманча системалары ярдәмендә тормышка ашырып

Фото: caparol.ru

булса, 1960 нчы елларда төзүчеләргә баш ватарга туры килә. Алга куелган бурычны ул вакытта мөмкин булган юллар белән хәл итәләр: витраж конструкцияләрен корыч прокаттан эшлиләр, баганаларын «эретепябыштыралар», арага туры китереп, җилем кыстыралар… Периметр буенча бинаны ике кат пыяла хисабына киңлеге 60 сантиметрлы һава мендәре белән әйләндереп алалар. Якты да, җылы да килеп чыга. Сүз уңаеннан, шулай ук «музыка гыйбадәтханәсе» төзелешендә төзүчеләргә консерватория студентлары үзләре дә булышкан, диләр.

Яңа залны шәһәр халкы, нигездә, җылы кабул итә. Итмәскә ни, мондыйны күргәннәре дә юк иде бит әле! Өстәвенә, шәһәр үзәгендә урнашкан, ул вакыт өчен үтә дә заманча бина тарихи ансамбльгә дә комачаулык итми: төзелеш сызыгыннан тыйнак кына берничә метр эчкәрәк кереп тора. Бу да яңа сүз була ул вакытта! Залның эче дә шундый ук тыйнак һәм гадәти түгел. Аның эскизларын Мөнир Агишевның хезмәттәше һәм хатыны – Инга Агишева уйлап чыгара. Аның нигезендә үсемлек мотивлары ята – бинаның заманча интерьерларына милли төс биреп тора.

Ул вакытта әлеге идеяне тормышка ашыру буенча кыенлыклар да туа, дип искә ала архитекторларның сөйләгәннәрен Герман Бакулин. Күн банкеткаларны һәм башка җиһазларны эшләргә Казан тире эшләнмәләре комбинатына заказ бирәләр. Предприятиенең мондый масштаблы эшләрне беренче тапкыр башкаруы була. Эре масштабта яфраклар, йөрәкләр, «кыярлар» тегү җиңел түгел – техник базаның куәте җитеп бетми. Әмма комбинат бу эшне башкарып чыга, ә тәҗрибәнең алга таба – Камал театры бинасын бизәгәндә кирәге чыга.

«ТАВЫШЫ ГАЛЕРКАГА КАДӘР ИШЕТЕЛӘ!»

Казан консерваториясенең Актлар залында беренче концерт 1967 елның 8 декабрендә була. Сәхнәдә филармониянең Натан Рахлин җитәкчелегендәге симфоник оркестры чыгыш ясый.

Әйтергә кирәк, ике коллектив – консерватория белән филармониянеке – пыяла бинада әле озак еллар бергәләшеп иҗат итә, аларның музыкаль максатларын тормышка ашыру өчен бик туры килә торган бина була ул.

– Акустика ягыннан зал бик әйбәт иде, – дип сөйли ТР ның атказанган артисты, Казан консерваториясе профессоры Нина Варшавская. – Тавыш галеркага кадәр ишетелә! Диварлар агач белән эшләнгән, балкон да, тавыш йота торган йомшак кәнәфиләр дә юк. Бернинди тавыш чокырлары юк! Мондый залда җырлавы рәхәт, тавыш турында кайгырасы юк – бик яхшы ишетелә иде. Ихтимал, уңайлылык һәм матурлык ягыннан кайтыш булгандыр, әмма ул вакытта безне ул ягы кызыксындырмый иде. Зал безнеке – консерваториянеке, ул студентлар һәм мөгаллимнәр өчен ачык. Без анда репетицияләр ясый, концертлар куя, имтиханнар һәм сынауларны җырлап бирә ала идек. Вакытлар узу белән аны үзгәртеп корырга кирәк булды, һәм без аны консерватория милеге буларак югалттык. Без аңа ияләнгән идек инде, шуңа да, югалткач, бик кыен булды. Безнең иске залыбыз турында бары тик якты һәм рәхәт хатирәләр генә калды.

ВАКЫТ СЫНАВЫН ҮТКӘН

Пыяла бина вакыт сынавын уза алмый. Техник яктан гына да түгел. «Башкача пыяла биналар кирәк түгел!» – дип күрсәтмәләр яза архитекторларга Дәүләт төзелеше. Чыннан да, алар артык күп булып китә, һәм алар янында консерваториянең беренче залы заманчалыгын югалта. Үзгәрешләр чоры, төгәлрәге, үзгәртеп корулар заманы килә. Пыяла биналар өчен генә түгел – урамда 90 нчы еллар!

Консерваториянең яңа ректоры Рубин Абдуллин яңа зал төзү идеясе белән озак яна. Республика җитәкчелеге аны ишетә. Җитәкчелек кенә дә түгел. Яңа Зур Концертлар залы төзелешенең дә үзенең кызыклы тарихы бар. 1993 елның җәендә залда республиканың яңа гимнын, дөресрәге аның конкурска килгән вариантларын тыңлыйлар. ТР Югары Советының халык депутатлары тыңлый. Таушалган залда гимнның тантаналы яңгырашы ничектер тоныкланып калгандай тоела. Депутатлар да сизә моны… Ихтимал, нәкъ менә шул көннән соң Абдуллинны хуплаучылар арткандыр да.

Бүген әлеге тантаналы зал бернәрсәсе белән дә теге пыяла бинаны хәтерләтми инде. Шулай да ул тере әле. Дәүләт статусы алган заманча Зур Концертлар залының тын гына торган дивар конструкцияләрендә, гүзәл Казаныбыз тарихында яңа музыкаль дәвер өчен рәхмәт хисен саклаган кешеләрнең хатирәләрендә саклана ул.

1960 нчы еллар. Казан, Ленин урамы. Сәлимхан Насыйбуллин фотосы.

ТОРМЫШНЫҢ МӘКТӘПКӘЧӘ ЧОРЫ

Узган гасырның 60 нчы елларында Казанда яшәгән бер гаиләгә фотосәяхәткә чыгабыз. Андый фотосурәтләр гадәттә бәрхет белән тышланган калын альбомнарда саклана. Алар теләсә кайсы вакытта үзләрен сак кына алып караганны көтеп, караучыны үткәннәргә алып китәргә әзер. Алар җуелмый, бозылмый, юкка чыкмый. Нибары тагын йөз-ике йөз елдан соң саргаерга гына мөмкиннәр.

60 НЧЫ ЕЛЛАР УРТАСЫ

НӘРСӘ КҮПМЕДӘН

АЗЫК-ТӨЛЕК БӘЯЛӘРЕ

- Арыш ипие *14–16 тиен.*
- «Подмосковный» күмәче *22 тиен.*
- Кибеттә сыер ите (еш кына булмый) *2 сум 30 тиен.*
- Базарда сыер ите (килограмм) *5 сум.*

Фото Гадел Хәиров архивыннан

1962 ел. Үзәк загста никахлашу тантанасы. Кияү – Рево, кәләш – Рәшидә. Икесе дә инженерлар.

1961 ел. Ленин бакчасы. Валерий Грязнов фотосы.

10 нчы автобус.

1967 ел. Ана белән бала.

Безнең автор Гадел Хәировның альбомына беренче йөз еллык куркыныч түгел. Альбом да, Гадел дә яшь әле, аларның гомере гасырлар белән үлчәнми. Еллар белән генә – биредә сезнең алдыгызда безнең автор һәм аның мәктәпкә кадәрге чорында үз күзләре белән күргәннәре.

- Югары сортлы пешкән казылык *2 сум 60 тиен.*
- Беренче сортлы пешкән казылык *2 сум 10 тиен.*
- Сөт, литр *28 тиен.*
- Җиләк-җимешле туңдырма *6 тиен.*
- «Эскимо» туңдырмасы *22 тиен.*
- Газландырылган шифалы су (автомат) *1 тиен.*
- Куе ширбәтле газландырылган су (автомат) *3 тиен.*
- Атланмай *3 сум 50 тиен.*
- Мичкәдән куас (0,5 литра) *6 тиен.*
- «Московская» аракысы *2 сум 87 тиен.*
- Ашханәдә горчица *Бушлай*

ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ХАКЛАРЫ

- «Саратов» суыткычы *150 сум.*
- «Романтик» магнитофоны *160 сум.*
- «Харьков» телерадиоласы *360 сум.*
- Олылар велосипеды *49 сум.*
- Кино билеты *25 тиен.*
- Газета *2–3 тиен.*
- Җәмәгать мунчасында юынып чыгу *15 тиен.*
- Мәктәп ашханәсендә туклану *15 тиен.*
- Трамвайда бер тапкыр бару *3 тиен.*
- Автомат телефоннан шалтырату *2 тиен.*
- Шырпы *1 тиен.*

БУШ ШЕШӘЛӘРНЕ ПЫЯЛА САВЫТ-САБА КАБУЛ ИТҮ ПУНКТЫНА ТАПШЫРЫРГА МӨМКИН

- Аракы яки лимонад шешәсе *12 тиен.*
- Кефир шешәсе *15 тиен.*
- Сөттән бушаган литрлы шешә *20 тиен.*
- Каймактан бушаган пыяла шешә *10 тиен.*

УРТАЧА ХЕЗМӘТ ХАКЫ – (1965 елгы мәгълүматлар) *92,5 сум.*

Бауман урамындагы атаклы кытыршы кибет.

Бауман ур. ТЮЗ актёры А. Купцов архивыннан.

Дустым Федя Чумаков һәм Ленин бакчасындагы Тюлень фонтаны.

1969 елгы мода. Мәктәпкә барыр алдыннан.

Студентлар йөри торган 2 нче трамвай.

Свердлов ур., Карл Маркс бюсты урнашкан сквер.

«Хезмәт резервлары» боксчылары. М. Горький исемендәге парк.

БАТЫРША: БАШ КҮТӘРҮЛӘР ТАРИХЫННАН

Тарихта Батырша һәм аның артыннан баш күтәргән халыкның нинди эз калдыруы – бүген дә бәхәсле мәсьәлә. Россия тарихында алар, әлбәттә, түнтәрелеш китереп чыгарып, гадел җәзага тарыган җинаятьчеләр буларак кабул ителә һәм сурәтләнә, әмма милли күзлектән һәм дә түбән катламнар күзлегеннән караганда, аларны каһарман дәрәҗәсенә күтәрәләр. Ничек кенә булмасын, объектив бәя урталыкта ята. Әмма алардан соң булган үзгәрешләрнең азмы-күпме халыкка иркенрәк суларга мөмкинлек бирүен дә онытмыйк.

Автор:
Илшат
Фәйзрахманов

XVIII гасыр уртасы – Идел-Урал төбәгендә вакыйгаларга бай чор. Патша хөкүмәтенең кысрыклауларыннан Казан, Түбән Новгород һәм Урта Идел буе төбәгенең башка якларыннан качып килгән халыкларны сыендырган Башкортостан җирләрендә хәлләр аеруча киеренкелек ала. Киеренкелек җирле администрациянең иркендә яшәргә өйрәнгән бу як халыкларына карата контроле көчәю сәбәпле дә үсә. Шушы җирләрдә 1735 елда Акай һәм Килмәк абыз, 1740 елда Карасакал җитәкчелегендәге баш күтәрүләр тикмәгә генә килеп чыкмый. Әлеге халык чыгышлары патша гаскәрләре тарафыннан аеруча кырыслык белән бастырыла: 696 татар һәм башкорт авылы яндырыла, 17 меңгә якын кеше җәзага тартыла, аларның 9 меңнән артык хатыннары, хатын-кыз туганнары, балалары алпавытларга коллыкка бирелә, каторгага 3400 дән артык кеше җибәрелә. Башкортлар белән татарлар арасында никахларны тыю һәм чикләү, башкорт җирләрен сатып, аларны баш күтәрүне бастыруда актив катнашкан мишәр старшиналарына бирү, рус булмаганнарга икмәк салымын ике тапкыр арттыру турында указлар чыга. Боларга дини изү дә өстәлә – мәҗбүри чукындыру кампанияләре берсе артыннан берсе үткәрелә. 1742–1744 нче елларда Тирсә волосте крестьяннарының алпавыт Тәфкилевләргә каршы яңадан баш күтәрүләре була.

ХАЛЫК АРАСЫНДА ЙӨРЕП...

Гади халыкка хакимият басымы көчәя генә барган әлеге шартларда яңадан-яңа баш күтәрүләрнең котылгысызлыгы билгеле. Мәйданга халык массаларын ияртеп башлап йөрүчеләр дә чыга. Себер юлы мөселманнары ахуны булып сайланган Габдулла Галиев (Батырша) 1755 елгы баш күтәрүнең идеологы булып танылa. Габдулла Нижгар якларыннан күченеп килгән мишәрләр нигезләгән Карышбаш авылында (хәзерге Башкортостанның Балтач районы Югары Карыш авылы) 1710 елда Туктаргали абыз (мулла) гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылларында алып, ул чорда танылган Тайсуган мәдрәсәсендә (хәзерге Татарстанның Әлмәт районында), аннары Ташкичү мәдрәсәсендә (хәзерге Татарстанның Арча районында) укый. Инде 34 яшендә

үз якларына якынрак якта – Гәйнә волосте Күземъяр авылында (хәзерге Пермь өлкәсенең Барда районында) һәм Исәт провинциясендә Мөслим Аширов старшинаның йомышлы татарлар яшәгән Олыкош авылында (хәзерге Чиләбе өлкәсенең Кунашак районында) мәдрәсәдә укыта, мулла хезмәтләрен башкара. 1749 елда, туган авылы Карышбашка кайтып, шул ук мулла, мөдәррис вазыйфаларына керешә. Ул ислам динен, шәригать законнарын бик тирән белүче буларак тирә-якта шөһрәт казана. Төрле хокукый мәсьәләләрне чишү буенча аның янына еш киләләр. Батырша дигән кушаматы да аның зур гәүдәле, физик яктан көчле, сүз көрәштергәндә дә курыкмыйча үз сүзендә нык тора торган булганы өчен бирелгән.

Батырша – 1730–1740 нчы елларда булган күтәрелешләрнең замандашы, ул патшага тугрылыклы һәм ачулы халык катламнары арасындагы каршылыкларны, качаклар, ярлы-ябага тормышын үз күзе белән күреп үскән. Ул әлеге халык күтәрелешләренең бастырылуларын, көчәеп китә алмауларының төп сәбәбен баш күтәрүчеләрнең таркау хәрәкәт итүендә, аларны алып баручы көчле җитәкчеләр булмауда күрә. Шуңа да халык күтәрелеше яңадан да була калса, аның җиңеп чыгуы өчен, халык белән оешкан төстә җитәкчелек итәргә сәләтле кешеләр килеп чыгар, дип өметләнә. Ул Башкортостандагы төбәкләр буенча күп йөри, урындагы хәлләрне күзәтә, бердәм эш йөрткәндә генә күп гасырлар буе тилмерткән рус администрациясенә каршы уңышлы көрәшеп булачак дигән фикерне кискен итмичә генә вәгазьләрендә халыкка җиткереп йөри. Ахрысы, болай итеп кенә изелгән халык аңында тамырдан үзгәрешләргә ирешү мөмкин булмагандыр. Ахыр чиктә, төбәктә яшәгән рус булмаган халыкларның (башкорт, татар, чуваш, мари, удмурт) баш күтәрүе рус администрациясенә һәм аның «верныйларына» гына каршы түгел, кяферләргә каршы көрәш рәвешен дә ала.

БАТЫРША ӨНДӘВЕ БЕЛӘН...

1755 елның мартында Батырша баш күтәрүчеләргә өндәмәсен төзи башлый. Восстаниенең башлануын 3 июльгә билгелиләр, аңа Урта Идел төбәге, Уралдагы халыклар да кушылыр дип уйланыла. Батырша – моңарчы вәгазьләр генә укып йөргән мулла – кулына корал алып баш күтәрүчеләрне турыдан-туры җитәкләмәгән, шулай да халык аны башлап йөрүче буларак кабул иткән. Әмма хәлләр башта уйланылганча гына бармый. Изүгә-мәсхәрәләүләргә түземе калмаган Бөрҗән волосте башкортлары кыйммәтле ташлар эзләп йөрүче Брагин исемле начальникны һәм аның экспедициясен нәфрәтләнеп тар-мар итәләр. Әмма бу хәл аерым бер волостьта гына була, башкалар кушылырга әле вакыт җитмәгән. Шуңа Бөрҗән волостенә патша гаскәрләре килеп тула – башкортлар качышып бетә, кача алмаганнарын тоталар, зинданга ябалар. Башка төбәкләрнең баш күтәрүе бераз соңара.

Фиринат Халиков иллюстрациясе

8–9 августта яңа күтәрелеш Ногай юлының башка волостьларына да күчә. Урыннарда патшага тугрылыклы старшиналар алына, кайбер металл ясау заводлары, крепостьлар туздырып ташлана. Әмма баш күтәрүчеләр таркау була. Шәхси сәбәпләр аркасында үзләре коралмаган алпавыт-феодалга каршы гына күтәреләләр, еракгагыларга ярдәм итәргә ашкынып тормыйлар.

Баш күтәргән башкортлар, яхшы әзерлекле патша гаскәрләре белән турыдан-туры очрашмас өчен, элек-электән казах далаларына китеп-кайтып торганнар. Бу юлы да шул ук тактиканы кулланырга телиләр. Әмма хәлләр башкача килеп чыга. Оренбург губернаторы Неплюев казах ханы Нурали белән килешү төзи: аның үзенә рус хөкүмәте елына 600 сум түләп тора башлый, казахларны төрлечә үз якларына авыштыралар, күченгән башкортларны үз коллары итеп тоту уен башларына сеңдерәләр. Шуңа казахлар белән башкортлар арасында, шулай ук башкортларны яклаганнары белән якламаганнары арасында каршылыклар үзара сугышларга кадәр барып җитә. Шулай итеп баш күтәрүчеләрнең бер төп терәге җимерелә.

1755 елның август ае ахырында Гайнә волосте башкортлары да күтәрелә, әмма шулай ук таркау хәрәкәт итәләр. Үзләре арасындагы «верный»лар, киресенчә, баш күтәрүчеләргә каршы торалар. Гайнә волостендагы баш күтәрү озакка сузылмый, башка җирләргә дә таралмый. Хөкүмәт баш күтәрүчеләргә өндәмәләр язып ятучы Батыршаны тотып бирүчегә 500 сум (аннары күләме 1000 сумга кадәр арттырыла) акча вәгъдә итә. Үз авылы Карышбашта аның йортын халык камап ала, әмма берсе дә Батыршага каршы чыкмый, гаиләсе, шәкертләре белән урманга качарга комачауламыйлар. Батырша, эзәрлекләүләрдән качып, якыннары белән Агыйдел урманнарында яши, бер авылда баз казып, кышны шунда уздыра. Хатынын, балаларын, шәкертләрен дә тотып бетерәләр. Инде гаделлек белән идарә итүче дип уйлаган патшабикәгә үз гозерләрен җиткерергә теләп кулга бирелергә була. Хәзерге Башкортостанның Борай районы мишәр авылы Әҗәктә кулга эләктереп, аны Уфага озаталар, аннан сак астында Петербургка җибәрәләр.

ГАДЕЛЛЕККӘ ӨМЕТ ИТЕП...

Батырша патшабикә белән шәхсән очрашуны сорый, әмма, билгеле булганча, дәүләт җинаятьчесе дип танылучыдан допрослар гына алалар, Императрицага җиткерәбез, дип ышандыргач, Батырша патшабикәгә хат яза. Ул хат «Гарызнамә» исеме белән билгеле. Петербургта аны шулай ук төрмә көтә. Шулай да монда ул, христианлыкка күчәм, дигән булып, попны китерегез, әгәр христиан диненең исламнан өстенрәк икәнен төшендерә алса, чукынам, ди. Шулай итеп, мөгаен, вакытлыча булса да яшәү шартларын яхшыртa алгандыр. Инде христианлыкка күчмәячәген аңлагач, 1757 ел уртасында, Батыршаны Шлиссельбург крепостенә мәңгелеккә ябалар. Ул шунда гомерлек колодник булырга тиеш була. Әле аннан да ул патшабикәгә хатлар яза, аның киң күңелле гадел хакимә булуына ышана, урыннардагы начальниклар гына аңа барлык кимчелекләрне җиткермиләр, дип уйлый. Батырша шулай 5 ел буе Шлиссельбургта тотыла, аның качу нияте дә була һәм мөмкинлек килеп чыгуга, сакчылар уяулыкларын югалткан мәлне, туры китереп балта белән дүртесен чабарга өлгерә, әмма артыгына көче җитми, үзе дә һәлак була, документта, йөрәге тотып үлде, дип аңлатыла.

Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрү эзсез генә узмый. Халыклар хөкүмәткә тугрылыклы булсын өчен элеккеге кансыз юллар гына түгел, башкача алымнар да кулланыла башлый: лашманчыларның (йомышлыларның) хезмәт хаклары 1–2 тиенгә арттырыла, Казан адмиралтействосына алар өстеннән контрольне көчәйтергә хокук бирелә, чукынганнар яшәгән авыллардан чукынмаганнарны кудыру туктатыла, шулай ук Казан губернасында бик күпләр коралмаган архиерей Лука Конашевич башка җиргә күчерелә (инде соңрак мөселманнарга мәчетләр ачу да рөхсәт ителә), 1755 елда баш күтәрүдә катнашучыларга карата үлем җәзасы кулланылмый (әмма төрмәләрдә һәм башка җирләрдә судсыз-нисез үлем очраклары бик күп була).

Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр куйган максатларына – патша администрациясен бәреп төшерүгә ирешә алмыйлар, билгеле. Чынлап та, дуамал беркатлы халыкны бер максатка юнәлдерү мөмкин хәл булмый. Халыкта, электән килгән кәсепләреннән китмичә, буйсынып яшәргә күнеккәннәре дә җитәрлек, үзара килешмәү дә көчле – еш кына баш күтәрүчеләрнең нәфрәте үз кавеменнән булган хөкүмәткә «верный»ларга каршы юнәлдерелә. Стихияле чыгышларның ахыр чиктә бастырылачагы алдан ук билгеле. Шулай да Батырша өндәве буенча күтәрелүчеләрнең «Ятып калганчы атып кал» дигән халык мәкалендәгечә эшләргә йөрәкләре җитә.



Батыршаның кульязмасы.

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ



ВАТАНГА КАЙТУ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов – татар тарихын, мәдәниятен һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнгән сирәк галимнәребезнең берсе. Үзенең юлын дәвам итәрлек шәкертләр тәрбияләгән олуг остаз. Ярты гасырга якын фәнни-тикшеренү эшчәнлеге дәверендә чал тарихка нисбәтле төрле юнәлештәге 500 гә якын бәяләп бетергесез хезмәтләр калдырган профессор ул.

Автор:
Мөршидә Кыямова

Фотоматериаллар галимнең шәхси архивы һәм Татарстан Милли китапханәсеннән алынды.



Галимнең шәҗәрәсе Татарстанның Әтнә районы Олы Мәңгәр авылына нисбәтле булса да, ул 1934 елның 31 маенда Көнбатыш Кытайның Синьцзян провинциясендәге (Шәркый Төркестандагы) Голҗа шәһәрендә туа. Бәхет эзләп чыгып киткән бабалары Кытай җирендә яшәп калганнар. 1941 елда Миркасыйм Госманов Голҗаның татар мәктәбенә укырга керә, башлангыч белемне шунда ала, аннары Голҗа шәһәренең рус гимназиясендә укый. Голҗа татар мәктәбе укучылары, гарәп графикасына нигезләнгән уку һәм язу күнекмәләре белән беррәттән кириллицага да өйрәнәләр. Ә бу исә, мәктәп һәм шәхси китапханәләрдә тупланган, Октябрьгә кадәрге чорның гарәп графикасындагы күпсанлы татар басмаларын өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Төрле телле төбәктә яшәү булачак галимгә табигый рәвештә тугандаш төрки телләрне: казах, уйгыр, кыргыз, үзбәк телләрен үзләштерергә ярдәм итә. Бу аның тарихчы-чыганакчы буларак профессиональ эшчәнлегенә, шулай ук тәрҗемәчелек эшчәнлегенә дә уңай йогынты ясый. Мәсәлән, татар укучысы Чыңгыз Айтматовның әсәрләре белән беренче тапкыр Миркасыйм Госманов тәрҗемәләре аша таныша.

Бабаларының туган җиренә кайтырга хыялланган егет теләген 1958 елда тормышка ашыра: Казан дәүләт университетына укырга керә. 1964–1967 нче елларда аспирантурада белемен арттыра. 1968 елда XVII–XVIII йөз татар тарихи чыганакларын тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. 1967 елда Миркасыйм Госманов СССР тарихы кафедрасында педагог булып эшли башлый.

«Тарихи ватанга кайтуымны (әйе, килү түгел, ә кайтуны!) уңай бәяләүчеләр, ихлас хуплаучылар, кирәк чакта ярдәм кулын да сузучылар күбрәк булды дип әйтә алам, һичшиксез, күбрәк... Галим сыйфатында җитлегүемә, уңышларыма килгәндә, моның сәбәпләрен иң элек үземнең көн-төн диярлек тырышып эшләвемнән, реаль шартларны дөрес аң-

Никах хәтирәсе. Салисә һәм Миркасыйм Госмановлар. Казан, 1961 елның 5 ноябре.

лап, түземле булуымнан эзләргә кирәктер. Шулай ук карьера өчен җиңелрәк һәм отышлырак юллар сайламыйча, ул чаклардагы модаларга иярмичә, язма мирас дөньясы кебек кыенрак, «четереклерәк» өлкәгә кереп китүем дә өстәмә сәбәп булгандыр,» – дип яза Миркасыйм ага үзе.

КУЛЪЯЗМА МИРАС ЭЗЕННӘН...

Идел-Урал буе төрки халыкларының тарихы һәм мәдәниятенә караган XIII–XX йөз башы төрки язма чыганакларын өйрәнү – Миркасыйм Госмановның фәнни-тикшеренү өлкәсендәге төп юнәлеш. Татарстан һәм хәзерге Россия Федерациясенең төрле өлкәләренә сибелеп яшәүче татар халкы арасында татар, гарәп, фарсы телләрендә иҗат ителгән, күчерелгән язма ядкарьләрне җыю һәм тикшерү буенча оештырылган археографик экспедицияләр бу өлкәдә аерым урынны алып тора. 1963 елда Миркасыйм Госманов университетта археографик экспедиция оештыру идеясен күтәреп чыга. Моны, Казан шәркыят мәктәбенең гарәби кулъязма ядкарьләрен җыю һәм өйрәнү өлкәсендәге элеккеге традицияләрен торгызу дип кабул итәргә кирәк.

Галим җитәкчелегендә, гарәп графикалы язма чыганаклар материалларына нигезләнеп, кандидатлык диссертацияләре яклана. Аның шәкертләре арасыннан байтагы инде фән докторы, профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән.

– Элеккеге автономияле биш республика һәм унбиш өлкәдәге татарлар яшәгән 900 гә якын авылны тикшерү нәтиҗәсендә 9 меңнән артык кулъязма һәм мең ярымга якын иске басма китап җыела. Экспедицияләрнең уңышлы эшләве Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш кулъязмалар фондын ике тапкыр диярлек баетырга мөмкинлек бирде.

Җыелган кулъязмаларда VII гасырдан алып XX йөз уртасына кадәр вакыт эчендә иҗат ителгән әсәрләрнең текстлары теркәлгән. Жанр ягыннан караганда да алар гаять күптөрле. Ни генә юк алар арасында: мөселман юриспруденциясенә караган кулъязмалар, ислам тарихы, астрономия, математика, география һәм фәннең башка тармакларына бәйле хезмәтләрнең күчерелмәләре, документаль чыганаклар, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият үрнәкләре. Гаять тырыш, тирән белемле, чын мәгънәсендә академик иде. Ул – халыкара масштабта да танылу алган галим, – дип искә алган иде Миркасыйм Госмановның шәкерте, галим Җәүдәт Миңнуллин.

Миркасыйм Госмановның «Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары» хезмәте галимнәр арасында гына түгел, киң җәмәгатьчелектә дә зур кызыксыну уятты. Балаларны, үсмерләрне тарих дигән кызыклы дөньяга җәлеп итүдә, фәнне популярлаштыруда җиңел тел белән катлаулы материалны бәян иткән әлеге хезмәтнең әһәмияте әйтеп бетергесез.

Галим туган телдә тарихка караган фәнни-популяр мәкаләләр һәм китаплар бастырып, әһәмиятле эш башкарып, яшь укучыларга үз халкының үткәне һәм мәдәнияте хакында бәян итте. «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» китаплары – шундыйлардан. Әлеге ике китап 1984 елда бер томда басылып чыкты.

Россиянең төрле архивларында, фәнни китапханәләрендә ифрат зур тырышлык күрсәтеп, төрки халыклар тарихы һәм әдәбиятына караган документларны фәнни әйләнешкә кертүдә дә галим зур эш башкарды. Идел–Урал буе төрки халыклары тарихы чыганакчылыгына багышланган «XVII–XVIII йөз татар тарихи чыганаклары» һәм «Җучи Олысының ярлыкаш актлары» исемле фундаменталь хезмәтләре дөнья күрде. Тикшеренүләрнең бай чыганакларга таянуы

ИСТӘЛЕКЛӘР

Ирек Һадиев, ТР Милли китапханәсе директоры урынбасары:

– Миркасыйм Госманов 1994 елдан бирле ТР Милли китапханәсенең төрки-татар һәм шәрык кулъязмалары буенча фәнни консультанты булып торды. Ул китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеген оештыруга, әлеге бүлекнең фәнни-тикшеренү һәм археографик эшчәнлеген үстерүгә зур өлеш кертте. 2000 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Химаячеләр шурасы әгъзасы итеп тә сайланды һәм республикабыздагы фән, мәдәният, мәгариф үзәге буларак, китапханәнең дәрәҗәсен күтәрүгә һәрдаим булышлык күрсәтте Миркасыйм Госманов язма чыганакларны туплау һәм өйрәнү, шулай ук иске татар язулы матбугат буенча библиографик күрсәткечләр төзү һәм бастыру өлкәсендә тикшеренү, оештыру эшләрен алып барды, кафедра, археографик лаборатория хезмәткәрләрен һәм студентларны да бу эшкә тарта иде. Шул ук вакытта ул 1917 елга кадәрге чорда Россия империясендә һәм аннан читтә яшәгән аерым татар диаспоралары тарихын өйрәнде.

Фәндәс Сафиуллин, сәясәтче, галим, публицист:

– Миркасыйм Госманов сәясәтче түгел иде, әмма беркайчан да үз халкының язмышына кагылган һәм бәрелгән сәясәттән читтә тормады. Аның фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлегенең юнәлеше беркайчан да милләтебезнең мәнфәгатьләреннән аерылмады. Миркасыймның сәяси карашы үткән гасырның 90 нчы еллар башында, онытылмас эзләр калдырган заманыбызда, бик ачык күренде. Ул татар җәмәгатьчелегенең Татарстанга союздаш республика статусын алу өчен, Татарстан Фәннәр академиясен булдыру һәм татар милли мәгариф системасын милли югары уку йортларына тикле җиткерү өчен көрәшен турыдантуры яклап чыккан иде. Ул бөтен гомерен халкыбызның мең еллык хәтереннән төшереп калдырырга дучар ителгән, яла ягып тапталган тарихын торгызуга, онытылырга хөкем ителгән данлыклы шәхесләребезнең исемнәрен халкыбызга кире кайтаруга багышлады. Моңа тиң булырлык үз халкыңа хезмәт итү бездәге сәяси вазгыятьтә сәяси партияләрнең дә, дәүләт оешмаларының да көченнән килерлек түгел әле.



Миркасыйм Госманов шәкертләре белән Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә. Казан, 1978 ел.

һәм аларны өйрәнү нигезендә ясалган нәтиҗәләрнең ышанычлылыгы Казан, Мәскәү, Баку, Тбилиси, Будапешт, Анкара һәм башка шәһәрләрдә басылган рецензияләрдә, ягъни халыкара фәнни җәмәгатьчелектә уңай яңгыраш тапты.

Археографик экспедицияләрдә, архив һәм китапханәләрдә табылган кульъязмалар, шулай ук 1917 елга кадәр дөнья күргән басмалар нигезендә Миркасыйм Госманов тарафыннан XIX йөз татар әдәбияты классиклары Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмуллаларның әдәби мираслары тикшерелеп, төп оригиналдагыча бастырып чыгарылды. Әлеге хезмәтләр әдәбият тарихында зур әһәмияткә ия дип исәпләнә.

«Искитмәле бит, болгавыр чорларда нигезен, бөтен кирәк-ярагын ташлап, ач үлемнән котылу өчен качып киткәндә дә, татар тәһарәт комганын, ләгәне һәм берничә кадерле китабын намазлык-сөлгесенә төреп алырга онытмаган. Миңа Идел буенда язылган, күчерелгән, басылган китапларны Иркутск, Красноярск ягында да, Уралның төрле өлкәләрендә, Себердә дә күрергә туры килде. Кая гына барып урнашмасын, 5–6 гаилә җыелуга, беренче эш итеп, алар кечкенә генә гыйбадәт йорты булдыруга керешкән, 4–5 бала укырлык мәктәп-мәдрәсә оештырган. Хәтта Урта Азия, Казахстан җирләрендә, Кытайда, Шәркый Төрекстанда да мәктәпләр ачу белән безнең татар мәгърифәтчеләре шөгыльләнгән бит», – дип соклана галим.

Миркасыйм Госманов «Җыен» фондының рәисе булып та бик күп игелекле гамәлләр башкарды. Татар телен һәм мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертүче

> **«Сүз урынына эш кирәк. Ял итә белмәдем. Язучылар берлеге әгъзасы буларак, диңгез буендагы иҗат йортларына, санаторийларга барырга мөмкин иде, җәйләрем исә экспедицияләрдә узды, табигатьтә булуым белән канәгать идем... Җаның теләгән эш белән шөгыльләнү үзе бер ял икән».**

«Җыен» фонды тарафыннан эшләнгән «Шәхесләребез» сериясеннән Карл Фукс, Михаил Худяков, Исмаил Гаспралы, Газиз Гобәйдуллин, Рәмиевләр, Һади Атласи, Габдрахман Сәгъди һ.б.лар турындагы китаплар аның гыйльми ярдәме белән дөнья күрде.

«Үзебезнең тарихны дөрес аңлар өчен дә борынгы билгеташлар зур әһәмияткә ия. Әйтик, болгар бабаларыбызның нинди иман тотып, нindirәк телдә, шивәдә сөйләшүләрен, дөньяга, үлемгә нинди мөнәсәбәттә булуларын, нindirәк гамәли сәнгатькә ия икәнлекләрен без алардан калган эпитафияләр ярдәмендә белдек. Тарихыбызның Болгар чоры белән Казан дәвере арасындагы тирән уртаклыкны да, өстәге ерманы да шул кабер ташлары күрсәтеп торалар. Әгәр мәсьәләгә бер гомум караш ташласак, XII–XVI йөз эпиграфик истәлекләребезнең бөтен кешелек тарихында әһәмияткә ия байлык икәнлеген дә күрербез. Чөнки дөньяда төркичә эпитафия традициясен биргән ике генә төбәк бар. Берсе борынгы төрки руник язмаларны тудырган, саклаган Үзәк Азия, икенчесе

Өлкәннәр куанычы: бабай оныгы Айгөл белән. 1997 елның гыйнвары

> «Картлыкның исә үзенә күрә кабатланмый торган юанычлары да бар икән. Балаларның, укучыларыңның үсеп җитүләрен, уй-теләк һәм гамәлләрнең нәрсәләредер дәвам итүен күрүнең ләззәт хисе бирүе табигый. Ә инде онык күргәндә генә чын-чынлап нарасый сабыйның гаҗәеп гүзәллек дөньясы икәнен белү, аңлау, аның «баба-а-й» дип эндәшүен ишетү, бәләкәй кулларының җылысын тою үзе ни тора! Үз балаларыңны үстергән чакта әле күп нәрсәләрнең кадер-кыйммәтен аңлап бетермисең икән...»

Хатыны Салисә һәм кызлары Диләрә, Айсылу.

безнең Урта Идел регионы. Шулай булгач, безнең болгар-татар эпиграфикасының гомумтюркологик әһәмияткә ия булганлыгы да бәхәссез», – дип яза Миркасыйм Госманов.

Ул үзенең шәкертләре арасында фәнни юнәлеш алганда, әзләнү өлкәләрен кабер ташларын өйрәнүгә нисбәтләгән егетләр үсеп чыгуына шатлана. КДУ проректоры булып эшләгән елларында студентларга гарәп язуы, соңрак шәрык телләре укытыла башлау да, киң катлам татар тарихын өйрәнердәй белгечләр үстерү максатын күздә тотып алып барыла. Казан университетында Миркасыйм Госманов язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастыру өчен фәннитикшеренү археография лабораториясен, 1989 елда ачылган Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында тарих-филология кафедрасын, экология факультетларын оештыруда якыннан торып катнаша. Ул Казан университетында шәрык телләре бүлекчәләрен торгызуга зур өлеш кертә. Аның катнашында Казан университеты һәм чит ил (Венгрия, ГФР, Кытай, Төркия) университетлары арасында элемтәләр урнаштырыла.

ҖИТДИ ГАЛИМ, ОСТА ЛЕКТОР

Миркасыйм Госмановның кыяфәте җитди булгангамы, еш кына кырыс холыклы дип бәяләүчеләр дә бар. Ләкин аның белән якыннан аралашканнар моның киресен дәлилли. Ә үзе исә: «Холкымдагы сыйфатларга килгәндә, әти-әнинең дә тәэсире булгандыр, шулай ук үземне үзем дә тәрбияләгәнмендер, чөнки бер хакыйкать бар бит: адәм баласы бишектән алып ләхеткә кадәр өйрәнергә, белем алырга тиеш. Үзеңнең холкыңны, характерыңны да шулай тәрбияләү зарурдыр» – дигән.

Замандашлары Миркасыйм Госмановта артистлык сәләте дә барлыгын искәртә. Табында утырганда дусларына мәзәкләр сөйләгәндә бу сыйфаты аеруча калку чагыла торган булган. Чак кына артист булып китмәве турында да белә аның якыннары. Берара театрда да уйнап алганын әйтеп салган чаклары булгалаган. Хәер, аның җыр-моңга, бигрәк тә татар халык әсәрләренә битараф булмаганын беләбез. Илһам Шакиров, Әзһәр Шакиров кебек күренекле артистлар белән дус булуы да моңа дәлил.

Төрле кичә-мәҗлесләрдәме, сәхнәдән яки телевидениедәнме чыгыш ясаганда Миркасыйм ага һәр сүзен тәмләп, саллы итеп, бастырып сөйли торган иде. Чып-чын нотыкчы, оратор! Аның шушылай сөйләм мантыйгын саклап фикерен тыңлаучыга ярып сала белүе күпләр өчен үрнәк тә, өлге дә дип уйлыйм.

Мөхтәрәм галимнең үз тормышы, кредосы хакындагы фикере дә кызыклы: «Безнең зур түрәләр минем характерымны, холкымны да яхшы белгәнгә, үз тирәләренә тартырга теләмәгәннәрдер. Совет идеологиясендә тәрбияләнгән түрәләр өчен үз фикере белән гамәл итүче «киребеткән», ни кушсалар да, ләббәйкә дип тормыйча, үзенчә эшләргә яраткан кешеләрне өнәп бетермиләр. Мондый хәл, дөресен әйткәндә, минем файдага булган икән – чиновник булып гомерне заяга уздырудан котылганмын. Гел гыйльми хезмәттә калдым. Әгәр яшьрәк чакта алданып, берәр чиновниклык юлыннан китсәм, бәлки, күптән «муеным сынган» булыр иде. Ә хәзер мин исән калып, ата-бабаларымнан беркемнең дә төшенә кермәгән югары гыйльми дәрәҗәләргә ирештем».

«Халыкны мәгърифәт, дин, аң, китап, җыр һәм моң яшәтәчәк. Әгәр халык элеккечә үк аерым бер халык булып яшәргә теләсә. Теләмәүчеләр дә табылырга мөмкин. Андыйлар элек тә булгалаган. Һәрбер халыкта. Нинди генә яңа казанышларга ирешелсә дә, кеше бары кеше булып калачак. Моннан дистәләгән еллар элек, менә язу машинасы чыкты, инде каләм бетәчәк, дип, әле күптән түгел генә компьютер чыкты, моннан соң китап бетәчәк, дип оран салганнар иде. Ә ләкин бетми бит китап! Каләм дә бетмәде! Бары куллану өлкәләре генә үзгәрде».

Казан мэры Камил Исхаков юбилярга медаль тапшыра. 2004 елның 31 мае.

ИСТӘЛЕКЛӘР

Кызы Диләрә Госманова, тарих фәннәре докторы:

– Әтиемне яшүсмер вакытымда аз булса да, аның күзгә күренмичә дә дигәндәй янымда икәнен еш тоя идем. Сабый чагым хатирәләрендә әтинең кичке якта һәрвакыт язу өстәле янында утырганы ачык сурәтләнеп калган. Университеттан кайткач, аз гына ял итеп ала да, үзенең яраткан текстлары һәм китапларына чумып утыра. Ул эшләгәндә яки ял иткәндә без сеңелкәш белән аяк очларына гына басып йөри идек. Сеңелем белән әтинең безгә күбрәк игътибар итүен тели идек. Ял көннәрендә безне ияртеп урамга чыгуын яки безгә китап укуын, ә җәй айларында диңгезгә алып баруын. Безнең гаиләдә әти һәрвакыт хезмәттә иде... Әтинең хезмәт сөючәнлеге, фәнгә мөкиббәнлеге бездә дә аның эшенә һәм тормыш итү рәвешенә хөрмәт тәрбияләде. Безнең гаиләдә иҗатка ихтирам зур булды. Гаиләдәге мохит мәктәп елларында да һәм аннан соң да дәвам итте: китаплар, танылган тарихчы-галимнәрнең кызыклы фикер алышулары, төрле темаларга әңгәмәләр сеңелем белән икебезнең киләчәк һөнәр сайлавыбызда да зур роль уйнады.

Әти, һәрвакыт эш белән мәшгуль булуына карамастан, буш вакытларын безгә багышлады. Әле дә хәтерлим, без гаилә белән ял йортына барган идек. Әти гөмбә җыярга ярата иде. Аның бу сыйфаты безгә дә күчте. Без бергә урманга барабыз, гөмбә җыябыз, бергәләп аны чистартабыз, киптерәбез.

Чираттагы китабы басылып чыккач, гонорар акчасына Мәскәүгә барганыбыз исемдә. Башкала белән безне таныштырып кайткан иде. Истанбулга бару әти белән соңгы сәфәрләребезнең берсе булды. 2008 елның ноябрендә әтигә биредә мәртәбәле премия (ИРСИКА) тапшырылды. Ул мөселман дөньясын өйрәнүдәге казанышлар өчен бирелә».

Торсынтай Галиев (Голҗа, Кытай):

– Казанда балаларыбыз урнашкан тулай торак, Ходайның рәхмәте, Миркасыйм абзыйларның йортына бик якын иде. Ул елны көздән үк салкыннар башланды. Егет һәм кызларның бик күбесе, әллә мондагы һавага ияләшә алмыйча, әллә инде бүлмәләре салкын булу сәбәпле, бер-бер артлы авырый башлады. Нәкъ менә шул көннәрдә Салисә апа белән Миркасыйм абый күпләргә үз туганына да күрсәтмәгән миһербанлык үрнәген күрсәттеләр. Өйләрендә күпме юрган-одеял булса, аларны күтәреп тулай торакка ташыдылар. Салисә апа күпме дарулар алганын, күпме дару үләннәре, салкын тиюдән дәвалаучы җиләк-җимешләр, берсеннән-берсе тәмле өй ашларын ташыганын, ничәмә-ничә бала янында күпме көннәрен үткәргәннәрен үзе дә хәтерләмидер. Миркасыйм абзый, Гаеттә корбан чалып, «Җыен» фондында шул балалар өчен аш мәҗлесе уздырды. Мондый мәҗлесләр үткәрү һәр Ураза һәм Корбан гаетендә гадәткә әверелде.

Илнур Миргалиев, ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты каршындагы Миркасыйм Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты:

– Миркасыйм Госманов – татар тарихчыларының абруйлы дәрәҗәсен озак вакытлар тотып торган шәхес. Бигрәк тә Урта гасыр, Алтын Урда тарихы буенча бастырган китаплары – бүгенге көндә шушы тема буенча шөгыльләнгән һәр тарихчы галимнең өстәл китабы. Миркасыйм ага хезмәтләренә сылтама ясамыйча, эшне җәелдерү мөмкин түгел. Ул үз эшен иң югары дәрәҗәдә алып барган галим, остаз. Аның эшләре әле дә дәвам итә. Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге аның исемен йөртә. Без, шулай ук, татар ханлыклары, Алтын Урдага бәйле чыганакларны күп табабыз, аларны фәнни әйләнешкә кертәбез, тәрҗемә итәбез, конференцияләр оештырабыз. Миркасыйм аганың эше тагын да киң колач алды, моның өчен мөмкинлекләр дә артты. Ул башлаган эшләр, ул эзләп тапкан тарихи кыйммәткә ия чыганаклар безнең эшнең төп нигезе булып торалар.

Мин үзем аның укучысы түгел, шулай да күп тапкырлар аралашырга насыйп булды. Мин аны һәрвакыт җылы хатирәләр белән генә искә алам. Ул Казан тарихчыларының хезмәтен дөньяга танытаң галимнәребезнең берсе.



КӨЛҮДӘН ГЕНӘ ТУКТАМА!..

Яңа уку елы башланды, аның белән бергә – балалар, яшүсмерләрнең дә, укытучылар, әти-әниләрнең дә шатлык-куанычлары, борчу-хәсрәтләре, хыял-өметләре, омтылыш-канәгатьсезлекләре... Гел шатлыктан һәм наз-яратудан, уңыш-казанышлардан гына тормаган Балачак дөньясына моңсу, ләкин гыйбрәтле сәяхәт ясыйсы килә бу санда. Яңа яшь авторның сискәндергеч романы аша.

Автор:
Луиза Янсуар

ДЖОКЕР (JOKER) 16+

Төшерелгән елы: 2019
Төшерелгән иле: АКШ, Канада
Слоганы: «Бәхетле кыяфәт ясa»
Дөньякүләм премьерасы: 2019 елның 31 августы
Режиссер: Тодд Филлипс
Сценарий: Тодд Филлипс, Скотт Сильвер, Боб Кейн
Продюсерлар: Брэдли Купер, Тодд Филлипс һ.б.
Оператор: Лоуренс Шер
Композитор: Хильдур Гуднадоттир
Рәссамнары: Марк Фридберг, Лора Боллинджер, Марк Бриджес һ.б.
Монтаж: Джефф Грот
Жанры: психологик драма, триллер, криминал
Төп рольләрдә: Хоакин Феникс, Роберт де Ниро, Зази Битц, Фрэнсис Конрой, Бретт Каллен, Джош Пэйс һ.б.

Мин бу фильмны бик тә заманча һәм социаль эчтәлектә кабул иттем. Без һәрберебез пиксельләрдән гыйбарәт экраннан тәүлекнең 24 сәгате буена елмаерга һәм ничек матур, ыспай, уңышлы яшәвебезне рекламаларга, пропагандаларга иялəшкән буын һәм заман вәкилләре... Ә менә җаныбызга бу тышкы ялтырауның нинди канәгатьсезлек кертеп бикләгәнлеген ачыктан-ачык тоемларга, кабул итәргә әзербезме соң?

8 МИНУТЛЫК «БРАВО!»

Быелгы Венеция кинофестивалендә тамашачылар зарыгып көтеп алган «Джокер» премьерасыннан соң 8 минут буена басып кул чапты. 8 минут буе «Браво!» сөрәннәре яңгырап торды. Нәтиҗәдә – «Алтын арыслан» һәм Soundtrack Stars премиясе.

Россия прокатына фильм 3 октябрьдә чыкты һәм шунда ук массакүләм карала торган картинага әверелде. Дөрес, күпчелек Бэтмен галәменә алданып, DC стилистикасына өметләнеп килгәндер. Баштарак. Әмма бу өметләрнең бушка булуы да массаны куркытмады һәм куып таратмады, дип ассызыклый кино тәнкыйтьчеләре.

Фильмга нисбәтле карашлар кискен һәм икеяклы, әмма ул берәүне дә битараф калдыра торганнардан түгел. Монысы – шиксез.

Яхшы сыйфатта, кинотеатр экраныннан карау зарур. Минем үземә Филлипс фактурасы һәм видеорәте, Гуднадоттирның сихерләү сәләтенә ия музыкасы, Шерның гаҗәеп камерасы белән Феникснең эре планнарда бүләк иткән ләззәте бер генә тапкыр караудан җитмәде, тагын, тагын бардым. Ә кат-кат караганда лентаның катламнары җетерәк ачыла төшә, ракурсы киңәя. Син үзең җитлегеп өлгерәсең.

Фильмны Финчерның «Бойцовский клуб»ы белән бер рәткә куеп, культ картиналар рәтенә керәчәк, дип фаразлап куйдылар. Алдан ук. Хит Леджер Джокерыннан соң Хоакин Феникс укылышы һәркемгә

Фотолар: www.kinopoisk.ru һәм www.film.ru сайтларыннан алынды

кызыклы иде, билгеле. Леджердан соң бу жанрда тагын нинди психологик тирәнлеккә төшеп була, дип бәхәсләүчеләр дә җитәрлек табылды.

Хоакин Феникс үзе баштан ук кистереп салды: «Хит Леджер тудырган Джокер, һичшиксез, иң шәбе. Минем Джокер исә – иң көтелмәгәне һәм кабатланмасы, бәлки. Джокерны моңарчы болай күрүче һәм тоючы юк иде әле».

Фильм экраннарга чыкканчы моны шапырыну буларак та кабул итүчеләр булды. Әмма шапырыну түгеллеге – хәзер аермачык.

- Студия җитәкчеләре Джокер ролендә баштарак Леонардо ди Каприоны күрәләр.
- Рольне башкарыр өчен Хоакин Феникс 24 килограммга ябыга, психологлар, психиатрлар белән эшли, көлүнең күп төрләрен һәм клоунлык сәнгатенең жанрларын өйрәнә.

Без Бэтмен турындагы комикслар, ә аннары фильмнар галәменең аерылгысыз өлеше булган Джокерны психологик яктан торган саен җентекләбрәк укырга тырышуларына инде Леджер героеннан соң, чынлап та, күнегеп җиткән идек. Әмма Филлипс укылышына, миңа калса, әле шактый иялешү таләп ителәчәк. Еллар дәвамында. Чөнки ул бу геройны, ул яшәгән жанр куштырнакларыннан чыгарып, бөтенләй икенче форматка күчерде. Социаль эчтәлекне тирән психологик драма белән үреп бирде, гәрчә Готэм каһарманнары моңа әллә ни дәгъва белдермәсә дә.

Шулай итеп, безне нәрсә көтә: борчый, куркыта, чиркандыра, ә тора-бара җәлеп итә, ышандыра, сокландыра... үз-үзеңә каршы килеп... яраттыра торган Джокер. Моннан тыш – әйләндереп капланган Готэм моделе. Һәм ул модель аша, әйтерсең, ертык полиэтилен каплау читләреннән җилфердәп чынбарлык күренеп тора. Диварлар буйлап чагылучы үз күләгәләребез, аяк астында тоташтан аунап яткан чүп капчыклары, дөньяны үтәли чылаткан яңгыр, күлдәвекләр, фонарь утлары саркылышы... һәм үтәли канәгатьсезлек, ялгызлык, сагыш...

Ә МИН... УЛ ТҮГЕЛ!

Кем соң бу «яңа Готэм»дагы Джокер? Урта яшьләрдәге Артур Флэк исемле уңыш елмаймый торган клоун. Ул әле шул яшендә дә тору шартлары коточкыч булган районда авыру әнисе белән яши, тормышының көч-хәл белән очын-очка ялгый, туктаусыз тәмәке тарта, тирәдәгеләрнең мыскыллавын, типкәләвен һәрвакыт елмаю белән уздырып җибәрергә тырыша... Ә ара-тирә ул елмаюы сәер, куркыныч көлүгә әверелә. Миндә, флэшбеклар булып, Виктор Гюго әсәрләрендәге караңгы-шомлы буяулар һәм «Человек, который смеется» сюжет линиясе белән параллельләр яңгырап торды. Артур көлгән мизгелләрдә, әле фабула буенча шөбһә сизелмәсә дә, без инде бу фильмнан исән-имин чыкмаячагыбызны аңлый башлыйбыз. Аны караңгы бер почмакка куалап кертеп, тибә-тибә кыйнаганда, эшендә мәсхәрәләгәндә, психотерапевты: «Артур, сездә негатив уйлар буламы?» – дип сораганда... инанабыз. «Доктор, минем барлык уйларым да негатив», – дип җавап бирә тормышы тоташ котылгысызлыктан торган героебыз, һәм ахыры күренми торган тар урамнар, метро вагоннары, подъезд коридорлары буйлап кабат үз өненә юл ала. Әнисе янына кайтып җитә дә, бар көченә елмаеп, телевизордагы шоуны карарга утыра. Ә анда миллионнарның кумиры булган Мюррей Франклин чираттагы тапшыруны башлап җибәрә.

«Мин фильмга әзерләнгәндә Туретта синдромы белән авыручыларны өйрәндем, әмма геройны авыру итеп күрсәтү өчен түгел, ә авыру чынбарлыктан качып котылу чарасын тапмаган бичара икәнлеген тагын да ныграк ассызыклар өчен».

Хоакин Феникс.

Героик комикслар каһарманы Бэтмен да, Джокер үзе дә сыеша алмый Филлипс тудырган чынбарлык картинасына. Без аның Готэм икәнлеген дә гомумән диярлек кабул итмибез, баштан ук үзебезнең реалика итеп тоябыз. Шулай булгач, Джокерның үз эчебездәге иблисләрне уятасына, күрсәтәсенә дә шигебез калмый. Югыйсә, режиссер стилистик яктан бик тә җентекле һәм гаҗәеп үтемле итеп 70 нче еллар Нью-Йоркы атмосферасына күмелдерсә дә. Моның чираттагы битлек һәм алдавыч икәнлеген тора-бара тагын да ныграк аңлыйсың һәм, сокланып, янә бер тел шартлатасың: «Шәп, маэстро!»

ГАП-ГАДИ ҮЗЕБЕЗ

Жанр чикләреннән алып чыккан каһарманы белән Тодд Филлипс инде алга таба гомумән церемонияләр ясап тормый, ул аны без балачактан Гюго, Золя, Гоголь, Достоевский, Короленко китаплары аша укып һәм танып белгән

«кечкенә кеше» фаҗигасе кырында да йөртә, героик эпосларга, грек риваятьләре фактурасына да куеп үлчәп карый. Көлүе белән комик яссылыкта көн иткән Флэкның каһарманы акрынлап трагик персонаж төсмерләрен ала башлый, ә аның тилелеге иң югары дәрәҗәдәге трагик нотага барып ирешкәч, кабат каһкаһәле аһәңнәр булып сибелеп төшә дә көлдереп сискәндерә.

Фильмның иң зур өстенлеге, әлбәттә, нәкъ менә шул традицион фабуланың аргы ягына чыгып карауда. Моңарчы әле Джокерның балачагына, геройны герой (дөресрәге, антигерой, без бит аны һәрвакыт антогонист буларак беләбез) иткән факторларга юл алган режиссер да, сценарист та булмады. Чынлап та, каян килеп чыккан бу каһарманнар дөнья сәнгате аренасына? Аларның тамырлары әлеге дә, баягы борынгы мифик катламнарга барып тоташмыймы? Һәрхәлдә, Филлипснықы психоанализга берсүзсез барып тоташа. Ә психоанализ үзе – нәкъ менә мифларның структурасында яшәгән сакрализацияне җимерүгә…

Сүз уңаеннан, Джокерны алгы планга чыгарып, режиссер икеләтә сынауга бара: 1) ачыктан-ачык тискәре, хәтта ки җирәнгеч тойгылар уята торган геройга сокландыру, хәтта ки кызгану тойгысы уяту зур сәләт таләп итә; 2) бу фильм белән үч алу, җимерү, үтерү кебек алымнарны пропагандалый, дигән гаепләүдән китә алып, масштаб тудыра алу – монысы инде икеләтә җаваплылык. Филлипс боларга экран артында утыручы тамашачысын акылдан шашу клаустрофобиясе тарлыгына куалап кертеп, аннары тулы бер социум фаҗигасенә алып чыгып, кешелек фаҗигасенә тоташтыру аша ирешә. Һәм без иң атаклы суперявызны түгел, ә… гап-гади үзебезне күрәбез: аның

43 яшемнең 35ен мин кинога төшеп уздырдым. Әмма һаман да кинонытөшерә башлар алдыннан төнемне йоклый алмыйча уздырам. Костюмерларга киемемә махсус тир сеңдергечләр тегәргә туры килә: шулкадәр дулкынланам ки, киемем манма була. Төшергән чакта беренче өч атнаны тоташтан шыбыр тиргә батып йөрим. Нервлар чыгырдан чыга. Әйтергә кирәк… үзем үлеп яратам шушы халәтне.

мыскыллы елмаючы кеше өере каршына чыгып басып көлүендә дә, җәберләргә дип ябырылучылардан качып котылганнан соң җәберсенеп елавында да, кыяр-кыймас кына, наз, мәхәббәт тамчысы өмет итеп, янәшәдәгеләренә тартылуында да, иң азактан, халык үзен идол, пот итеп күтәреп алганда, күккә чөйгәндә, йөзеннән узган чиксез зарлы, чиксез бәхетле елмаюында да. Бу мизгелдә ул классик сюжеттагы Джокерга шактый якыная – үз легендасының каһарманына әверелә. Әмма – бер мизгелгә генә. Аннан яңадан гап-гади адәм булып калыр өчен…

Америка прокатында «Джокер» беренче елларда ук рекордлы 93,5 миллион долларны җыйды.

ТУУ БЕЛӘН ҮЛЕМ АРАСЫНДА…

Әйе, Джокер – шушы шәһәр, шушы кешеләр, аларның метаморфозалары, үзләреннән-үзләре үк яшергән проблемалары, чишелешләре, гөнаһлары, саваплары, зарлары, шатлыклары, тантанасы, агониясе ул. Безнең Туу белән Үлем арасындагы ике чиктәге өзлексез иллюзияләребез һәм агониябез.

Социаль яссылыкта ачылганда, Джокер заманны бар шомында күрсәтә. Һәм иң куркыныч мизгел, апогей – аның очраклы каһарман булып әверелүе. Фильм азагында шәһәр буйлап машиналар шартлатып, йортлардагы тәрәзәләрне чәлпәрәмә китереп ватып йөрүче клоуннар отряды… кайчандыр бу алым үзенең коточкыч тәэсире белән Джеймс МакТигның «V значит Вендетта» картинасыннан бөркелгән иде. Биредә исә Филлипс безгә явызлыкның бик гади һәм карап торышка куркыныч булмаган вак-төякләрдән башлануын һәм, очраклы сайланышка эләгеп, стихияле төсмер алырга мөмкинлеген ачыктан-ачык күрсәтә. Фильм бу җәһәттән бик тә кисәтүчән яңгыраш ала.

«Джокер»ның феноменаль популярлыгы, минемчә, аның кискен реализмына һәм сәнгати радикализмына турыдан-туры бәйле. DC мифологиясе элементларын саклап калган хәлдә, ул бөтенләе белән супергероика галәменең чираттагы өлешенә әверелми, аңарга хәтта якын да килми.

Мультиплекс өчен радикаль исәпләнгән һәм уен картинасының масса өчен ярытылган клишесыннан, форматыннан азат булган картиналар кинотеатрларга ачыктан-ачык юл яра башлады, дисәк тә буладыр. Узган сезондагы Гуаданьиноның «Суспирия»се генә дә моның ачык бер мисалы иде. Быел без озакламый Стивен Кинг буенча «Сияние»нең өр-яңа укылышын көтәбез. Җитмәсә – төп рольдә Юэн Мак-Грегор белән. Римейклар аша да җитди шедеврларга юл салып була, дип еш кабатлый башлады кино тәнкыйтьчеләре.

Бу – киноиндустриянең тагын бер яңа этаптагы сихере, магиясе-дер, бәлки. Сыйфат билгесе.

Күзәтүләргә таянып, шуны да әйтәсе килә: Хоакин Фениксны әлеге рольгә аның алдагы ике шедевраль роле дә әзерләгәндер, мөгаен. Болар – «Мария Магдалина» картинасындагы Иисус роле һәм «Тебя здесь никогда не было» фильмындагы сугыш ветераны Джо. Бу ике рольдә дә ул үзенең, актер буларак, бөтенләй яңа дәрәҗәгә чыгуын исбат иткән иде. Юкка гына бер әңгәмәсендә хәтта болай димәгәндер: «Иисусны уйнарга тәкъдим иткәч, иркен сулап куйдым: ниһаять, мине аңлаучы да табылды!»

«Тормышымның иң шәп вакыты – менә хәзер!» – дип елмая ул тагын. Димәк, әле чираттагы рольләрдән ләззәтләнергә өметләнә алабыз.

ХОАКИН ФЕНИКС ФИЛЬМОГРАФИЯСЕННӘН ҺИЧШИКСЕЗ КАРАЛЫРГА ТИЕШЛЕ 10 КАРТИНА:

1. **«Гладиатор»**, режиссер Ридли Скотт, 2000;
2. **«Таинственный лес»**, режиссер М.Найт Шьямалан, 2004;
3. **«Переступить черту»**, режиссер Джеймс Мэнголд, 2005;
4. **«Я все еще здесь»**, режиссер Кейси Аффлек, 2010;
5. **«Мастер»**, режиссер Пол Томас Андерсон, 2012;
6. **«Она»**, режиссер Спайк Джонс, 2013;
7. **«Иррациональный человек»**, режиссер Вуди Аллен, 2015;
8. **«Тебя никогда здесь не было»**, режиссер Линн Рэмси, 2017;
9. **«Братья Систерс»**, режиссер Жак Одиар, 2018.
10. **«Мария Магдалина»**, режиссер Гарт Дэвис, 2018.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 47нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Бүгенге көндә баш врач Фәрит Җиһаншин җитәкчелек иткән **Академик Владимир Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе** үзенә нигез салынуның 150 еллыгын билгеләп үтте.

Психиатрия ярдәме локомотивы

Искәндәр Миңнуллин,
«Республика клиник тире-венерология диспансеры» ДАССУ баш табибы

– Хөрмәтле Фәрит Галимҗанович! Сезнең профессиональ коллективыгызны күренекле юбилей датасы белән котлыйбыз!

Бу Татарстан өчен генә түгел, гомумән илебез өчен дә әһәмиятле вакыйга. Александр Фрезе, Лев Рагозин, Владимир Бехтерев һәм башка бөек акыл ияләре һәм искиткеч оештыручыларның исемнәре шушы хастаханә белән бәйле.

Сезнең учреждение хаклы рәвештә Россиянең иң яхшы психиатрия оешмасы булып танылган, һәм психиатрия юнәлешендә эшләүче врачларны әзерләү, белемнәрен арттыру буенча төп үзәкләрнең берсе булып тора. Гасыр ярымлык тәҗрибәсе аның киң практикасын һәм үз вакыты өчен дистәләрчә революцион яңалыкларын күзалларга мөмкинлек бирә.

Хәзер дә республиканың төп психиатрия хастаханәсе фән өчен һәм пациентларының рухи сәламәтлеге хакына алгарыш юлы белән атлавын дәвам итә.

Фәрит Галимҗанович, үзегезгә дә, Сез җитәкләгән коллективка да даими үсеш-үзгәреш, яңа перспективалар, матди-техник базагызның яхшыруын һәм фәнни уңышларга ирешүегезне телим!

Фото «Республика клиник тире-венерология диспансеры»ннан алынды

Реклама

Нәкыйп Гатиятуллин, «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» ФБУнең Казан филиалы директоры, ноябрьдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Профессионал һәм патриот

Данис Нургалиев,
КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры

– Хөрмәтле Нәкыйп Сәлахович, Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Илебезнең геология разведкасын үстерү эшенә Сез керткән өлешнең никадәр зур булуы турында исемегезнең Татарстан, Россия, чит илләрнең профессиональ даирәләрдә яхшы билгеле булуы сөйләп тора. Республикабыз нефть һәм газ табу тармагында һәм аны эшкәртү сәнәгатендә югары казанышларга шулай ук Сезнең фидакарь хезмәтегез нәтиҗәсендә дә иреште, ә аның нигезендә – Сезнең үз профессиягезгә һәм туган ягыгызга ихлас мәхәббәт ята.

Инде 90 нчы елларда ук Сез, үтә үзле нефть табуга нинди мөһим роль бирелачәген алдан күзаллап, мондый төр нефть объектларын эзләү һәм ачыклау методларын сизелерлек камилләштердегез һәм бу өлкәне принципиаль яңа баскычка күтәрдегез. Сезнең тырышлык Татарстанның халык саны тыгыз булган берничә районын сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итүгә зур өлеш кертте.

«Татнефть» ААҖнең 1989 елдан 2015 елга кадәр Сез җитәкчелек иткән Татарстан геология разведкасы идарәсе тарафыннан углеводород катламнарын эзләү һәм табуның берничә ысулы эшкәртелде һәм патент алды, алар Татарстанда, элекке БДБ илләрендә һәм чит илләрдә нәтиҗәле кулланылды. Бу Татарстанның әлеге өлкәдәге әһәмиятен һәм абруен халыкара дәрәҗәдә сизелерлек күтәрде. Идарәдә эшкәртелгән сейсмик сигнал образларын танып алу системасын – «Нейросейсм»ны да искә алырга кирәк, аның ярдәмендә уннарча мең погон километр сейсмик профиль эшкәртелде, нейрокомпьютер анализлары үткәрелеп, Татарстанда, Самара, Ульяновск һәм Оренбург өлкәләрендә, Калмыкия, Коми Республикасында йөзләрчә чыганакларда эзләү-разведка бораулауларын үткәрергә тәкъдим ителде.

Сез бүгенге көндәге – «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» ФБУ директоры вазыйфасындагы эшчәнлегегезне дә үзегезгә хас профессионализм һәм зур җаваплылык белән башкарасыз, ул шулай ук Татарстан икътисадына һәм сәнәгатенә ярдәм итүгә юнәлтелгән.

Нәкыйп Сәлахович, Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшегездә уңышлар, энергия һәм яңа казанышлар өчен илһам телим!

Фото КФУ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

Ренат Мөслимов, ТР Президентының нефть һәм нефть-газ чыганакларын эшкәртү мәсьәләләре буенча консультанты, октябрьдә үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Нефть сәнәгате легендасы

Хөрмәтле Ренат Хәлиуллович! Геология һәм нефть-газ технологияләре институты коллективы исеменнән 85 яшьлек юбилеегыз белән иң ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Сез – легендар шәхес! Профессиональ сыйфатларыгыз һәм тормыш тәҗрибәгез республиканың гына түгел, бөтен илебезнең милли казанышы булып тора. Татарстанда нефть табу эше Сезнең исем белән аерылгысыз бәйләнгән. Сез аның башлангычында тордыгыз һәм хәзер, ярты гасыр үткәч тә, әлеге тармакның гармонияле һәм нәтиҗәле үсешендә актив катнашасыз.

Нефть сәнәгатендә эшләгән һәркем Сезне һәм бәһасез хезмәтегезне чиксез хөрмәт итә. Зирәк акыл, компетентлык, таләпчәнлек һәм җаваплылык – шушы сыйфатларыгыз өчен Сезне коллегаларыгыз һәм хезмәттәшләрегез югары бәяли. Туган Татарстаныбызның уңышларында һәм чәчәк атуында Сезнең турыдан-туры катнашыгыз бар. Хезмәтләрегез дистәләрчә тапкыр иң югары дәрәҗәдә дәүләт бүләкләре белән бәяләнде.

Бәхетебезгә, республикабыз нефтькә генә түгел, Сезнең кебек тирән акыл һәм фән дөньясы алыпларына да бай. Сезнең нефть чыганакларын эзләү, табу һәм эшкәртү мәсьәләренә караган уникаль эшләрегез һәм экспериментларыгыз үз җимешләрен бирде. Хәзер йөзләгән яшь белгеч шулардан өйрәнә, белем ала.

Юбилеегыз көнендә Сезгә һәр көн башкарган хезмәтегез, энтузиазмыгыз һәм Татарстанга булган чиксез мәхәббәтегез өчен тирән рәхмәтебезне белдерергә рөхсәт итегез. Сезгә чын күңелдән актив озын гомер, ныклы сәламәтлек, гаилә учагы җылысы һәм коллегаларыгызның, якыннарыгызның ярдәмен тоеп яшәвегезне телим!

Хөрмәт белән, **Данис Нургалиев**, КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры

Реклама Фото КФУның матбугат хезмәтеннән алынды

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76,

8-9272-483-384

e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

БИГЕШ – ҮТКӘННӘР САГЫНДА...

Зәй районының Бигеш авылына барганчы ук, бер кызык хәл турында ишеттем. 1960 нчы елларда авыл мәктәбе директоры укытучыларга: «Авыл кешеләре өчен мөгаллим маяк кебек булырга тиеш. Шуның өчен сез өс-башыгызны карап йөрегез, костюм киегез. Сыер-сарык асрамасагыз иде...» – дип мөрәҗәгать иткән. Шул рәвешле директор укытучының дәрәҗәсен, абруен күтәрергә тырышкан. Мөгаллимнең тышкы кыяфәте, тормыш рәвеше дә гади колхозчыдан аерылып торырга тиеш, дип санаган. Бүген ничек яши бигешлеләр? Мәктәп директорының кайчандыр әйткән киңәшләре әле актуальме? Зәйгә баргач, шушы һәм башка сорауларга җавап эзләдек.

Автор:
Руфия Фазылова

МӘЧЕТ КАРШЫНДА – ЛЕНИН СЫНЫ

Бигеш авылы җирлегенә алты авыл керә. Шуларның иң зурысы – Бигеш. Биредә 340 кеше яши, 201 хуҗалык бар. Дөрес, заманында халык саны ике тапкырга артыграк булган. Тирә-яклардагы иң зур авыл саналган ул. Колхоз идарәсе, урта мәктәп, участок хастаханәсе – күрше салалардан да бирегә килгәннәр. Тик менә сиксәненче елларда халык саны кими башлаган. Ни өчен дигәндә, янәшәдә генә Чаллы, Түбән Кама кебек шәһәрләр зурая барган. Авыл кешесе, кала тормышына кызыгып, заводларга барып урнашкан. Шәһәрләр дә якын шул – Бигештән Чаллыга утыз чакрым тирәсе, ә Түбән Кама унике чакрым ераклыкта гына. Район үзәге дә булган Зәй шәһәренә – егерме биш чакрым. Бүген дә йөзләп бигешле читкә йөреп эшли.

Фото: Александр Ефремов

– Авылда эш юкмы? – дигән соравымны бирдем Бигеш авылы җирлеге башлыгы Илгиз Вәлиевкә.

– Юк та түгел, күп тә түгел. Авылда урта мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, амбулатория үзәге эшли. «Зәй» агрофирмасы бар, анда дистәләп кеше хезмәт куя. Ялкау булмаган кеше өйдә тик ятмый инде үзе.

Амбулатория үзәге турында аерым әйтергә кирәктер. Элеккеге хастаханәне хәзер шулай дип йөртәләр. Аны көндез дәвалана торган үзәк итеп калдырганнар. Шулай да авыл кешеләре бик канәгать: система куйдырырга, башка төрле дәвалау курслары узарга – бер дигән мөмкинлек, бигрәк тә өлкәннәр өчен. Шунда ук теш табибы да бар. Дәваланырга күрше авыллардан да киләләр икән.

– Дәвалаучы табиб бик белемле, үз эшенең чын остасы, – дигән сүзне берничә кешедән ишеттек.

Бигеш авылы мәдәният йортына килеп туктауга ук, Ленин сынына игътибар иттек. Сынның кырыйлары матур итеп коймa белән тотып алынган. Ленин бабай бик «почетлы» урында тора, әллә бирердә һаман да социализммы, дип уйлап куйдым. Тагын да игътибар белән карасам, мәчет тә шунда ук. Бу картина бик кызык тоелды: кулын алга сузган Ленин сыны янында мәчет. Әллә бөек юлбашчы мәчеткә барырга чакыра, әллә киресенчә, аңламассың...

Сынның сере турында авылның аксакалы, күп еллар Бигеш урта мәктәбендә тарих укыткан Рәүф абый Насыйбуллин сөйләде:

– Бигеш авылы дуңгызчылык буенча дан тоткан колхоз булды. Ни өчендер Бигешкә сыерлар кайтармадылар, алары күрше авылларда иде. Зур авыл, диептер инде, дәүләт биргән планны үтәү – 5000 баш чучка асрау Бигеш кешеләре җилкәсенә төште. Санаулы вакыт эчендә ферма бинaлары кордылар, шул исәптән элеккегеләрен рәтләделәр. Һәм 5000 баш чучка асрап, бер ел эчендә 500 тонна югары сыйфатлы ит тапшырдылар. Дөрес, бер-ике ел гына 5000 дуңгыз тоттылар, 4500–4000 – баш санын шуннан да киметмәделәр. Ә ит күләменә килгәндә, 350 тоннадан да кимрәк ит саткан вакыт булмады.



– Ул заманда авыл халкы, бигрәк тә өлкәннәр чучка үрчетүгә ничек карады? – дим.

– Ничек, дип. Нишлисең инде, сәясәткә каршы барып булмый. Ул чорда халыкны бер генә әйбер борчыды: авыл өстендә бер зәһәр ис бар иде. Ә дини ягына килгәндә, чучка асраганга карап кына халык диннән бизмәде. Мәчет булмаса да, ирләр җомга саен намазга җыелды, мөселманча исем кушылды, мәет җирләнде...

Бигеш авылы кешеләре өчен авылда дуңгыз фермасы булуның иң зур уңайлыгы – даими хезмәт хакы. Фермада алтмыш ике кеше эшли. Шуңа күрә колхозлар таркатылып, дуңгыз фермалары бетерелгәч, авыл кешеләре уфтанып та куя. Тукта, сүз башы бит Ленин сыны иде. Дуңгызчылык өлкәсендәге уңышлары өчен, дип, авылга Мәскәүдән кадәр кайтарганнар аны. Районга берне, нәкъ менә Бигешкә! Авыл халкы өчен зур горурлык булган ул. Шуңа да аны үзәккә – Мәдәният йорты янына куйганнар. Соңрак исә, 1992 елда, авыл үзәгендә мәчет төзелә. Тик аңа карап Ленин бабайга тимәгәннәр, чөнки алар өчен бу бер кадерле истәлек, үткәннәр кайтавазы...



Әллә бөек юлбашчы мәчеткә барырга чакыра, әллә киресенчә, аңламассың...

Бигеш урта мәктәбе күренекле галим, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты Мансур Хәсәнов исемен йөртә.

УКЫТУЧЫЛАР – МӘКТӘПНЕҢ ЙӨЗЕ

Бигеш урта мәктәбе күренекле галим, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты Мансур Хәсәнов исемен йөртә. Аталы шәхеснең кайчандыр бу мәктәптә укуы – укытучылар, укучылар өчен дә зур горурлык, бер үрнәк.

Бигешкә килгәч, мәктәпкә керми китә алмадык. Язма башында ук, укытучылар әле һаман да элеккеге директорның киңәшен тоталармы икән, дигән идем бит.

Мәктәп ишеге төбендә безне ак төстәге бәйләнгән күлмәк кигән сөйкемле мөгаллимә каршы алды. Фирдания Ханнанова – утыз ике ел балаларга химия, биология укыта икән, шуларның егерме биш елын – Бигеш урта мәктәбендә. Һәм... бәйли дә. Мөгаллимә, без киләсен алдан белеп, сыйныфында үзе бәйләгән күлмәк, костюмнардан күргәзмә ясап куйган. Шуларны күргәннән соң, сүз үзеннән-үзе бәйләүгә күчте:

– 10 нчы сыйныфта укыганда ук әнигә ияреп бәйли башладым, – диде оста куллы мөгаллимә. – Беренче кул эшем – карават башы иде. Соңрак күлмәк бәйләүгә күчтем. Юк, үзем өчен түгел, сеңелләремә бәйләп бирдем. Ни өчендер, мин үзем бәйләгән күлмәкләрне кия алмадым. Хәзер киям үзе, андый кыенсыну бетте.

Фирдания Мөнәвәровна төрле күргәзмәләргә дә йөри. Химия укытучысының кул эшенә оста булуы күпләр өчен гаҗәп тоела икән. Мөгаллимә бәйләү үрнәкләрен интернетта таба. Ә башта газета-журналлардан да карап өйрәнгән.

– Мәктәп балаларын да бәйләргә өйрәтәсезме? – дип сорадым.

– Хәзер юк, – диде ул. – Ни өчен дигәндә, бүген укучыларның вакыты юк. Икенчедән, аларга бәйләү әллә ни кирәк тә түгел, кызыксынулары икенче. Хәер, мәктәптә балалар саны да аз. Алар белән конкурска әзерләнәсеңме, имтихан сорауларын өйрәнәсеңме. Барысы да шул санаулы укучылар җилкәсендә бит!

Әйе, кайчандыр алты йөздән артык бала укыган мәктәптә бүген 55 укучы белем ала. Бу-биш авылга. Сүз уңаеннан, биредә 1979 елга кадәр татар балалар йорты эшләгән. Мәктәп каршындагы өч катлы бина әлеге балалар йортын хәтерләтеп тора. Анда тәрбияләнүчеләр дә янәшәдәге урта мәктәптә укып белем алганнар. Авылда яшьләр калмауның сәбәбен алда язып узган идем. Ни кызганыч, бу – шуның җимеше.

Бигеш мәктәбенең тагын бер үзенчәлекле мөгаллимәсе белән таныштык. Ул – Альфира Зәкиева, башлангыч сыйныф укытучысы. Безне кайсы ягы белән җәлеп иттеме? Эшкә киткәнче иртән торып, биш (!) сыер сава икән.

– Кайчандыр Бигеш мәктәбе директоры укытучыларга маллар тотмаска дигән тәкъдим белән чыккан. Сезгә дә җитәкчегезнең шундый фикер әйткәне юкмы? – дим мөгаллимәгә, ярымшаяртып.

– Юк. Ул бит минем төп эшемә комачауламый. Сыерлар күбрәк ирем өстендә, мин савучы гына.

– Гомергә шулай күп итеп мал асрадыгызмы? – дим.

– Берничә ел гына әле. Мәктәптә дәрес сәгатьләрем аз калгач, тормыш алып барырга кирәк, дип, ирем белән сыерлар сатып алдык. Ике улыбыз бар безнең. Аларны югары уку йортында укытырга кирәк. Алай да без дигәнчә генә булмады: мәктәптә эш килеп чыкты. Башлангыч сыйныф укытучы-

Бигеш мәктәбенең оста куллы укытучылары – Фирдания Ханнанова һәм Альфира Зәкиева.

Бигеш авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе – Рамилә Биктимерова һәм китапханә мөдире Айгөл Маликова.

сы лаеклы ялга чыкты да эшеннән китте. Мин аның урынына калдым.

Мөгаллимәнең ике улы да Казан дәүләт аграр университетында белем ала. Диплом алгач, авылга кайтып, хуҗалыкларын үстерергә уйлыйлар икән.

Бигеш мәктәбе укытучылары менә шулай яши. Костюм-чалбар гына киеп йөрүгә килгәндә, төрле чак була, диделәр. Хәер, алар минем болай өс-башка басым ясауны бик үк яратмадылар шикелле:

– Ул заманда халык фәкыйрь яшәгән, – диештеләр. – Укытучы авыл халкын агартучы саналган. Ә бүген авыл кешесе дә шәһәрдәге кебек яши: киенү рәвеше дә, көнкүреше дә әллә ни аерылмый.

Әлфия Гыйбадуллина

ХӨРМӘТКӘ ЛАЕКЛЫЛАР

Авылларга баргач та, кызыклы кешеләр эзли башлыйбыз. «Мөгезле» үк булмаса да, әлегә кадәр язылмаган тема булсын, дибез. Бигешкә баргач, андый кеше каршыбызга үзе очрады. Карасак, велосипедлы бер әби килә. Ерактан ук елмаеп сәлам бирде. Велосипедыннан төшеп, безнең белән бик тәмләп сөйләште:

– Әлфия апагыз булам мин, фамилиям – Гыйбадуллина. Монда туып-үскән кешеләр авылда икәү генә калдык хәзер. Җитмешне тутырдым инде, – диде.

– Яшегезне әйтмәсәгез, һич уйламас идек. «Сәпидтә» йөргән әбиләрне гел очратмыйбыз, – дим.

– Бу дүртенче «сәпитем» инде, кызым. Үземне белгәнне бирле «сәпиттә» җилдерәм. Кара җир чыккач утырам, кар яуганчы йөрим. Бигеш урамын көнгә алты әйләнеп кайтам. Бик рәхәт бит, аякларга да физзарядка.

Әлфия апа гомере буе колхозда эшләгән. Склад мөдире дә, ферма мөдире дә булган ул. Өч бала тәрбияләп үстергән. Бүген улы Рафис белән яши. Бигеш авылы китапханәчесе Айгөл Маликова Әлфия апа турында болай диде:

– Авылның иң күп китап укучысы гына түгел, иң актив кешесе дә Әлфия апа. Мәдәният йортында узган барлык чараларда актив катнаша. Өлкәннәр көненә ел саен гаҗәеп тәмле җимеш бәлеше пешереп алып килә.

Бигешнең тагын бер хөрмәтле кешесе белән таныштык – Гадилә апа Хәерова.

1958 елда Бигешкә ике каенана янына килен булып төшкән ул. Кырык елга якын каенанасы белән яшәгән. Тормыш иптәше белән өч кыз тәрбияләп үстергәннәр. Гадилә апа, 1959 елдан башлап, колхоз таркалганчы, дуңгыз фермасында эшләгән.

– Беренче урынны бирәүгә дә бирмәдем, – диде ак яулыгын матур итеп таратып бәйләгән әби. – Тырыш булдым. Каенаналарыма рәхмәт, бик ярдәм иттеләр. Балаларны караштылар, эштән кайткан җиргә ашарга әзер иде. Без кайтмыйча, ашарга утырмадылар. «Сез – эш кешесе», – дип кенә тордылар. Ирем дә дуңгыз фермасында эшләде. Күп тапкыр грамоталар белән бүләкләндек. Район өчен Бигеш дуңгыз фермасы зур табыш кертә иде. Шуңа да безгә карата игътибар зур булды. Тормышымнан бер дә зарланмыйм.

Гадилә апа бүген ялгыз яши. Хәер, алай дип әйтү бик дөрес түгел. Бер кызы, тормыш иптәше белән күршесендә яши. Икенче кызы да гаиләсе белән Бигештә гомер итә.

– Кызларым, кияүләрем, оныкларым да бик яхшы, Аллага шөкер, – дип, берничә тапкыр шөкер итте авылның ак әбие.

...Телгә оста, шат кешеләр яши Бигештә. Без моңа инанып кайттык. Май чүлмәге тышыннан билгеле, диләр. Килгәч тә Мәдәният йортында эшләүче ханымнарның ачык булуына игътибар иткән идек, җирле халык та шундый булып чыкты. Күрәсең, халык аларга карап үрнәк ала.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Картлар сөйләгәннәрдән шунысы билгеле: бу төбәккә беренчеләрдән булып хәзерге Мамадыш районы Комазан, Кирмән, тагын кайсыдыр авыл кешеләре күчеп утырган. Бигеш (Бигәш) дигән кеше беренчеләрдән булып бу җиргә килгән, дип фаразлана. Шуның өчен дә авыл аның исемен алган. Шуны да әйтим: «Бигәш» исеме бик борынгы, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына караган документларда ук очрый.

Әтием Нигъмәтулла, аның әтисе Ибәтулла, аның әтисе Таһир, аның әтисе Дәбир (Зәбир), аңа кадәр Габделмәҗит, аның әтисе Заһидулла, ә җиденче бабам Һаит исемле булган. Безнең илдә буыннар арасында уртача 30 ел аерма булуын истә тотып, әмма патша Россиясендә солдат хезмәтенең 25 ел булган чакларын да онытмыйча санап, Бигеш авылына 350 еллар дип әйтә алам.

2002 елда чыккан «Татар энциклопедиясе»нең 1 нче томында: «Бигеш авылы XVII гасыр ахырында – XVIII гасыр башында нигезләнгән», – дип язылган. Әлеге датаны борынгылата торган материалларыбыз азрак әле. Бу өлкәдә тикшеренүләрне дәвам итәргә кирәк.

Фаяз Хуҗин, тарихчы.

Халыклар арасында тынычлыкны саклау кемнән тора? Халыклар дуслыгына ничек теләктәшлек итәргә? Киләчәк буыннарның күңеленә ничек итеп керергә? «СМИротворец-2019» конкурсы финалистлары әнә шул сорауларга җавап эзләделәр, алар октябрь аенда Удмуртия Республикасы башкаласы – Ижевскида җыелды. Кунакчыл удмуртлар белән аралашкач, танылган Буран әбиләренең җырларын тыңлагач, легендар Калашников автоматыннан атып карагач, милли пәрәпәчләр белән сыйлангач, төрле төбәкләрдән килгән коллегаларын тыңлагач, җаваплар үзеннән-үзе табылды. Алар – журналист материалларын аерым оригиналь форма белән бирүдә, этносара бәйләнешләр темасына креатив якын килүдә, хиссез-җансыз пресс-релизларны кабатламаган иҗатта, нәкъ менә шул чын журналистика була да инде. Россия Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр советы әгъзасы, Этносара журналистика гильдиясе президенты Маргарита Лянге җитәкчелегендәге жюри Россия журналистларының төрле жанрларда һәм үзенчәлекле формаларда башкарылган эшләрен билгеләп үтте. Алар арасында: бөтен Россия буенча таралган удмурт мәдәнияте үзәкләре буйлап үткән велосипедчының юлъязмалары; «Бөтендөнья хәлифәте» төзү идеясе белән агуланган ирләре, алдап, Әфганстанга алып киткән һәм могҗиза белән генә кайта алган башкорт хатыннарының хикәяләре; төрле милләт халыклары вәкилләренең башка милләт авылы мохитенә «чумдырылуы»ннан реалити-шоу һ.б. «Татарстан» журналының «Авыл сәяхәтләре» шулай ук «СМИротворец-2019» конкурсының җиңүчесе булды, шул уңайдан без үзебезнең барлык Татарстан авылларын котлыйбыз!

– Чит ил халыкларының йолаларына һәм традицияләренә гаҗәпләнергә була, ә шул ук вакытта Россия халыкларында да гаҗәеп әйберләр күрергә мөмкин, чөнки без халыклар ягыннан да, аларның гореф-гадәтләре һәм традицияләре ягыннан да күп тапкырга баерак. Россиядә гомер итүче милләт халыкларын бер-берсе белән журналистик материаллар аша таныштырып, без элемтәләрне аңлаешлырак итәбез, дуслык күперләрен узарга булышабыз. Шул рәвешчә тынычлыкны саклыйбыз. Ягъни тынычлыкны саклау безнең һәркайсыбыздан тора, – дип нәтиҗә ясады Маргарита Лянге һәм булачак конкурсларның жюриларына киләчәк буыннарга барып җитәргә сәләтле тагын да кызыклырак материаллар белән очрашу теләде.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Казан. «Университет» тукталышы, 2019 ел

Александр Ефремов фотосы

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



Казан. «Ленин бакчасы» тукталышы, 1962 ел